ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№3 (327) – МАРТ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Эш
кешеләре

Игътибар үзәгендә –
мәктәп

Әдәбиятның
соңгы морзасы

– МИЛЛӘТТӘШЛӘР ОЧРАШУЫ – ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕБЕЗ БЕЛӘН УРТАКЛАШУ УЛ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов,
Ната Смирнова, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Айгөл Хәйри, Татарстанның атказанган
артисткасы. Лилиана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1000 данә,
рус телендә: 2500 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-751
Басарга кул куелды: 25.03.2019
Басмадан чыкты: 29.03.19

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ХЫЯЛЛАР – ТӘРТИП БУЕНЧА

Дөньяда язга шатланмый торган кешеләр дә бар, диләр. Шаккаткыч! Булсалар да, болар эссе илләрдә яшәүчеләдер: гомергә бер мәртәбә кар эрегәнне дә күрмә инде син! Хәер, эрүдә генәмени хикмәт, бу затларга кар үзе дә кул җитмәс хыял булып тоеладыр. Чана-чаңгы да шумыйча, Кар бабай белән Кар кызы әвәләмичә, якаңа салган кардан үрле-кырлы сикермичә, гомумән, рәхәтләнеп карда әвәләнмичә, яшәп кара әле син. Туңмыйча, өшемичә! Бездә озын-озак кышларны кичеп чыкканчы хәтта хыяллар да өшеп боз булырга өлгерә.

Ә без, үзебезнең тәнебез-җаныбызда ел фасылларының ничек алмашынуын тоеп-кичереп яшәүчеләр, җәй хакына ерак җирләргә очучылар, асылда, нинди шәп климатның насыйп булуы хакында уйлап та карамыйбыз. Бездәге кебек төрлелек, үзгәрешләр тагын кайда бар?! Чыдап кына өлгер!

Дөньяның төрле почмакларында һәм полюсларында яшәүче аборигеннар мондый бәхет хакында хыяллана гына ала. Ә бездә хыяллар – һәрчак көтеп алына һәм чынга аша. Билгеле бер җайга салынган тәртип буенча. Йөз процентка ышанырга була бу тәртипкә! Әйтик, кар турында хыялланучыларның хыялы кышын һичшиксез чынга аша. Җәйгә ымсынучыларга – июнь аен гына көтеп җиткерәсе. Урманнарның алтын-кызыл гәрәбә төсенә кереп балкуын көткәннәргә бүләк булып көзнең киләчәге шиксез. Ә инде табигатьнең уянуын зар-интизар булып көткән һәркемне яз сөендерәчәк: карларын челтәрләп эретеп, кошларын өздереп сайратып, төсләрне көннән-көн җетерәк, ямьлерәк итеп...

Сез әле һаман да эссе якларга юл тотарга җыенасызмы? Ашыкмагыз! Язны күрми каласыз лабаса! Һәм бер хыялыгыз чынга ашмый калачак... Ә хыялдагы яздан баш тарту – ярый торган эш түгел!

СЕЗНЕҢ ЯЗГЫ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **924 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

Харис Якупов. Иделдә яз. 1960 ел.

МАРТ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Казаннан Дрезденга кадәр.
Саксония ничек безнең стратегик партнерга әверелде

8. Прага шәһәре. Хезмәттәшлеккә курс.
Татарстан предприятиесе Чехиядә нинди завод төзеде

10. Яңа спорт объекты.
Ни өчен Юдинода хәзер ел әйләнәсе тимераякта шуарга мөмкин

12. «Эшкуарлык фабрикасы» миллионерлары.
Керемле бизнесны ничек төзергә һәм янмаска

16. Игътибар үзәгендә – мәктәп.
Яклауга кем мохтаҗ

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

22. Йолдызлар – безнең арада.
Ничек «Ел хатын-кызы» булырга

24. Хуҗабикәләрнең яшерен коралы,
яки Гаилә бәхетенең сере нәрсәдә

32. «Татарстан» журналы проекты.
Әбиләрне ничек матурлык алиһәсенә әйләндерергә

38. «Татарстан» рецепты.
Америка татарлары ни белән туклана

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

44. Тарихи сәхифәләр.
Казан ханбикәләре: Сөембикә

50. Индустриальләштерү героикасы.
Беренче бишьеллыклар республика йөзен ничек үзгәрткән

56. Әйдә, иптәш, безгә – колхозга.
Кумәкләшү өчен нинди бәя түләнгән

60. Совнарком һәм олы мәдәният.
Беренче татар опералары кайда туган

68. Әмирхан Еники.
Әдәбиятның соңгы морзасы

84. Татар авыллары.
Лашманчылар кайда төпләнгән

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

7.03

Одри Азуле, ЮНЕСКОның генераль директоры, – Казанда, ЮНЕСКО кафедралары Бөтенроссия конгрессының пленар утырышында:

– Татарстан төрле диннәр, мәдәниятләр, тарихларның үзәгендә тора һәм уңышлы мәдәниятара аралашуның уникаль тәҗрибәсенә ия, бу – бергә тату яшәүнең үтемле юлларын эзләүче бөтен дөнья өчен дә уникаль байлык. Әлеге фәлсәфә Татарстан Республикасы һәм ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитеты арасында югары профессиональ дәрәҗәдә алып барылган диалог эчендә ята.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

3.03

Наина Ельцина, Россиянең беренче Президенты хатыны, – Казанда, «Ельцин кубогы» халыкара теннис турниры көннәрендә:

– Татарстанны барысы да ярата, Казанны да яраталар, күпләр бирегә ял итәргә килә. Казанның әһәмиятле спорт ярышлары үзәге генә түгел, туризм үзәгенә дә әверелүе бик шәп. Сез кунакларга шат, һәм бу һәрвакыт сизелә.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

13.03

Владислав Веселов, «Динамо-Казан» уенчысы, туплы хоккей буенча Россия җыелма командасы составында Кышкы универсиада-2019 җиңүчесе:

– Алынган медальләргә әлегәчә ышанып бетмим, эмоцияләр – иң югары кимәлдә. Мөгаен, мин гомерем буе моңа әзерләнгәнмендер. Безнең команда җиңгәч, әти-әниләр дә, дуслар да шатланды, бу бик күңелле, борчылып торулары өчен барысына да олы рәхмәт.

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Подписка!
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Ватанга хезмәт итү –
намус эше!
Ватанпәрвәрләрне кайда әзерлиләр
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
21 марта 2019
18 марта 2019
Билгесез Фатих Кәрим
Шагыйрьнең эчкерсез дөньясы
Гаҗәеп балыклар: Тәтеш музее раритетлары турында
Безнең белән сәяхәт итегез
«Иң гаҗәеп сыйфатым – җанлылык, терелек»
Реклама 16+

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Саксония белән хезмәттәшлек республикага **НИНДИ** файда китерә

Татарстан предприятиесе Чехиядә **НИНДИ** завод төзеде

Юдинода хәзер **НИ ӨЧЕН** ел әйләнәсе тимераякта шуарга мөмкин

Керемле бизнесны **НИЧЕК** төзергә

Мәктәп: **КЕМ** яклауга мохтаҗ



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

СТРАТЕГИК ПАРТНЁРЛЫК: ТӨБӘК ДӘРӘҖӘСЕ

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Саксониягә һәм Бавариягә эш сәфәре.

КАЙДА:

Дрезден, Мюнхен

КАЙЧАН:

19 февраль

– Соңгы елларда Германия белән Татарстан арасында үзара товар әйләнеше $2 млрд ка җитә. Без немец компанияләре белән яхшы мөнәсәбәтләрне саклый алдык. Безнең берничә эре проектыбыз бар. Саксония һәм Татарстан Республикасы уртак көченең куәтенә ышанам, без аны актив рәвештә тормышка ашыра алабыз. Хакимият структурасының иң төп бурычларының берсе – бизнесны үстерү өчен уңай климат булдыру. Икътисадый мөнәсәбәтләр алга таба безнең сәяси мәсьәләләрне хәл итүгә позитив чагылыш табачак.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты

Фотолар ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды (Марат Хөсәенов)

ТУЛЫРАК:

Дрезденда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Саксония Премьер-министры Михаэль Кречмер белән очрашты. ТР Хөкүмәте һәм Саксония Федераль җирләре Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды. Татарстан Президенты килешү Россия–Германия мөнәсәбәтләрен ныгытуга юнәлдерелгән ике яклы төбәкара хезмәттәшлеккә яңа этәргеч бирәчәгенә ышана. Татарстан Саксония белән машина төзелеше комплексы, нефть химиясе, энергетика кебек кайбер тармаклар буенча хезмәттәшлекнең бай тәҗрибәсенә ия, дип хәбәр итте Рөстәм Миңнеханов. Вузлар арасындагы хезмәттәшлек мәсьәләсенә дә аерым игътибар бирелә. ТР Президенты шуны да искә төшерде: Германия Россия Федерациянең һәм, аерым алганда, Татарстанның стратегик партнёры санала. Хезмәттәшлекнең перспективалы юнәлешләре арасында ТР Президенты цифрлы икътисад сферасын билгеләп үтте. «Предприятиеләрне цифрлаштыру, хезмәт җитештерүчәнлеген, җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттыру сораулары буенча сезнең ил, шул исәптән Саксония, гаять зур тәҗрибәгә ия», – диде ул. Михаэль Кречмер, үз чиратында, алар имзалаган килешү ике төбәк арасындагы хезмәттәшлекне сыйфат ягыннан чыннан да яңа дәрәҗәгә күтәрергә мөмкинлек бирер, дип билгеләп үтте. Ул АСК тармагындагы уртак тикшеренүләрне активрак үстерергә һәм урта белем бирү өлкәсендәге хезмәттәшлекне ныгытырга чакырды.

ПЕРСПЕКТИВАЛАР:

Мюнхенда Рөстәм Миңнеханов Linde Engineering компаниясе Директорлар советы рәисе, Linde AG идарәсе әгъзасы Кристиан Брух белән очрашты. Татарстан Президенты 2017 елның июнендә Петербург икътисадый форумында «Түбән Кама Нефтехим»да яңа этилен комплексы төзелеше проектын Linde тарафыннан проектлаштыру турында килешү имзаланган булуын искә төшерде. Узган елда шулай ук Петербург халыкара икътисадый форумы мәйданчыгында башында «Дойче Банк» торган банклар консорциумы белән Татарстанның «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ арасында 800 млн евролык кредит килешүенә кул куелган иде. Акчалар яңа комплекс проектын финанслауга юнәлдерелә. Кристиан Брух, үз чиратында, ТР Президентына Linde компаниясенең Түбән Камада этилен комплексы өчен белгечләр әзерләү академиясен ачуы турындагы хәбәрне ирештерде. «ТКНХ»да яңа җитештерү төзелешен быелның көзендә башларга ниятлиләр. Проект 4 этапта гамәлгә ашырылачак. Нәтиҗәдә республикада 600 мең тонна этилен җитештерү буенча ике яңа комплекс пәйда булачак.

Татарстан Президенты Мюнхенда шулай ук Бавария дәүләт канцеляриясе җитәкчесе Флориан Херрманн белән алга таба хезмәттәшлек итү сорауларын тикшерде. «Татарстан һәм Бавария – әлеге ике эре төбәкнең бер-берсенә кирәклегенә ышанам», – диде Рөстәм Миңнеханов.

ПРАГА ШӘҺӘРЕ. **ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ КУРС**

– Без дәүләтләребез арасында нәтиҗәле элемтә урнаштыручы буын булырга омтылабыз. Узган елда Татарстан – Чехия арасында товар әйләнеше 41% ка үсте һәм 632 млн АКШ долларын тәшкил итте.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты

НӘРСӘ:

Чехиягә эш сәфәре

КАЙДА:

Прага, Брно, Простеев

КАЙЧАН:

5–6 март

Фотолар ТР Президенты сайтыннан (Эдуард Хәйруллин)

ТУЛЫРАК:

Сәфәр вакытындагы төп вакыйгалар арасында – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Прагада Чехия Республикасы Президенты Милош Земан белән очрашуы, Чехиядә «Данафлекс» компаниясе заводын ачу, төрле өлкәләрдә хезмәттәшлекне киңәйтү турында чех министрлык җитәкчеләре һәм бизнес җәмәгатьчелеге вәкилләре белән сөйләшүләр алып бару. Рөстәм Миңнеханов шулай ук Россия Федерациясе белән Чехия Республикасы арасында икътисадый, сәнәгать һәм фәнни-техник хезмәттәшлек буенча Чехия сәнәгать һәм сәүдә министры Марта Новакова һәм РФ сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров җитәкләгән хөкүмәтара комиссиясе утырышында катнашты.

Рөстәм Миңнеханов Милош Земан әфәндегә әлеге очрашу мөмкинлеге һәм Россиянең икътисадый яктан иң алга киткән төбәге саналган Татарстанга карата булган кызыксынуы өчен рәхмәт белдерде. ТР Президенты Татарстан белән Чехия Республикасы арасында хезмәттәшлекнең киләчәктә Россия–Чехия мөнәсәбәтләрен ныгыту хакына актив үсәчәгенә ышаныч белдерде. Рөстәм Миңнеханов Милош Земан әфәндене Россия Федерациясенә сәфәре вакытында Татарстанга килергә чакырды. Чехия Республикасы Президенты Казанга бик рәхәтләнеп киләчәген әйтте.

> – «Данафлекс» компаниясенең яңа җитештерүен ачу Чехиягә Россия инвестицияләрен кертүнең файдалы булуын күрсәтте. Яңа завод башка компанияләр өчен күркәм бер үрнәк булыр.
>
> ***Марта Новакова,***
> *Чехиянең сәнәгать һәм сәүдә министры*

ПЕРСПЕКТИВАЛАР:

Чехия шәһәре Простеевта «Данафлекс» компаниясенең яңа заводын кулланылышка кертү тантанасында Рөстәм Миңнеханов шуны җиткерде: сыгылмалы төргәк җитештерүгә турыдан-туры инвестицияләр күләме беренче этапта гына да 40 млн еврога якын сумманы тәшкил итте. Заманча җиһазландырылган яңа заводта 180 эшче урын ачылачак. ТР Президенты «Данафлекс»ның Россия базарының 15%ын алып торуын, төрү материаллары җитештерүдә лидер булып торуын искәртеп үтте. Яңа җитештерү өчен чимал Татарстаннан китереләчәк. Бу «Данафлекс» компаниясенең дүртенче заводы, Европада – беренче.

БЕЛЕШМӘ:

«Данафлекс» компанияләр төркеме – Россиянең сыгылмалы төргәк җитештерүчесе, ул базарның 15%ын биләп тора. «Данафлекс» заводлары югары технологияле пленка һәм сыгылмалы төргәк җитештерүнең тулы циклын гамәлгә ашыра. Компания азык-төлек сәнәгатенең төрле тармаклары өчен (май, кондитер, бакалея, сөт, снэк), һәм шулай ук тирәнтен катырыла торган продуктлар һәм эчемлекләр өчен төргәкләрнең киң спектрын тәкъдим итә. Моннан тыш, компания азык-төлек булмаган продуктлар өчен дә төрү материаллары җитештерә: көнкүреш химиясе, саклагыч пленкалар һәм хайваннар өчен товарлар.

ЮДИНО. БУЛАЧАК ҖИҢҮЛӘР АРЕНАСЫ

НӘРСӘ:

Боз аренасы ачылышы

КАЙДА:

Юдино бистәсе

КАЙЧАН:

4 март

– Бүген без әлеге күркәм боз сараен ачабыз. Проект бик кыска вакыт аралыгында тормышка ашырылды. Без хоккейны һәм фигуралы шууны үстерүгә зур игътибар бирәбез: республикада барлыгы 44 боз аренасы исәпләнә.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты

Фотолар ТР Президенты сайтыннан (Марсель Бадыйкшин)

ТУЛЫРАК:

Казан янындагы Юдино бистәсендә яңа боз аренасы төзелешенә ярты ел вакыт кына таләп ителде. Спорт комплексы нигезенә таш салу тантанасы, исегезгә төшереп үтик, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «РТЮ» ААҖ генераль директоры – идарә рәисе Олег Белозеров катнашлыгында узган елның августында узган иде. Боз аренасы ачылышы тантанасында Татарстан Президенты Юдинода спорт һәм социаль-мәдәни объектлар инфраструктурасын үстерү буенча эзлекле эш алып барылуын билгеләп үтте. Кыска срокларда төзелгән яңа матур боз сарае – башкарылырга тиешле киңкүләм эшләрнең бер өлеше генә. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, якын перспективада җирле Тимерьюлчылар мәдәният йортын, Иҗат йортын тәртипкә китерү һәм җәмәгать урыннарын төзекләндерү планлаштырыла.

Казан мэры Илсур Метшин Юдинодагы боз аренасының Татарстан башкаласында ачылган ясалма бозлы ундүртенче мәйданчык икәнлегенә басым ясады. Ул спорт объектларын үстерүгә ярдәм күрсәткән өчен республика җитәкчелегенә рәхмәтен белдерде.

– Бүген без барыбыз да әлеге шәп боз сараен, яшь хоккейчыларыбыз өчен булдырылган матур киләчәкне күрәбез. «РТЮ» ААҖ генераль директоры Олег Белозеров исеменнән барыгызны да әлеге күркәм вакыйга уңаеннан тәбрикләргә, яшь спортчыларга уңышлар һәм алтын бүләкләр яулауларын теләргә рөхсәт итегез, – диде «РТЮ» ААҖ генераль директоры урынбасары – баш инженеры Сергей Кобзев.

Спорт объекты алкалы хоккей һәм фигуралы шуу буенча ярышлар уздыру, шөгыльләнү өчен каралган. Моннан тыш, биредә Юдино бистәсендә һәм якын-тирәдәге районнарда яшәүчеләр өчен тимераякта шууларны оештыру планлаштырыла. Боз сарае ел әйләнәсе эшләячәк.

Фотолар Элина Комарованың шәхси архивыннан

ЭШКУАРЛАРНЫ ӘЗЕРЛИБЕЗ

Нәтиҗәле бизнес структурасын ничек булдырырга һәм, иң мөһиме, үз керемеңне ни рәвешле арттырырга? Әлеге һәм шуңа охшашлы башка сораулар-га «Эшкуарлык фабрикасы» проекты җавап бирергә сәләтле. Ул ТР Икътисад министрлыгы, Казан федераль университеты һәм Стратегик инициативалар агентлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Беренче мәртәбә Казанда оештырылып, соңрак Татарстаннан читтә дә гамәлгә кертелә башлаган проектның максаты – кешеләрне үзләренең бизнес-идеяләрен тормышка ашырырга өйрәтү. Биш ел эчендә фабрикада өч меңнән артык эшкуар уку-өйрәнү узган. Эшләп киткән 800 гә якын бизнес-проектны фабриканың беренче нәтиҗәләре дип атарга була.

ЭШ КЕШЕСЕ

Ул миңа эшен күрсәтә. Яшел фондагы картинада – кып-кызыл йөрәк. Нинди буяу кулланылган соң? Акварельме? Юк, икән шул. Картина мүктән эшләнгән.

– Өйдә – табигатьнең бер почмагы, карап, тәрбияләп тоту да таләп ителми, – дип елмая Элина Комарова. Әлеге табигый материал аңа үз стартабын табышка чыгарырга һәм «Эшкуарлык фабрикасы» проектында җиңәргә мөмкинлек биргән.

Автор:
Катерина Котова

ХЫЯЛЛАРГА ИЯРЕП...

– Кешеләрнең күбесе тормышында ниндидер тотрыклылыкны югалтудан курка, хәтта ки яраткан эшең өчен бары тик 20 мең сум гына түләсәләр дә, – ди Элина. – «Эшкуарлык фабрикасында» да барлык тыңлаучыларның, иялəшкән урыннарыннан торып китеп, үз бизнесларын ачарга кыюлыгы җитмәде. Бу бит зур тәвәккәллек сорый, җитди җаваплылык йөкли һәм, ниһаять, күпме борчу китерә. Ләкин барысы да үз эзенә төшәрлек, куркушикләнүләр юкка чыгарлык вакыт та җитәр, бәлки?

Бизнес-карьерасы башланганга бер елдан артык вакыт үткән. Төннәрнең берсендә Элинаның башына бер уй килә: ул ландшафт дизайны белән шөгыльләнәчәк! Менделеевның периодик таблицасы да авторның төшенә кергән, диләр, ләкин аңа кадәр галимнең бу турыда егерме ел уйланып йөргән азлар гына беләдер. Менә безнең героинябыз да бәләкәй чагыннан ук үз куллары белән матур әйберләр ясарга ярата: үзенә – күлмәкләр, дус кызларына сумкалар тегә. Дөрес, аңа дизайнерлыкка укырга керергә насыйп булмый. Әмма Элинаны бу туктатмый.

– Ландшафт дизайны курсларына укырга керү беренче адымым булды, – дип сөйли ул. – Мин тагын да мавыгыбрак киттем.

һәм үз эшемне ачарга кирәк дигән уем ныгый гына төште.

Атаклы бизнес-тренер Радислав Гандапас раслаганча, эшкуарны ялланып эшләргә әзер кешедән аерып торган төп сыйфат – эш барышында туа торган проблемаларга һәм уңышсызлыкларга бирешмәү: «Эх, презентация килеп чыкмады! Һай, клиент бернәрсәне дә сатып алмады! Эшкуарны озын дистанциядәге соңгы гомуми нәтиҗә кызыксындырырга тиеш». Элина атлаган сукмакта очраган иң беренче авырлык – дизайнер программасы таләпләренә җавап бирә торган компьютер техникасының булмавы, аның иске компьютеры мондый эшне тарта алмый. Элинага кирәкле техниканы сатып алу сегментындагы бәяләр 80 мең сумнан башлана. Эш башлаучы эшкуарга акчаны каян алырга?

– Мәшгульлек үзәгендә бизнесны үстерү өчен грант отарга мөмкин дигән хәбәрне ишеттем, – дип сөйли ул. –120 мең сум – минем максат өчен җитәрлек сумма. Нигә әле бу мөмкинлектән файдаланмаска, дип уйладым. Бизнес-план төзедем, анда ландшафт дизайны хезмәтләре күрсәтеп шактый акча эшләп булачагын дәлилләдем. Проектны махсус комиссия каршында якладым. «Бу кызның күзләре шулкадәр яна ки, барысын да булдырачагына шикләнмибез!» – комиссия карары шундый булды.

Грант бик зур ярдәм була һәм эш башлана. Шул ук вакытта эш башлаучы үзенең билгеле бер йөкләмәләре булуы турында да онытмый. Базарда, иң аз дигәндә дә, ике ел дәвамында эшләргә кирәк.

РУХЛАНДЫРГЫЧ АДЫМ

Бушлай игъланнар сайтына нинди хезмәт күрсәтүчегә турында мәгълүмат элүгә үк, Элинага беренче потенциаль сатып алучы шалтырата.

– Яшермим, бик куркыныч булып китте! – дип искә төшерә ул. – Кич буе интернетта нәтиҗәле сөйләшүләрне алып бару турында төрле мәкаләләр укыдым. Янымда тәҗрибә уртаклашырлык остазым да юк иде әле. Аның каравы, беренче клиентым гаҗәеп кеше булып чыкты – эрудицияле, иҗади, зыялы.

Ир-ат үзенең бөтен дөньяга сибелгән туганнарын бергә җыяр өчен ата-баба нигезен торгызырга ниятли. Ул инде кирәкле корылмаларны төзергә өлгергән: төп бинага өстәмә рәвештә – дүрт матур йорт (балаларының саны буенча). Алар туганнар җыелуга кунак йортына

әверелә. Элина әлеге территорияне төзекләндерергә, аны матурларга һәм уңайлы итәргә тиеш була.

Шул рәвешле ул үзенең беренче ландшафт дизайн-проектын эшли. Әлеге эшендә Элина бу күркәм гаилә тарихын берләштерергә тырыша. Эш алып барылырга тиешле утар юл буенда гына урнашкан. Биек коймалар төземәс өчен, аны үсемлекләрдән үреп ясарга була. Элина территориядә бассейн төзергә тәкъдим итә. Һәм шулай ук беседкага йорт кинотеатры да урнаштырырга булалар. Анда гаилә фильмнарын һәм видеохроникаларны бергәләп карар өчен җыелырга мөмкин булачак… Элина функциональ, ләкин шул ук вакытта уңайлы, кирәкмәгән детальләр белән катлауландырылмаган проект ясауга ирешә.

– Проектымның кайбер өлешен мин инде тормышка ашырдым, әмма эшләргә төп старт язга тәгаенләнгән, – дип сөйли Элина. – Сүз уңаеннан, сезон башына мин ныклап әзерләнергә тырыштым. Әле көз көнне үк гап-гади юл – бушлай игъланнар бирү нәтиҗәсендә заказлар җыйдым, кыш буе проектлар эшләдем һәм хәтта инде урында минем идеяләремне гамәлгә ашырырга тиешле подрядчыларны да таптым…

Бүген бизнесны башлау – һичкайчан булмаганча җиңел. Эш башлаучы эшкуар чишәргә тиешле иң зур проблема – аның үз куркуын җиңүе («ә килеп чыкмаса?!»), дип саный Элина. Әлбәттә, эшкә салган акчаларны югалту куркынычы, тәвәккәллек эшкуарлык эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә. Мөгаен, эшне кредит сорап банкка мөрәҗәгать итүдән башларга ярамыйдыр, әмма моннан башка мөмкинлегең юк икән, бөтен финанс куркынычларын исәпләргә һәм үзеңнең максатчан аудиторияңне җентекләп өйрәнергә кирәк.

«Эшкуар кайчак чынбарлыктан аерыла, ләкин бизнес – ул уен түгел, монда бөтенесен дә уйлап, исәпләп бетерергә кирәк» – «Эшкуарлык фабрикасы»ның беренче юбилеен билгеләп үтү тантанасында Рөстәм Миңнеханов яңа гына үз эшен ачкан эшкуарларга әнә шундый сүзләр белән мөрәҗәгать итте. Фабриканың максаты – бизнесны ничек дөрес итеп алып барырга өйрәтү генә түгел, әлеге проектларны гамәлгә ашыру чорында эшкуарга һәрьяклап ярдәм итү дә, дип өстәде ул. Нәкъ менә шул чакта, фабрикада, Элинаның үз бизнес-остазы пәйда була. Проект таләпләре буенча үзенең эше булган һәм ул аена 1 миллион сумнан да ким булмаган керем кертә торган кеше остаз була ала. Алексей Шамов шулай ук ландшафт дизайны белән шөгыльләнә, Элинага файдалы киңәшләрен биреп кенә калмыйча, мораль яктан да ярдәм итеп тора. Сүз уңаеннан, «Эшкуарлык фабрикасы» проектына ул «компания өчен» иптәш кызы Ләйсән Галимова (ул да дизайнер, тик интерьерлар буенча) белән килә. Уңышлы коммерция эшчәнлегенең төп принципларының берсе – кооперацияне кулланалар, кызлар фабриканың финалына кадәр җитәләр. Ә соңрак фабриканың җиңүчеләре дип табылалар.

– Без бер-беребезне бик яхшы тулыландырабыз. Клиентларыбыз бик еш кына йорт тирәсендәге кишәрлекләрен генә түгел, өйләрен дә матурларга омтылалар, һәм киресенчә. Шуңа күрә Ләйсән белән без берләшергә уйладык. Киләчәк планнары – уртак студия ачу.

ЮЛДАН ТАЙПЫЛМАСКА

«Эшкуарлык фабрикасы» белем бирү проекты – бүгенге стартапер өчен кирәкле белемнәр генә түгел, чынлыкта проект, уку вакытында ук көрәш уты кабызып, үзендә катнашучыларны намуслы көндәшлек рельсларына кертә. Фабрикага эләккән һәркемнең рейтингы тотылып бара. Җиңү (бизнеста шулай кабул ителгән) оригиналь идеяләр белән генә билгеләнми, монда финанс нәтиҗәләре мөһим. Ике ай эчендә Элина белән Ләйсән үзләренең табышларын ярты миллион сумга җиткергәннәр. Эшчәнлекләренең оригинальлегенә килгәндә, үзегез уйлап карагыз.

– Башта без табышны арттыру өчен, нәрсә эшләргә кирәклеген белми идек, – дип уртаклаша Элина. – Әйе, фабрикага без үз идеябез белән килдек – икебез дә дизайн белән мавыккан идек, ләкин шунда ук диярлек бу эш белән тиз генә акча эшләп булмаячагын аңладык. Проек-



тыбызны эшләү барышында, шулай ук остазыбыз киңәшләрен дә тотып, әкренләп кайсы юнәлештә хәрәкәт итәргә кирәклегенә төшендек.

– Көндәшлек булган һәр эштә ниндидер яңалык табарга стимул барлыкка килеп тора, – ди Элина.

Кыш – ландшафт дизайны сезоны түгел, ләкин нәкъ менә шул вакытта яшеллекне һәм җәйне сагына башлыйлар. Шуңа күрә дә кызлар вертикаль яшелләндерү белән шөгыльләнергә уйлыйлар. Идеяләре шәп булып чыга – тотрыклыландырылган мүктән эшләнгән эшләрне дизайн базарында хуплап каршы алалар.

– Әйе, шул бу, урманда үсә торган мүк, – дип күрсәтә Элина мүктән кызыл йөрәк ясалган картинага ишарәләп. – Мүкне махсус тотрыклыландыргыч эретмә белән эшкәрттек, ул үсемлеккә киләсе ун ел дәвамында тере һәм йомшак булып күренергә мөмкинлек бирә. Моннан тыш, мүк тузан җыеп тормасын өчен, аңа антистатик та сибәбез.

Элина белән Ләйсәнгә клиентлардан шалтыратулар башлана. Республика чикләре дә тарая – иң эре заказ Мәскәүдән алына. Бүген тотрыклыландырылган мүктән эшләнгән матур картиналы иң зур агач панель (иданнән түшәмгә кадәр) башкаладагы фатирларның берсен бизи. Хуҗага Казан дизайнерларының эше бик ошаган, ул үз офисын да шул рәвешле «яшелләндерергә» ниятли.

Сүз уңаеннан, Элинаны әлеге идеягә әнә шул – аның беренче клиенты рухланыра. Ул өендәге ишеген матурлауны сорый. Элина стандарт булмаган вариантны озак эзли. Иң кызыклысы өчен мүк кирәк була. Ул әлеге материал белән эшләүнең нечкәлекләрен өйрәнә, тәэминатчыларны эзли...

– Әлеге идея безгә җиңәргә булышып кына калмады, ниндидер бер «куркынычсызлык мендәренә» әверелде, ул ашыкмыйча һәм артык куркыныч тудырмыйча бизнесның төп юнәлешен үстерергә ярдәм итә, – ди Элина.

Стартапер иң еш очраткан проблемаларның берсе – үз эшеңне башлаганда стресснең соңгы чигенә җитү. Икенчесе – эшне рухланып һәм азарт белән башлап, шулай ук тиз арада сүнү.

– «Эшкуарлык фабрикасында» безнең белән бергә башлыклар бәйләргә теләүче яшьләр бар иде, ләкин 300 мең сум акча эшләр өчен генә дә күпме нәрсә бәйләргә кирәклеген санап чыгаргач, әлеге идея үзеннән-үзе юкка чыкты, – дип сөйли Элина. – Яки тагын берсе: акыллы яктырткычлар ясау белән хыялланган бер егет белән таныштым. Ә соңрак аның заказ буенча егерме яктырткыч эшләгәннән соң, бу эштән тәмам туйганын, хәтта ки күрәлмый башлаганын ишеттем.

Элина шуны да аңлый: әгәр эшне башыннан ахырына кадәр берүзең генә башкарсаң, физик талчыгудан һәм эмоциональ янудан котылып булмый. Өстәвенә, теләсә кайсы бизнеста күп кенә кызыклы булмаган эш табыла – исәп-хисап эшләрен алып баруны яисә башка теләсә кайсы көндәлек эшне. Вәкаләтләрне бүлешергә кирәк! Һәм бу бик катлаулы момент. Беренчедән, сиңа бу эшне синнән дә яхшырак итеп башка беркем дә булдыра алмас кебек тоела. Кешеләргә ышанырга өйрәнергә кирәк. Икенчедән, подрядчыларга түлисе килмичә, барысын да үзең эшләргә теләү омтылышы комачауларга мөмкин. Бу юл да дөрес түгел. Вәкаләтләрне башкаларга да тапшырып, өметле проектларны үстерү һәм яңа белемнәр алу өчен үзеңә вакыт калдырырга кирәк. Әлеге схемага таянып, акчаны тагын да күбрәк эшләргә була.

Фабрика минем өчен мизгел кебек кенә тоелды, бик тиз үтте, көн-төн эшләргә туры килде, дип таный Элина. Җиңү теләге шулкадәр көчле була!

– Бу проектта мин бик теләп катнаштым, мавыгып эшләдем. Биредә эшкуарлык идеясе белән янган, киләчәккә омтылган, үзенекен булдырырга тырышкан, рухи яктан үземә якын кешеләрне очраттым. Мин үземне киләчәктә уңышлы бизнес иясе итеп күрәм. Дизайн студиясен ачачакмын – моның өчен барысы да әзер! Алга таба хәрәкәт итүгә юнәлдерелгән яраткан эшең булу – уңышның нигезе, дип саныйм.

ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ – МӘКТӘП

Автор:
Руфия Фазылова

Февраль аенда РФ Дәүләт Думасы депутаты Борис Чернышев Россия мәгариф министры Ольга Васильевага мөрәҗәгать белән чыкты: укучыларга карата агрессия күрсәткән укытучыларның хезмәт хакын өчтән бер өлешкә киметергә. Агрессия тагын кабатлана икән, хезмәт хакын бермә-бер кисәргә. Депутат фикеренчә, укучыларга бөтен җан җылысын биреп эшләгән мөгаллим белән «кызу канлы» укытучы бертөрле акча алырга тиеш түгел.

Депутатның әлеге тәкъдименә бернинди рәсми җавап та булмады. Шулай да мәктәпләрдәге агрессия турындагы хәбәрнең Дәүләт Думасына кадәр барып җитүе әлеге проблеманың кискен торуы турында сөйли.

«УКЫТУЧЫҢ АЛДЫНДА ГАФУ ҮТЕН!»

Атна саен диярлек Россиянең теге яки бу төбәгендә мәктәп белән бәйле гаугалар чыгып тора. Әле бер мәктәптә укытучы укучыны кыерсыткан, әле икенчесендә кулын уйнаткан. Укучылар да кимен куймый: укытучының битенә төкерү, фәлән-фәлән тарафка җибәрүләр гадәти күренешкә әйләнеп бара. Аннан да хәтәррәкләре дә булгалый...

Татарстан да Россия мәктәпләреннән әллә ни аерылып тормый. Республика шәһәр мәктәпләренең берсендә белем бирүче укытучысы 9 нчы сыйныф укучысына: «Тынычланмасаң, бер шалтыратуым җитә, килеп, танавыңны җимереп китәчәкләр», – дип җи-

керенә. Казан мәктәпләренең берсендә рус теле укытучысы чыгарылыш сыйныф укучысына: «Дура! Синең имтихан ничек бирүең миңа барыбер» – дип дулый. Болар әле социаль челтәрләргә эләккән видеоязмалар гына. Әлбәттә, һәр очракта укытучы юктан гына чыгырдан чыкмаган, дип уйларга кирәк. Тик Интернетта нигездә мөгаллимнәрнең «тавышы гына йөри».

Нindидер нәтиҗәләр чыгарганчы, танышым Илфат белән булган хәлне бәян итим. Утыз яшен тутырган, укытучы стажы 8 ел булган әлеге тыйнак егет Казан мәктәпләренең берсендә укытты. Бер уйламаган җирдән ноябрь уртасында эшеннән китте. Юкса эшен яратып башкара, яңа уку елыннан үзен директор урынбасары итеп тә билгеләгәннәр иде. Бактың исә эш менә нәрсәдә икән: директор укырга китү сәбәпле, Илфатны вакытлыча җитәкче вазыйфаларын башкаручы итеп куйганнар. Гөнаһ шомлыгына каршы, нәкъ шул вакытта дүртенче сыйныф җитәкчесе белән бер укучы арасында конфликт килеп чыккан. Малай дәрес барганда укытучысына каршы әйткән. Шуннан бөтен яшьтәшләре алдында сыйныф җитәкчесенә төкергән. Укытучы, бу хәлгә түзә алмыйча, шунда ук Илфат янына кергән. Ул исә, директор вазыйфаларын башкаручы буларак, дүртенче сыйныф укучылары белән сөйләшергә юнәлгән. Эшнең нәрсәдә икәненә төшенгәч, Илфат малайга:

– Укытучың алдында гафу үтен, – дигән.

Укучы үтенмәгән. Алай гына да түгел:

– Син кем соң миңа... «Фәлән» җиргә кит, – дип җавап кайтарган.

Бу мизгелдә инде Илфатның сабырлыгы беткән: укучы малайны этеп җибәргән...

Икенче көнне укытучыларны «фәлән җиргә» җибәрүче малайның әнисе район мәгариф бүлегенә барып шикаять язган. Мәктәпкә тикшерү килгән. Илфат, озак та уйламыйча, эшеннән китү турында гариза язган.

– Минем өчен иң аяныч – теге укытучыны яклаучы да, аннан гафу үтенүче дә булмады, – ди Илфат. – Ананың тәрбия күрмәгән баласы да хаклы булып калсын инде?! Ә мескен укытучыларны ник берәү дә якламый!

Бу укытучы ни өчен сабырлыгын җуярга мөмкин соң дигән сорауга җавап. Яңалык ачмам: бүген укучы укытучыга теләсә нәрсә әйтә ала. Югары икътисад мәктәбе (ВШЭ) тарафыннан 2018 елда, мәктәпләрдә укытучы белән укучы бер-берсенә карата нинди мөнәсәбәттә булуын ачыклау максатыннан, онлайн-сораштыру уздырылган. Аның нәтиҗәләре белән «Белем бирү мохитендә көч куллану» дип аталган конференциядә таныштырдылар. Саннар ныклап торып уйланырга мәҗбүр итә: сораштыруда катнашкан укытучыларның 70 проценты мәктәпләрдә мөгаллимнәрнең укучылары тарафыннан кимсетелүләре турында ишетеп-күреп белә. «Әйе, укучылар миңа карата агрессия күрсәтә», – дип җавап биргән укытучыларның яртысы ике-өч мәртәбә мыскыллауга дучар ителгән, ә 6 проценты мондый хәлләрне даими рәвештә кичерә икән. Ничек итепме?

Менә кайбер мисаллар:

– укучылар аларны махсус рәвештә үчекли, төрле кушаматлар уйлап таба, укытучыны ишетмәмешкә, күрмәмешкә салыша;

– мөгаллимнең шәхси тормышын тикшерә;

– ишарәләр һәм күз карашлары ярдәмендә укытучысын яратмавын күрсәтә;

– дисциплинаны системалы рәвештә һәм махсус боза;

– укытучы кушканны эшләүдән баш тарта һ.б.

Әле кайчан гына мөгаллимне илаһи затка тиңлиләр иде. Берничә дистә ел эчендә нәрсә булды соң? Шул хакта абруйлы Казан мәктәбенең директоры белән сөйләштек. (Ул тулы исемен күрсәтмәвебезне үтенде).

– Җәмгыять үзгәрде, төп сәбәп шунда, – диде ул. – Гомумкешелек кыйммәтләренә игътибар кимеде. Ә бу аерым бер зәгыйфьлеккә китерә. Мәктәпләрдәге агрессия – шуның ачык мисалы.

Ә сез алда бәян иткән очракны шәрехләү авыррак. Ни өчен дигәндә, ситуациянең ничек булганын төгәл белмибез бит. Тик нәрсә дисәм дә, Илфат исемле укытучы дөрес эшләмәгән. Укытучы укучыга кагылырга тиеш түгел! Бу очракта ул, җитәкче буларак, теге сыйныфка да атылып керергә тиеш түгел иде. Башта укытучыны тынычландырырга, конфликтның асылына төшенергә кирәк. Аннан – кабинетына әлеге дә баягы укучы белән ата-анасын чакыртырга. Һәм барысы бергә җыелып, хәлне уртага салып сөйләшергә. Гадәттә, гаеп бер яклы гына булмый, дистә еллар директор булып эшләү дәверендә мин моңа кат-кат инандым. Бу очракта укытучы егет тәҗрибәсез булган, шуңа күрә дә әлеге конфликтны җайлап җибәрә алмаган.

Мактанып әйтү түгел, безнең мәктәптә зурга киткән гауга чыкканы юк. Әйе, ата-аналар белән укытучылар арасында ниндидер аңлашылмаучанлыклар була. Тик аның 90 проценты мәктәп эчендә генә кала. Конфликтлы очракларда «өчлекне» – укучы, укытучы, ата-ананы – үз кабинетыма чакырам. Һәр як үз фикерен әйтә. Аннан соң нәтиҗә чыгарабыз. Күп очракта уртак фикергә киләләр!

«ЯРДӘМ КИРӘК!»

Шунысы гаҗәп: ниндидер низагларга катнашы булган укытучыларның күбесе – мәктәптә дистә еллар эшләгән мөгаллимнәр. Шул исәптән Татарстан мәктәпләре белән бәйле гаугаларда да сүз стажлы, тәҗрибәле укытучылар турында бара. Ни өчен шулай? КФУның Психология һәм мәгариф институтындагы педагогик психология кафедрасы доценты Резеда Хөсәенова республиканың 7 районында яшәүче 600 укытучы катнашында тикшеренү үткәргән. Һәм шундый нәтиҗәгә килгән: эш стажы 15 елдан артык булган мөгаллимнәр профессиональ яктан тәмам талчыккан, йончыган.

– Күбрәк эшләгән саен, укытучы дистанцияне саклый алмый башлый, ягъни өенә кайткач та, мәктәп турында онытмый. Бу сәламәтлек, эмоциональ халәт өчен бик зыянлы. Нәтиҗәдә, андый мөгаллимнәрдә «һөнәри яну» күзәтелә.

«Һөнәри яну» турында психологлар, психиатрлар да күптән чаң кага. 1974 елда ук Америка психиатры Герберт Фрейденбергер аерым хезмәтләр язган. Һәм бу бер укытучы һөнәренә генә кагылмый. Халыкара кадрлар порталы (hh.ru) «һөнәри яну» куркынычы сагалаган иң төп биш профессияне атаган. Менә алар: укытучылар, медицина хезмәткәрләре, банкта эшләүчеләр, социаль ярдәм күрсәтү хезмәткәрләре, кибетчеләр. Күргәнебезчә, исемлекнең башында укытучылар тора. Резеда Хөсәенова, моңа гаҗәпләнәсе юк, ди:

– Бүген берәү дә укытучының тормыш рәвешен, рухи дөньясын тикшерми. Төп күрсәткеч – мөгаллимнең белем бирүе. Ә бит ул да шушы җәмгыятьтә яши. Укытучының да авыр вакытлары була, әмма ул эмоция-кичерешләрен тышка чыгармый. Һәм көннәрдән бер көнне аның сабырлыгы шартларга мөмкин. Шуның өчен бүген мәктәп психологы укытучылар белән дә эшләргә тиеш.

2017 елда КФУның педагогик психология кафедрасы мәктәп психологлары өчен махсус программа эшләгән. «Укытучыда «һөнәри яну» булмасын өчен профилактика чаралары» дип атала ул. Программа сайлап алу турларын узган, хәтта уку программаларының реестрында да теркәлгән. Тик, ниндидер сәбәпләр аркасында, гамәлгә кертелмәгән.

– Программа укытучыга үзенә читтән карарга, халәтен анализларга өйрәтә, – ди Резеда ханым. – Адекват булмаган ситуацияләрдә ничек итеп үзеңне тыныч итеп, нормада тотарга кирәклеген аңлата. Тик, ни кызганыч, әлегә ул мәктәпләргә кермәде…

Аттестация узган вакытта бүген укытучылар психологик квалификацияләрен дә күтәрә ала. Әмма бу мәҗбүри түгел. Мөгаллимнәр моны күп вакытта кирәксенми икән. Ә бу бик мөһим, ди белгечләр.

«ЯКЛАУЧЫ ЮК!»

Бүген педагогика институтларына укырга кергәннәрнең зур күпчелеге үзләренең киләчәкләрен мәктәп белән бәйләргә җыенмый. Шуңа күрә мәктәптә эшләүче укытучылар – нигездә өлкән яшьтәге белгечләр. Бу яктан Татарстан да искәрмә түгел: укытучыларның уртача яше – 47. 58 процент укытучының эш стажы 20 елдан артык вакыт аралыгын тәшкил итә. Шуңа күрә, нәрсә генә әйтсәк тә, бүген мәктәпнең «кабыргасы» – стажлы укытучылар. Резеда Хөсәенова әйткәннәрне күздә тотсак, аларның күбесендә «һөнәри яну» башланган булырга мөмкин. Ә нишләргә соң?

Узган уку елында Татарстан мәктәпләреннән күпме мөгаллим эштән киткән, алар арасында 35 яшькә кадәргеләре күпме? Бу турыда мәгълүмат алу өчен, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгына мөрәҗәгать иттек. 2017/18 уку елында төрле сәбәпләр аркасында (лаеклы ялга чыгу, Татарстаннан читкә китү, башка эшләргә күчү һ.б) 3 мең 300 укытучы эшеннән китте, дигән рәсми җавап алынды. (Кызганычка каршы, министрлыкта эштән китүчеләрнең яшен, конфликтлы очраклар белән бәйле гариза язучыларның санын ачыклау буенча аерым статистика алып барылмый). Шул ук вакытта, ел саен Татарстан мәктәпләренә 3 мең 500 белгеч килә, шуларның 800е – яшь укытучылар. Яңа уку елы башында ТР мәктәпләре 99 процентка кадрлар белән тәэмин ителгән булган. (Дөрес, бу очракта квалификациясен үзгәртеп, ягъни бер фәннән икенче фән укытуга күчкән мөгаллимнәрне дә исәпкә алырга кирәктер. Мондый күренеш аеруча авыл мәктәпләрендә еш очрый).

Казан мәктәпләренең берсендә эшләүче яшь укытучы Илсур Ф. белән сөйләштем. (Төгәл адресын күрсәтмәвемне үтенде). Мәктәптә өченче елын эшли. Үзе әйткәнчә, тәмам гарык булган.

– Бүгенге мәктәп без укыган чордагы кебек түгел, – диде ул. – Тәртипләр башка. Ялгыш кына баланың кулына яки башка җиренә кагылып китүдән куркасың, педофиллыкта гаепләргә дә күп сорамыйлар. Гомумән, бүген балалар белән үзеңне ничек тотарга да белмисең. Кемгәдер аерым игътибар күрсәтсәң, яклый, диләр, катырак әйтсәң, тагын ярамый. Иң мөһиме – укытучыларны яклаучы юк. Күптән түгел мәктәптә бер очрак булды. Тарих укытучысына бер ата кул күтәргән. Укытучы эшне судка кадәр җиткерергә теләгән иде, директор туктатты. «Безнең янда эшлисең килсә, тавышны мәктәптән читкә чыгарма!» – диде. Мәктәп директорларына уку йортының абруе кыйммәт. Шуңа да тиз генә конфликтны йомарга, мәктәптә генә хәл итеп бетерергә тырышалар. Башка мәктәптә эшләүче коллегалар белән аралашып торам, аларда да шул ук хәл. Укытучылар якланмаган. Миңа калса, без үзебезгә аерым бер оешма төзергә тиешбез. Кеше хокукларын яклаучы аерым оешмалар бар бит, шулар да кушылсын. Көчле юристларны чакырыйк…

Бу турыда адвокат Руслан Нагиевның фикере белән дә кызыксындык:

– Әгәр цензурага туры килмәгән сүзләр яки көч кулланса лар, барлык гражданнар кебек үк, укытучы да, үз хокукларын яклап, судка мөрәҗәгать итә ала. Тик бу очракта укытучысына сугенгән яки мәктәп дисциплинасын бозган укучының ата-анасын административ хокук бозу буенча җавапка тартырга мөмкин. Ә 14 яшькәчә бала – кагылгысыз, хәтта хәтәррәк җинаять эшләсә дә… Бәлки, мөгаллимнәрне яклый торган аерым законнар кабул итәргә вакыт җиткәндер. Бала хокукларын яклау турында законнар бар, укытучыга кагылышлысы юк. Бүген укучылар теге яки бу конфликтны видеога төшереп социаль челтәрләргә куя. Һәм күп вакытта балалар укытучыларны гаепле итеп калдыра. Ә чынлыкта конфликтның сәбәбен, чын асылын аңлаткан кадрлар Интернетка эләкми, – дип, үз фикерен белдерде юрист.

…Миңа калса, җәмгыятьтәге тирән үзгәрешләр, шул исәптән совет чорындагы белем, тәрбия бирү системасы (ә ул иң алдынгы белем бирү системаларының берсе саналган) җимерелүе белән бергә, укытучы белән укучы, аларның ата-аналары арасындагы мөнәсәбәтләр дә үзгәрде. Ата-аналарның үз функцияләрен башкаруы, баласы белән аралашу методлары, кыйммәтләр системасы да үзгәреш кичерде. Еш кына бүгенге ата-ана үзе үк тәрбиягә мохтаҗ. Бүгенге көндә гамәлдә булган социаль институтларга да әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, аларны өйрәнеп эш итәргә, гаиләгә, мәктәпкә ярдәм кулы сузарга кирәктер… Мәктәп системасы бүгенге җәмгыять ихтыяҗларын канәгатьләндерә ала торган яңа таләпләргә, яңа алымнарга таянырга тиеш. Шунсыз булмый.

Сүземне төгәлләп шуны әйтәсем килә: югарыда исеме телгә алынган Борис Чернышев укытучыларга һәр биш елдан соң бер ел түләүле ял бирергә тәкъдим итте. Менә монысы чынлап та зарур, минемчә.

Энҗе Латыйпова, КФУның Гамәли психология, этнопсихология һәм мәдәниятара коммуникацияләр психологиясе фәнни-белем бирү үзәге директоры:

– Бүген әти-әнигә, балага, мәктәпкә дә таләпләр югары. Ә кешегә мөмкинлекләреннән артыграк таләпләр куела икән, теге яки бу эмоциональ реакция барлыкка килә. Шуларның берсе – агрессия. Нәрсә ул агрессия? Гади генә әйткәндә, начар, негатив эмоция. Ул төрлечә – вербаль һәм вербаль булмаганнан башлап, физик көч куллануга кадәр барып җитә. Агрессия күрсәтү – кешенең көчсезлеге яки аның нинди дә булса хокуклары кимсетелгәнлеге турында сөйли. Агрессия ул медальнең икенче ягы. Ә икенче ягында кешенең көчсезлеген күрәбез.

Өчпочмак – укытучы, укучы, ата-аналар – мәктәп системасын билгели. Укучыдагы агрессия сәбәпләре турында сөйләгәндә, шуны карарга кирәк: баланың нинди ихтыяҗлары кимсетелгән? Физик, биологик куркынычсызлыкмы, балага карата хөрмәт, ярату юкмы – өйрәнергә кирәк. Бала үзен яратканнарын белсен, үзен кирәк, дип тойсын.

Ата-ана бүген укытучыга карата югары таләпләр куя. Тәрбия дә бирсен, укытсын да. Ә үзләренең ул-кызлары белән шөгыльләнәсе килми. Шуңа ата-ана баласына бирмәгән игътибарын финанс як белән тигезләргә тырыша. Ә бу, үз чиратында, балаларны кулланучы гына булырга өйрәтә.

Кызганычка каршы, мәктәп системасында җитешсезлекләр шактый. Бүген укытучы тәрбияче дә, тьютор да, оештыручы һ.б. да. Ә бит болар бүленгән булырга тиеш. Андый очракта укытучының эше җиңеләер иде...

Гүзәл Удачина, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

– Узган 2018 елда гына да мәктәпләрдәге конфликтлы ситуацияләргә бәйле 120 гариза керде. Коллектив белән язылган мөрәҗәгатьләр дә булды. Ни өчендер прокуратурага караганда, безгә күбрәк мөрәҗәгать итәләр. Ләкин шуны да әйтим: ата-аналар башта зарларын мәктәп җитәкчелегенә хәбәр итә, чара күрелмәгән очракта гына башка органнарга чыгалар.

Мөрәҗәгатьләр арасында иң киң таралганы – психологик басым, ягъни мыскыллы, тәртипсез сүзләр әйтү, корректлы булмаган ниндидер кисәтүләр. Бу башлангыч сыйныфларда да күзәтелә.

Укытучы белән укучы арасындагы низаглы очракларны өйрәнгәч, шундый нәтиҗәгә килдем: профессионал буларак укытучы начар булмаска да мөмкин, әмма ул балаларны яратмый. Ә балаларны яратмаган кешегә мәктәптә эшләргә ярамый!

Миңа калса, бүген БДИ нәтиҗәсенә караганда, мәктәпләрдә укучы өчен тудырылган мохит мөһимрәк. Һәм белем бирү йортларының рейтингын төзегәндә, конфликтлы очракларның булу-булмавы да исәпкә алынырга тиеш.

Юрий Прохоров, Татарстан укытучылары профсоюз комитеты рәисе:

– Соңгы арада укучы-укытучы мөнәсәбәтләре турында еш сөйләргә туры килә миңа. Хәзер дә шуны кабатлыйм: укытучы хезмәтче түгел! Ни кызганыч, бүгенге система мөгаллимнәрне шундый вазыйфага куйды.

РФнең «Мәгариф турында»гы Законында барысы да язылган: укытучы һәм укучы мәктәптә үзен ничек тотарга, шул исәптән ничек якларга тиеш. Ни өчендер соңгы елларда без күбрәк укучы хокуклары турында гына сөйләшәбез. Ә бит укытучының да хокуклары бар. Мисал өчен, укучы укытучыга дорфа сүзләр әйтте яки сүгенде, ди. Әгәр бу беренче тапкыр гына икән, укытучы мәктәпкә укучының ата-анасын чакыра. Хәлне уртага салып сөйләшәләр. Тагын шундый очрак кабатланса, мәктәп администрациясе дә кушыла. Аннан соң да уңай нәтиҗәләр күренмәсә, балигъ булмаган балалар белән эшләү инспекторын да чакыру зарурияте туа. Алар начар, тәртипсез укучыларны учетка куярга мөмкиннәр. «Мәктәп Уставы»на буйсынмаган (әлеге дә баягы тәртипсезлек, укытучыны санга сукмау һ.б.) укучыны белем бирү учреждениесеннән куарга да мөмкиннәр. Бу хәлләр системалы рәвештә кабатланганда һәм элегрәк кулланылган тәрбия чаралары нәтиҗә бирмәгәндә, укучыны махсус мәктәпкә дә җибәрергә мөмкиннәр. Ләкин боларның барысын да мәктәп администрациясе үзе генә хәл итми. Моның өчен белем бирү учреждениесенә балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе әгъзалары килә. Махсус комиссия төзелә, беркетмә тутырыла, карар чыгарыла. Тик, тәҗрибә күрсәткәнчә, бүгенге көндә махсус мәктәпкә җибәрүләр кулланылмый дияргә була. Т

Югары икътисад мәктәбе (ВШЭ) уздырган тикшеренүдә катнашкан укытучылардан:

«Укучыларыгыз тарафыннан сезгә карата күрсәтелгән агрессия турында башкаларга сөйлисезме?» – дип сораганнар. Җаваплар түбәндәгечә:
- 35 проценты коллегалары белән уртаклаша;
- 31 проценты гаиләсенә сөйли;
- 23 проценты бу турыда берәүгә дә әйтми;
- нибары 13,2 проценты психологка мөрәҗәгать итә.

СТРАТЕГИЯ – МИНЕМ ФИКЕР

Татар халкы үсеше стратегиясен әзерләү турындагы фикерләрне март санында да дәвам итәбез. Бу санда сүзне тарихчы, ислам белгече, берничә телләр белүче югары уку йорты мөгаллименә бирергә булдык.

«БЕЗ ҮЗЕБЕЗНЕҢ ТАРИХЫБЫЗНЫ БЕЛМИБЕЗ!»

Азат Ахунов, филология фәннәре кандидаты, тарихчы

– Стратегия берничә бүлектән торачак, монысы аңлашыла. Аның милли-мәдәни мирас өлешенә караган бүлегендә күбрәк гомуми сүзләр әйтелә кебек. Беренче чиратта шуңа игътибар ителсен иде.

Соңгы елларда традицион ислам турында еш кына фикер алышалар. «Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави, Риза Фәхретдинов кебек күренекле шәхесләребезнең хезмәтләренә таянырга, аларны торгызырга кирәк», – дип сөйлиләр. Ләкин аларның эшләре ислам дине белән генә чикләнми. Алар бит тарихны да өйрәнгән. Ул әдипләребез әдәбият, төбәк тарихы белән бәйле күпме документлар, истәлекләр калдырган. 1917 елгы революциягә кадәр әдипләрнең барысы да өйрәнелмәде. Мәсәлән, шул ук Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимовларның аерым әсәрләре. Әйе, аларның мирасы соңрак кайтты, әле анысы да тулысынча түгел.

Ни кызганыч, без үзебезнең тарихыбызны аз беләбез. Тарих институты «Татар тарихы»ның җиде томлыгын чыгарды, ләкин анда аерым детальләр кермәгән. XIX гасыр буенча Милли архивта «Татар ратушасы» дигән фонд бар. Бер галимне санамаганда, аның белән шөгыльләнгән кеше дә юк. Ә бит «Татар ратушасы» фонды XVIII гасыр азагыннан башлап оеша, бик күләмле, бай мәгълүматлар тупланган анда. Бу байлыкны берничек тә бер генә кеше эшләп, өйрәнеп бетерә алмый.

«Татар ратушасы» XIX гасырда шактый көчле оешма була. Бирегә татарлар үзләренең проблемалары белән килгән. Фондта бүген меңләгән документ бар. Аның буенча Казан татарларының тарихын язарга була. Алар бик кызык – ул замандагы милләттәшләребезнең тормышы, кимчелекләре, барысы да бар. Мин ул документларның бер өлеше белән таныштым. Һәм шундый нәтиҗәгә килдем – XIX гасырда да хәзерге проблемалар булган. Милләтләрне кысу, телләр бетүне күздә тотам. Безгә әлеге мирасны кайтарырга, аны өйрәнергә кирәк. Төрек, гарәп дөньясы белән чагыштырганда, әлбәттә, без кальшабыз. Моңа гаҗәпләнәсе юк, сан ягыннан татарлар азрак. Ләкин безнең дә аларныкы кебек бай мирасыбыз бар. Аны өйрәнергә, халыкка танытырга бер нәрсә дә комачауламый: сәясәткә каршы килми бит бу...

Әйе, институтларда тарих, борынгы мирас белән эшләүче галимнәр, белгечләр бар. Тик ул кадрлар гына җитми, биш-алты кеше белән генә андый күләмле эшне башкарып чыгу мөмкин түгел. Бу өлкәдә эшләү өчен махсус фәнни төркемнәр кирәк. Ул белгечләр бездә бар да, әмма ләкин эш әлеге дә баягы акчага кайтып кала.

Милләтне, телне саклап калу буенча проектлар шактый. 90 нчы еллардан соң алар аеруча күп булды. Тик ул күбрәк «формаль» рәвештә эшләнде. Ә стратегиянең язмышы бүтәнчәрәк: халыкта кызыксыну, нәрсәнедер үзгәртергә теләк бар. Алга таба нишләргә, милләтне ничек саклап калырга? Бу сорау бик күпләрне борчый. Стратегия законга каршы килми, димәк, аны үстерергә була. Җитәкчеләр белән халыкның мәнфәгатьләре туры килүе, берберсен аңлаулары гына кирәк, дип уйлыйм.

Стратегия буенча үз фикерләремне тупладым. Мин аларны түбәндәгечә аерып билгеләр идем:

- РФ Фән һәм мәгариф министрлыгына чыгып, Татарстан һәм татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә, милли кадрлар үстерү максатыннан, бюджет урыннар сорарга. КФУда татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате белән бәйле юнәлештәге факультетларда бюджет урыннарны кимендә 80 процентка җиткерергә;
- татар тарихы, әдәбияты, сәнгате белән бәйле чыганакларны, гомумән, язма мирасны җыю, барлау системасын булдыру. Россиядә һәм чит илләрдә татарлар яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештыру;
- халыктан кульязмалар һәм сирәк китаплар сатып алу өчен махсус фонд булдыру;
- ТР Фәннәр академиясе базасында татар мирасын пропагандалау өчен өч телдә чыга торган фәнни журнал булдыру;
- татар телен белмәгән, әмма милли үзаңын саклап калган милләттәшләребез белән эшне активлаштыру зарур. Татар рухи мирасы, әдәбияты, сәнгате белән бәйле язмаларны рус теленә тәрҗемә итәргә, аларны милләттәшләребезгә таратырга кирәк. Аерым сәбәпләр аркасында, туган телен белмәгән күпме милләттәшләребез бар. Алар татар булулары белән горурланалар, тамырларын эзлиләр. Димәк, без алардан йөз чөерергә тиеш түгелбез!

Әзерләде:
Руфия Фазылова

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

НИЧЕК «Ел хатын-кызы» булырга

Гаилә бәхетенең сере **НӘРСӘДӘ**

Әбиләрне **НИЧЕК** матурлык алиһәләренә әйләндерергә

Америка татарлары **НӘРСӘЛӘР** белән туклана

ЗУР ХИМИЯ **ЙОЛДЫЗЛАРЫ**

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсына быел 600 гариза тапшырылган иде. Дәгъва кылучыларның һәрберсе – тормышның һәр тармагында уңыш һәм гармониягә ирешүнең чын үрнәге булгандыр.

Түбән Камада конкурсның зона туры 12 февральдә – Гашыйклар көне алдыннан узды. Бу исә залдагы атмосферага да йогынты ясамый калмагандыр: монда искиткеч җылы һәм дустанә мөнәсәбәт хөкем сөрде. Конкурсантлар әзерләгән тамашаны карап, «үзебезнекеләр өчен җан атарга» теләүчеләр дә бик күп булып чыкты – буш урыннар бөтенләй калмады. Гүя сәхнәгә цех, завод, лабораторияләре хезмәттәшләре түгел, ә дөньякүләм танылган йолдызлар чыгарга тиеш… Ул арада сәхнә артында Түбән Каманың гап-гади кешеләре, дулкынлану хисен җиңәргә тырышып, үз эшләре турында сөйләргә әзерләнә иде. Аларның күбесе өчен бу бәйге – сәхнәдә чыгыш ясауның беренче тәҗрибәсе.

ИГЕЛЕКЛЕ ТЫЛСЫМ

«Һөнәрем – минем язмышым (Хатын-кыз җитештерүче)» номинациясендә катнашучылар аеруча күп. Елена Николаевна Ткачева, әлеге чыгышына үзенә хас җаваплылык белән килеп, ТАИФ компанияләр төркеменә кергән «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ фән-технология үзәгендә әйдәп баручы инженер-технолог эшенең тормышында нинди роль уйнавын сөйләде.

Елена Николаевна мономерлар һәм пластмасса тикшеренү лабораториясендә инновацияле продуктлар уйлап табу юнәлешендә эшли. Без көнеккән төргәкләр һәм башка пластик предметлар нәкъ менә аның катнашында ясалган һәм алар чит илдән товар кертүне уңышлы алмаштырып килә. Былтыр Елена ханымның уңышларын «Ел инженеры – 2018» Бөтенроссия конкурсының «Профессиональ инженерлар» номинациясендә дә таныдылар. Елена Ткачева фән-технология үзәгендә 30 елга якын эшли. Бу вакыт эчендә ул әйдәп баручы инженер-технолог вазыйфасына кадәр күтәрелде. Елена Николаевна 3 уйлап табу патенты, 43 рационализаторлык тәкъдиме, фәнни конференцияләрдә яңгыраган 12 доклад һәм фәнни журналларда басылган 6 мәкаләнең автордашы булып тора. Хәзерге вакытта ул стироль пластикларның эре тоннажлы җитештерү процессын фәнни-техник яктан тәэмин итү буенча тикшеренү эшләре белән шөгыльләнә.

Елена Николаевна сәхнәгә чыккач, софитларның зәңгәр уты аның күлмәген мизгел эчендә янып торган сапфирга әйләндерде, менә хәзер сәхнә артыннан химикларның барысын да серле яктылыкка төрәчәк куе томан килеп чыгар төсле иде. Залда Елена ханымның тавышы яңгырый, ә аның артында бер-бер артлы көндәлек тормыш кадрлары алышына: лабораториядә тикшеренүләр, хезмәттәшләр белән аралашу мизгелләре һәм химик формула рәвешендәге хезмәт нәтиҗәләре. Балалар башкаруындагы шигырь һәм дәртле җыр ярдәмендә химик ханым тамашачыларга үзенең шактый катлаулы эшен гади тел белән белән аңлатып бирә алды. Конкурсның жюри әгъзалары аны «Һөнәрем – минем язмышым (Хатын-кыз җитештерүче)» номинациясендә бертавыштан җиңүче дип тапты һәм конкурсның Казанда узачак финал этабына чакырды.

– Ни өчен конкурста катнашырга булдыгыз?

– Минем эшем кеше күзенә күренми, ә көндәлек мохитем – лаборатория диварлары. Анда мин яңа продуктлар уйлап чыгарам, азык-төлек төрү материаллары һәм торак өчен панельләр өлкәсендәге технологияләрне камилләштерәм. Хезмәтемнең нәтиҗәсе белән кешеләрнең һәр көн файдалануы миңа илһам бирә, һәм әлеге хис-ниятләремне мин башкалар белән уртаклашырга телəдем.

– Номер әзерләү авыр булдымы?

– Сәхнәгә чыгу, шигырьләр уку, җырлау – минем өчен күнегелгән нәрсә түгел, әмма конкурс аркылы үземне көтелмәгән рольдә сынап карадым. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ профсоюз комитеты һәм җитәкчелеге, хезмәттәшләрем һәм якыннарым чыгышка әзерләнгәндә бик нык ярдәм иттеләр, көч биреп тордылар. Алар миңа ачылып китәргә булышты, ә номерны әзерләү-кую безне рухландырды һәм берләштерде, шуңа күрә, җиңгәнче үк, мин бик күңелле хисләр кичердем.

– Эштә дә, шәхси тормышта да гармониягә ирешүегезнең сере нидә?

– Хатын-кыз гаилә белән һөнәр арасында сайлап интекмәсен өчен, аларның икесен дә бертөрле яратырга тиеш. Шуңа күрә сер ихлас теләктә дияр идем: яхшы эшлисең икән, шул чакта уңышлар да киләчәк. Якыннарың белән дә нәкъ шулай ук, аларның күңелен күрәсең икән, нәтиҗәсе дә, ихтирам, ярдәме дә булачак. Әнә шул вакытта гына тормыштан киеренкелек тоеп түгел, ә һәр мизгеленнән канәгатьлек алып яшисең.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең гүзәлзатлары – хатын-кыз хезмәткәрләре җитәкчелек һәм профсоюз комитеты ярдәме белән «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсында күп еллар катнашып килә, кагыйдә буларак, үз номина-

Фото: Алёна Кутыркина

цияләрендә җиңүчеләр булып танылa. Шул рәвешле алар җитештерү эшендә һәм гаиләдә хатын-кыз статусын югарырак күтәрә.

ҖЫР БЕЛӘН ЯШӘП...

Әлфия Сибгатуллина «Хатын-кыз – ел үрнәге» номинациясендә лауреат булды. Ул кырык елдан артык «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖдә өлкән лаборант булып эшли.

Тормышта да, һөнәрендә дә үрнәк булырлык башка кешене күз алдына китерү дә кыен. Яшь кыз мәктәптә үк химия белән кызыксына башлый. Аннары әлеге мавыгу аның тормыштагы урынын билгеләде. Бүген Әлфия Әсхәдулла кызы һөнәри тәҗрибәсен яшь белгечләр белән уртаклаша, югары квалификациясе аңа аеруча катлаулы җайланмаларда эшләргә мөмкинлек бирә һәм шул ук вакытта ул зур тату гаиләне җыеп, тартып баручы зат та булып тора.

Әлфия Сибгатуллина чыгышының иҗади өлешендә аңа авылдашлары ярдәм кулы сузды, алар якташларына җыр җырлап булышлык күрсәтте. Түбән Кама Халык иҗаты йорты тамашачылары берничә минутка Әлфия ханымның туган ягы – Шәңгәлче авылы Сабан туена күчтеләр. Сәхнәдә яңгыраган дәртле татар җырына чын-чынлап биеп китәсе килә иде, конкурсантка якын ике яшь егет әнә шулай эшләде дә. Аяклар үзеннән-үзе тыпырдап тора, Әлфия җырлый да, җиңел генә әйләнеп биеп тә китә – мондый энергетикага эстрадабызның теләсә кайсы примадоннасы кызыгыр иде, залда бу аншлаг юкка түгел икән.

– Ни өчен конкурста катнашырга булдыгыз?

– Коллективта саллы эш стажым өчен генә түгел, ә кешелек сыйфатларым өчен дә хөрмәт итүләре миңа бик ошый. Балаларым да минем юлдан китте – КХТИ тәмамлап, тормышларын химия белән бәйләделәр. Эштә минем янда һәрвакыт тормыш кайный: яңа лаборантлар килә, мин алар белән аралашып-сөйләшеп торам, өйрәтәм, үземә дә көн саен нинди дә булса яңалык ачам. Компаниянең профсоюз комитеты мине «Ел үрнәге» номинациясендә катнашырга чакыргач, уйлап та тормый ризалаштым, чөнки бу – үз энергиям белән уртаклашу һәм ниндидер яңа нәрсәдә үземне сынап карауның тагын бер мөмкинлеге бит.

– Номер әзерләү авыр булдымы?

– Чыгышым бик лирик рухта, мин тормышым һәм эшем турында шигырь юллары белән сөйлим. Дус кызларым белән бергә туган авылыбыз турында татарча җыр башкарабыз. Номерның ахыры бик күңелле, ярдәмче биючеләр дә – менә дигән. Бераз дулкынландырды, әмма без күп репетиция ясадык, миңа ярдәм иткән һәркем әлеге эшкә күңеленең бер өлешен салды, бу исә бик зур ышаныч өстәде.

– Эштә дә, шәхси тормышта да гармониягә ирешүегезнең сере нидә?

– Үземдә шулкадәр көч-дәрт каян килгәнен белмим, табигатем белән дәртле кешедер инде мин. Эшсез ятуны, нидер көтеп утыруымны күз алдына да китерә алмыйм. Холкым хезмәтемә искиткеч туры килә, чөнки лабораториядә эш даими үзгәреп тора. Башта кәгазьләр тутырабыз, аннары анализ ясыйбыз, нәтиҗәләрне өйрәнәбез, йомгак ясыйбыз. Мин үз эшемне һәр көн яңалык белән тулы булганы өчен яратам, 40 елдан артык вакыт эчендә бер дә күңелсезләнергә туры килмәде. Уңай кәефем гаиләгә дә күчә, зур компания белән өстәл артында җыелу һәм якын кешеләремне яңа ризыклар белән сыйлау, аларның бәхетле елмаюларын күреп үзем дә сөенү миңа бик ошый.

ТАИФ компанияләр төркеменә кергән «Түбән Кама Нефтехим» компаниясенең нинди иҗади талантларга ия икәнен күрсәтеп, конкурсантлар жюрины да, үз предприятиеләрен дә сөендерде. Акционерлык җәмгыятендә 15 000 чамасы кеше эшли, шуларның 39% ы – хатын-кызлар. Уңышлы эш алып бару, һөнәрдә дә, иҗатта да үз-үзеңне табу, үстерү өчен предприятиедә аларга барлык шартлар да тудырылган.

Нәтиҗә буларак, «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсының «Һөнәрем – минем язмышым» номинациясендә фән-технология үзгәнен әйдәп баручы инженер-технологы Елена Николаевна Ткачева – «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ вәкиле чираттагы тапкыр җиңү яулады. Республиканың башка күренекле хатын-кызлары белән бергә Елена Ткачеваны Татарстанның беренче затлары да бүләкләде. Төрле номинацияләрдә җиңүчеләргә бүләкләрне Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм аның урынбасары Римма Ратникова тапшырды. Тантана Халыкара хатын-кызлар көне алдыннан Казанның С.Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында узды.

Быел иң яхшылар исеменә барлыгы 600 хатын-кыз дәгъва кылган иде, алар арасында югары даирә вәкилләре дә, күп балалы әниләр дә, эшмәкәрләр дә, үз тармакларында һәм бала тәрбияләүдә уңышка ирешкән төрле эшче һөнәр вәкилләре дә бар иде.

Тәвәккәл хуҗабикәләр

8 Март бәйрәмендә бөтен матбугат хатын-кызларга мәдхия укый. Бигрәк тә, шагыйрь язып калдырганча, дуамал айгырны иярләүдән һәм янган йортка керүдән курыкмаган кыю-тәвәккәл туташ вә ханымнарга дан җырлана. Һәм тагын, нигәдер, нәкъ менә ирләргә хас һөнәрләрдә уңышка ирешүчеләр – комбайнда эшләүчеләр, штанга күтәрүчеләр, космоска очучылар мактала... Әмма бер үк вакытта гаилә учагын саклау һәм балалар үстерү кебек хатын-кызлар өчен иң мөһим нәрсәләргә тиешле игътибар бирелеп җитми шикелле. Комбайнчы да, штангачы да, космонавт та – барысы да бала үстерә ич– кичләрен, ял көннәрендә, әниләр көнендә, ял вакытында, авырып ял алганда... Кем ничек өлгерә, кем ничек булдыра инде. Өлгерүен барысы да өлгерә, әлбәттә, чөнки шунсыз булмый.

«Татарстан» тапталган сукмактан йөрми. Ул үзе сукмак салырга ярата. Бу юлы гомерләренең иң мөһим эше гаилә булган чын хатын-кызларга кунакка юнәлдек. Бала чүпрәкләре белән күлмәкләре, ашарга әзерләү, өй җыештыру, дәресләр хәстәрләү, түгәрәкләр-секцияләрне истә тоту – болар кабатлана да, кабатлана... Безнең бу сандагы геройларыбыз – хуҗабикәләр. Бар эшкә дә осталар. Үзләренең яраткан һөнәрендә уңышка ирешүчеләр. Бүген алар «Татарстан» журналының өч төп соравына җавап бирә:

1

Ни өчен хуҗабикә һөнәрен сайладыгыз?

2

Гаилә бәхетенең сере нидә?

3

Гаиләгезне 20 елдан соң ничек күзаллыйсыз?

Фото: Ната Смирнова, Нәфисә Исмаилова, Гүзәл Басыйрова, Светлана Изамбаева архивларыннан

Нәфисә Исмаилова. Файда китерүче

Нәфисә исеме «кешеләргә файда китерүче» дигән мәгънәне белдерә. Бу турыда Нәфисә үзе өчен шундый тормыш девизы сайлаганнан соң гына борынгы мөселман исемнәре китабыннан укып белгән. Ул һәрвакыт кешеләргә ярдәм итәргә әзер. Менә хәзер дә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен үсеш студиясе ачу турында хыяллана. Анда теләсә нинди социаль статустагы сабыйлар бушлай йөрер иде. Нәфисәгә балалар белән шөгыльләнү ошый. Үзенекеләр белән дә, чит сабыйлар белән дә.

Фото: Ната Смирнова

1 Гомумән, мин балачактан ук очарга хыялландым. Очучы буласым бик тә килде. Бу хыялымнан хәтта сыйныфташлар да көлә иде: ничек инде кыз кеше очучы булсын ди?! Әмма мин бик үҗәт кеше. Гражданнар авиациясе институтын тәмамладым, авиация инженеры белгечлеген алдым һәм оча башладым – 24 ел стюардесса булып эшләдем. Эшем бик кызыклы иде, кияүгә чыгасым килмәде, соңрак бер чыгармын әле, дип уйладым. Булачак иремне очраткач та, аңа кияүгә чыгармын дип уйламадым әле. Тик шулай да өйләнештек, бер елдан кызыбыз туды, ул бераз үскәч, тагын эшкә чыктым. Алты елдан соң икенче кызыбыз туды. Тагын ике елдан – улыбыз. 2015 елда исә төпчегебез Анатолия дөньяга килде. Хәзер мин бала тәрбияләү белән мәшгуль – аларны укырга һәм спорт түгәрәкләренә йөртәм: зур теннис, йөзү, кызларны – биюгә, улымны – дзюдога. Баштарак миңа бала караучылар да, әнием дә булышты. Хәзер инде балалар үсте, үзем дә өлгерәм. Йорт эшләрен мин бик теләп башкарам. Савыт-сабаны да, керне дә машина юа, кызларым бар эштә булыша. Ашарга пешерергә яратам. Миңа ошамаган бернинди йорт эше дә юк, барысы да бик җиңел бирелә.

Гомеремне яңадан башларга туры килсә, мин кабат күкне һәм үземнең гаиләмне сайлар идем. Әбиемнең бер генә баласы булган – минем әнием. Ул һәрвакыт зур гаилә турында хыялланды, тормышта бертуганнарың ярдәмен тоюның никадәр мөһим икәнлеге хакында гел сөйли иде. Әнием белән мин аның хыялын тормышка ашырдык: без дә бишәү үстек, минем дә дүрт балам бар. Берничә сабыйның әнисе булу – ул искиткеч рәхәтлек бирә торган хис. Минем ирем дә балалар ярата. Ул ЦСКА хоккей клубында эшли, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен бушлай хоккей клубы төзергә хыяллана. Мин дә сабыйлар өчен кечкенә бакча-студия оештырырга телим, анда балалар бушлай шөгыльләнерләр иде. Балалар безне менә шундый эшләргә илһамландыра.

Миңа кешеләргә ярдәм итү ошый. Без бу дөньяга матди яктан да, физик яктан да булышыр өчен туабыз бит. Кемдер – хосписларга, кемдер – балалар йортларына, кемдер күршеләренә булыша. Бу – норма, безнең өчен куаныч. Миңа тагын уку, яңа белем алу, балаларны укыту, нәрсәгәдер өйрәтү ошый. Шунлыктан мин аларны түгәрәк-секцияләргә көн саен рәхәтләнеп йөртәм. Вакыты җиткәч, бу шөгыльләнүләр үз җимешен бирер, мин моны яхшы беләм.

Алавия, Ламис, Альдияр һәм Анатолия – балаларымның исемнәре шундый. Кечесен бабасы хөрмәтенә атадык. Калган исемнәрне «36 мең мөселман исеме» китабыннан сайладык. Ирем белән балаларыбызга матур һәм хөрмәткә лаеклы исемнәр кушарга теләдек. Һәм аларга лаеклы белем бирергә дә өметләнәбез.

2 Иң әүвәл бер-береңне хөрмәт итү зарур. Ярату – һичшиесез! Мин иремне җаным белән тоеп яратам. Ул бик яхшы кеше. Бик белемле, күп телләр белә. Бер-беребезне бик яхшы аңлыйбыз һәм ихтирам итәбез. Без инде күп еллар буе бергә һәм талашканыбыз юк. Бары бәхәсләшкәнебез генә бар – күп очракта балаларга кагылышлы мәсьәләләрдә. Җәмгыятьтә балалар хөрмәтен саклап калу кыен. Барысы да, ни өчендер, иң мөһиме – матди як, дип саный, мин исә балаларыма иң мөһиме – кеше, дип тәкърарлыйм. Шунлыктан һәркемне – сыйныфташыңны, укытучыңны яратырга һәм ихтирам итәргә кирәк, дип өйрәтәм. Бу кемнең гаджеты нинди бәядә булуга караганда мөһимрәк. Кешенең үзенең кадерен белергә кирәк. Башка бөтен нәрсәне сатып алып була, әмма акча ул – бүген бар, ә иртәгә юк, кеше исә һәрвакыт кеше булып кала. Чын дуска синең акчаң булубулмау мөһим түгел. Балаларымны шулай өйрәтәм. Минем улым беренче сыйныфта барысын да – кызларны да, малайларны да – ишекне ачып кертте, үзе иң арттагы партага утырды. «Әнием, син мине шулай өйрәттең бит», – ди. Һәрвакыт һәркемгә ярдәмгә килергә әзер. Аның белән горурланам.

3 20 елдан соң балаларымны яхшы белем алган, хөрмәтле кешеләр итеп күзаллыйм. Нинди генә һөнәр сайласалар да, яратып сайласыннар. Күз алдымда шундый манзара тора: барыбыз да бер табын тирәли җыелганбыз, балалар һәркайсы үз гаиләсе белән – безгә кунакка гына килгәннәр. Һәр бала аерым яшәргә тиеш. Һәр гаиләнең – үз аурасы, үз тынычлыгы, үз традицияләре, үз балалары. Әмма без барыбыз бергә – бер гаилә, бер ыру. Миңа ничә яшь булмасын, хәлемнән килгәнчә һәрвакыт булышачакмын. Аларның һәркайсы минем яраткан балам гына түгел, аларның һәркайсы минем өчен – изге. Миңа әни булып эшләү ошый. Әни булу бик кызыклы һәм искиткеч шәп. Көн саен балалар белән сөйләшергә, аларны кочакларга һәм үбәргә – ничә яшьтә дә аларга игътибар бирергә кирәк. Балаларыгызга телефонга кадалып кына утырырга рөхсәт итмәгез. Ешрак кочыгыз, сөйләшегез, шул вакытта бала телефонга үзе дә тартылмаячак.

Фото Нәфисә Исмаилованың шәхси архивыннан

Гүзәл Басыйрова. Иң сөйкемле һәм иң ягымлы

Гүзәл Галим кызы күптән түгел юбилеен билгеләп үткән. Ул бик матур һәм мөстәкыйль. Өстәвенә бик сөйкемле һәм мөлаем да. Аны белүчеләр гомере буе әни булып эшләде һәм, пенсиягә чыккач кына, һөнәрен... әбигә алыштырды, әнә шундый бәхетле хатын ул, дип санnetwork сanyйлар.

Фото Гүзәл Басыйрованың шәхси архивыннан

1 Мин «КАМАЗ»да санитария табибы булып эшләдем. Без шәһәр янында яшәдек һәм миңа өч балабызны мәктәпкә, аннары төрле түгәрәк һәм секцияләргә йөртү кыенга туры килә иде. Шунлыктан ирем мондый карар кабул итте: ул эшли, гаиләне акча белән тәэмин итә, мин исә бала тәрбияләү һәм белем бирү белән шөгыльләнәм. Шулай хуҗабикәгә әйләнүемне сизми дә калдым. Хәзер инде балалар үсеп җитте. Эльза исемле кызыбыз – Казан финанс-икътисад институтын, Лондонда магистратураны тәмамлады, хәзер кияүдә, Мәскәүдә яши. 11 айлык оныгыбыз Дамир бар.
38 яшемдә тапкан кече улым Нияз гимназияне алтын медальгә тәмамлады һәм, математика буенча Россия олимпиадасы призеры булып, Мәскәүдәге Югары икътисад мәктәбенә (МИЭФ ВШЭ) укырга керде. Быел бакалавриатны тәмамлый һәм ике диплом – Россиянеке һәм Британиянеке (Лондон университетында инглизчә укый) алачак. Балаларым бик булдыклы – барлык олимпиадаларда катнашып, гел җиңделәр! Алар әле тагын теннисчы да. Без гаиләбез белән зур теннис уйныйбыз. Улыбыз берничә тапкыр шәһәр чемпионы булды, республика турнирларында җиңде, хәзер үз университеты өчен уйный. Тенниска мәхәббәт этиләреннән күчте. Мин күбрәк мәктәп буенча белгеч. Мәктәпне тәмамлаганда улыбызга: Мәскәүдә укырга телисең икән, үз белемеңә таянсаң гына китәсең, дидек. Уку өчен түләү бик кыйбат бит. Һәм ул үзе, олимпиадада җиңүче буларак, бюджетка керде. Ул безнең бик максатчан егет. Әтисе кебек. Ирем Зөфәр Рәшитович озак еллар үзенең IT-компаниясен җитәкләде. Соңгы елларда «КАМАЗ»да IT-проектларга җитәкчелек итә. Ул булдыклы кеше - 2007 елда хәтта «Замандаш портреты. Татарстан» китабына да кертелде.

2 Мөгаен, берниндиис китәрлек яңалык та ачмамдыр: гаилә бәхетенең сере – үзара аңлашуда, сабырлыкта, үзеңнең хәләл җефетеңә яраклаша алуда, юл бирә белүдә. Һәм тагын, ничек кенә кыен булса да, елмаерга кирәк. Гаилә тормышында төрле хәлләр булырга мөмкин. Гәрчә миңа ирем белән беркайчан да кыен булмады. Ул бик тыныч һәм теләсә нинди хәлдә дә һәркемне тынычландыра ала.
Тагын әле гаиләнең уртак мавыгуы булырга тиеш. Без һәрвакыт балаларыбыз белән сәяхәт иттек – 23 ел эчендә 45 илдә булдык. Һәм гел музейларга, экскурсияләргә йөрдек. Нәкъ менә шундый сәфәрләрдән соң балалар тарих, география белән кызыксына башлый иде. Бергәләп театрларга, күргәзмәләргә, концертларга бардык. Хәзер инде алар үзләре безне Мәскәүгә театрларга чакыра. Күптән түгел Зур театрда «Жизель» балетын карадык, көз көне Кремль сараенда Хулио Иглесиас концертында булдык. Тау чаңгысы, сноуборд, урманда йөрү – болар барысы да балачактан ук гомер буена хәтергә сеңә.
Балалар, гаилә корганда, аны үз әти-әнисе мисалында төзи. Яки инде киресенчә – аларның ялгышын кабатламаска тырыша. Минем кызым үзенең булачак ире белән мәктәптә үк дуслашкан иде, без аның әти-әниләрен, яхшы гаиләдән икәнен белдек. Балаларыбызның бездән үрнәк алырлыгы бар, дип исәплим. Кызым гаиләсенә карыйм да, куанам – алар 6 ел буе очрашып йөрделәр, төрле шәһәрләрдә яшәп сыналдылар, әмма чын хис сүнми, дөрли генә бара бит. Мин дә иремне армиядән шулай сагынып көтеп алдым… Кайберәүләр күп бала табудан курка. Бернәрсәдән дә куркырга кирәкми. Без менә кризис чорында да яшәдек – барыбыз да исән калдык бит әле. Ирем: «Безнең бакчабыз бар, ничек тә ачтан үлмәбез, җаен табарбыз!» – ди иде. Ул минем бик позитив кеше!
Кызым да аңа охшаган, ире белән икенче, өченче бала турында да хыялланалар. «Балаларың булу – иң зур бәхет бит ул», – диләр. Гаилә бәхетенең сере менә нәрсәдә.

3 Тормышта барысы да кабатлана. Кайчандыр шулай булган иде инде: әти-әнием – укытучылар, без, өч кыз туган, өчебез дә табиблар. Гаиләләребез белән әти-әни янына кайта идек. Хәзер минем балалар да, туганнарымның балалары да Мәскәүдә яши. Безгә, Чаллыга, кунакка кайталар. Бәйрәмнәрне, озын ялларны, каникулларны бергә үткәрәбез. Әти-әнием исән чактагы кебек үк, зур, тату компания булып табын тирәсенә җыелабыз. Әлбәттә, якынрак буласы, ешрак очрашасы килә, балалар Мәскәүгә чакыра. Әмма безнең монда зур йортыбыз, зур кишәрлегебез бар, ирем алтын балыклар йөзә торган буа ясап куйды. Мин чәчәк үстерәм, утызга якын төрле розам гына бар. Ирем яшелчә үстерә. Ничек инде шундый гүзәллекне ташлап китәсең?! Әлегә беркая да китәсе килми. Бирегә яшибез, сәяхәт итәбез, чаңгы шуабыз, бакчабызда хозурланабыз һәм балаларыбызны, яраткан оныгыбызны гел кунакка көтәбез.

Светлана Изамбаева. Миссис Позитив

Светлананың ВИЧ инфекцияле хатын-кызлар арасында уздырылган «Мисс Позитив» бәйгесендә җиңүеннән соң байтак вакыт үткән инде. 14 ел эчендә ул үз чиреннән курыкмый һәм оялмый башлаган, зур гаилә корган һәм хәзер үзе кебек ВИЧ инфекцияле әниләр һәм бәбиләрне тормышка оптимизм белән карарга өйрәтә. Бүген ул үз гаиләсендә – «Миссис Позитив», тик аны ире, балалары, эте-песие генә түгел, ә ул киңәшләре, эшләре һәм шәхси үрнәге белән булышкан бөтен кеше дә ярата.

Фото Светлана Изамбаеваның шәхси архивыннан

1 Минем зур гаиләле буласым килә иде. Кимендә өч бала турында балачактан хыялландым. Үземнең зур гаиләмә ничек итеп ашарга әзерләвемне, бергәләшеп урманда йөрүебезне, чаңгы шууыбызны, зур табын тирәли кичке ашка җыелуыбызны күз алдына китерергә ярата идем... Бәлки үзем үскән гаиләдә мондый хәл булмагангадыр – без биш бала булсак та, әти эчкәч, моның турында хыялланырга гына кала иде шул...

Минем өчен гаилә – һәрвакыт беренче урында. Тик ВИЧ диагнозы белән яшәгәнгә, үзем турында да кайбер нәрсәләрне аңлау мөһим иде. Шунлыктан мин башкаларга ярдәм итү төркеме оештырдым, чөнки, башкаларга булышканда, син үзеңә дә булышасың. Беренче балам өч айлык чагында тупладым мин өемдә беренче төркемне. Икенче тапкыр йөккә узгач, әнием вафат булды. Балигъ булмаган ике энекәшемне балалар йортына урнаштырдылар. Әниемнең матәме вакытында ук иремне энекәшләрне үзебезгә тәрбиягә алырга күндергән идем инде. Тик миндә ВИЧ булгач, РФ законы буенча аларны асрамага алырга ярамый, диделәр. Ул чакта, 10 ел элек, судлар аша опеканы дәгъвалап алдым. Башта – бер энемне, аннары – икенчесен. Берсенә – 8, икенчесенә 10 яшь иде. Кечесендә ДЦП, ул урында ятып кына тора. Минем улым да өзлегеп туды. Мондый зур гаилә белән менә инде 10 ел яшим икән.

Хуҗабикә булсам да, иҗтимагый эшчәнлегем дәвам итә. Атнасына бер тапкыр ВИЧ диагнозлы авырулар белән очрашып сөйләшәм, үземнең шәхси мисалымда аларны хәсрәтле уйлар сазлыгыннан тартып чыгарырга тырышам. Әмма бу «эш» көнендә дә балаларымны игътибарсыз калдырмыйм. Иртән шалтыратып тикшерәм: алар көнегүләр ясарга тиеш, кич – бассейн. Якшәмбе исә без атта йөрибез. Ял саен тагын үзара ярдәм төркеме белән очрашам, тик бу көнне балаларым да минем белән бергә була. Башка балалар белән бергә алар уен бүлмәсендә уйнаганда, мин ВИЧ йоктырган хатын-кызларны балага вирус күчмәслек итеп йөккә узарга, йөклелек вакытында нинди дарулар эчәргә өйрәтәм, ни өчен имезергә ярамаганны аңлатам. Мин клиник психолог, травмо-терапевт һәм гештальт-терапевт, белмәмне күтәрәм, бертуктаусыз укыйм.

Балаларым, энекәшләремне карарга, чирләремне җиңәргә миңа урман, чаңгы булыша – без бергәләшеп табигать кочагында ял итәргә яратабыз. Юдинода яшибез. Балаларымның үсештә нигә артта калуын аңлар һәм аларга булышыр өчен, мин нейропсихологияне өйрәндем. Яхшы логопедка әйләндем – балалар начар сөйләшкәнгә, аларны белгечләргә йөрттем, үзем дә алар белән бергә барлык биремнәрне үтәдем һәм бу һөнәрне үзләштердем. Бөтен нәрсә минем хәлемнән килә. Барлык хатын-кызлар да шундый. Ир-ат берьюлы 15 эш эшли алмый. Ә хатыннар моны булдыра. Хатын-кыз күп куллы кебек. Мин моны хатын-кызлар клубында да күзәтәм... Һәркайсының башында берничә яшерен шкаф бар диярсең – әле монысын эшләргә кирәк, әле тегесен... Һәм хатын-кызның баласы күбрәк булган саен, башында компьютердагы сыман «эш өсталләре» саны да арта бара, аларның һәркайсының үз бурычы бар. Йорт хуҗалыгын алып бару – гаять зур хезмәт. Миңа җайлырак, чөнки бурычларым гел алышынып тора – бераз өй эчендә эшләп алам, аннары урамга чыгып китәм, шул арада каядыр барып кайтам... Иртәнге күнегүләр, аннары иртәнге аш. Балалар ашаган арада урында яткан баланың памперсын алыштырам, аны ашатам, аягын күнектерергә швед стенкасына бастырам. Шул арада башкаларын мәктәпкә озатам. Аннары төшке аш әзерлим. Мәктәптән кайткач, киемнәрне алыштырабыз да урманга китәбез. Кышын – чаңгыда, җәен – велосипедта.

2 Гаилә бәхетенең сере – үзеңнең бөтен барлыгыңны һәр адымда тоюда ул. Арыйм икән – ятып йоклыйм. Баллы ризык ашыйсым килсә – ашыйм. Иргә дә, балаларга да игътибар бирергә кирәк, әмма үзеңне дә һич онытырга ярамый. Гел юу-уу-үтүкләү турында гына уйлау гаилә бәхете түгел ул. Иреңне балалар белән аралашырга җәлеп итәргә, бергәләп әкиятләр укырга, сөйләшергә, әвәләргә, рәсем ясарга кирәк. Әгәр ир эштән арып кайткан икән, башта аңа ял итү мөмкинлеге бирү зарур. Аңа бәйләнмәскә, юк-бар сораулар белән аптыратмаска, теңкәсенә тимәскә кирәк. Бер дулкында булу мәслихәт. Ирнең кәефсез чагында җитди сөйләшү башламау хәерле. Тән, караш, эчке халәттәге билгеләрне танып, аңларга өйрәнү яхшы. Бер-береңне мәхәббәт белән тотыру, учакка гел утын өстәп тору зарур.

Миңа бәхет сере зур йорттадыр кебек тоела. Балаларыма уңайлы йорт һәм бәби турында хыялланам. Инде өченче тапкыр йөккә узарга әзерләнәм. Бернинди вак-төяккә бүленәсем килми. Үземнең беренче балаларым белән никадәр күп нәрсәне югалтуымны хәзер мин бик яхшы аңлыйм. Балага өч яшь тулганчы, әнисенең һәрвакыт янында булуы кирәк. Бу бик мөһим вакыт. Беренче балам туганда, миңа үз диагнозыма ияләнергә кирәк иде әле. Минем нәрсәдер дәлиллисем, башкаларга булышасым килде. Хәзер исә мин моңа мохтаҗ түгел. Миңа хәзер 38 яшь, миңа балалар белән шөгыльләнү бик ошый.

3 Әбием алдынгы сыер савучы иде. Аның сыерлары бөтен кешенекеннән күбрәк сөт бирде. Әбиемнең тырышып эшләгән өчен медальләре дә күп булды. Мин аларны караганда, ул миңа: «Менә, иртүк килеп, сыерларны ашаткач, алар күп итеп сөт бирә», – дип сөйли иде. Хәзергә кадәр аның киңәшләрен истә тотам һәм аларны үтәргә тырышам. 20 елдан соң миңа 57 яшь тулачак. Балалар инде үсеп җитәчәк. Кечесенә, тагын бер елдан туса, ул чакта 20 тулачак. Мин – әби. Өлкән балаларның инде үз сабыйлары бар. Минем зур йортым бар. Урман янында, күл буенда. Зур мунча. Мин биергә йөрим, бик шәп биим. Мин – бик көттә әби. Ял көннәрендә балаларым һәм оныкларым җыела. Кечесе әле үзебезнең янда. Ирем белән без барысын да каршы алабыз, мунча ягабыз, мин бик тәмле бәлешләр пешерәм. Балаларым гаиләләре белән бер-бер артлы мунчага бара. Себеркене дөрес итеп парлап, җиренә җиткереп, мин әле оныкларымны чабам. Без бергәләп сәяхәт итәргә яратабыз, һәм мин аларга әбиемнең сыерлары һәм медальләре турында сөйлим... Т



Гади генә шатлыклар

Әбиләр ничек үзгәрә 2

Республиканың Балык Бистәсе районындагы Картлар һәм инвалидлар өчен Корноухово интернат-йортында бәйрәм алды ыгы-зыгысы андагы күркәм затларның искиткеч матур булып үзгәрүенә сәбәп булды. Бу үзгәрешне профессиональ стилистлар, косметологлар, мода экспертлары, фотографлар тормышка ашырды... Образларның трансформациясе бу күңелле вакыйгада катнашучы ханымнарның үзләрен дә үзгәрткәндәй тоелды. Кемдер фотографиягә төшәргә һәвәс булып чыкты, кемдер безнең белән үзенең тормышны ярату серләрен уртаклашты: «Картаям, дип уйлама, кадерлем, бу уй үзе үк картайта»... Ә кемдер, елмаеп, үзенең көзгедәге чагылышы алдында уйга калды...

«Татарстан»ның традициясе буенча истәлеккә фото – махсус рамда һәм журналда – яз бәйрәмендә хатын-кыз өчен шуннан да яхшы нинди бүләк булырга мөмкин? Чөнки һәр ханымда үзенең матур һәм стильле фотосы булырга тиеш бит.

КАТНАШУЧЫЛАР
(Корноухово Картлар һәм инвалидар йортында яшәүчеләр):

Анна Зайцева

Нурзия Гарипова

Александра Канифатова

Рәмзия Хәкимуллина

Ирина Әдһәмова





БАР ХИКМӘТ – ЕЛМАЮДА

Анна Зайцева:

– Матур булып күренергә яратам. Мин элек тә буяна-ясана идем, чәчләремне дә һәрвакыт буяп-ясап йөрдем. Бүген дә калышмыйм! Мин бик яхшы гомер иттем. Өч ирем булды – барысы да әйбәт кешеләр. Аларның берсе капитан иде, моряк, ә мин – морячка! Корабльдә аш-су пешерүче булып эшләдем, бөтен командабызны ашаттым. Яхшы вакытлар иде ул. Әмма бүген дә тормышка сөенеп яшәргә тырышам, елмаер өчен сәбәпне һәрчак табарга була бит.

ГАДЕЛ ХЕЗМӘТТӘ ШАТЛЫК КҮП

Нурзия Гарипова:
– Авылда үстем мин. Фермада эшләдем, сыер саудым. Ә ничек тегә һәм бәйли идем! Шатлык һәр җирдә бар ул, аны гадел хезмәттә дә табып була.



ИКМӘКНЕҢ ХУШ ИСЕ БЕЛӘН НӘРСӘНЕ ЧАГЫШТЫРЫРГА МӨМКИН?

Александра Канифатова:

– Усал кеше беркайчан да тәмле икмәк пешерә алмый, диләр. Күпләр бу эштән курка. Авыр, диләр. Чыннан да шулай! Икмәк хуш исле булсын өчен, түземлек һәм яхшы күңеллелек кирәк. Ә минем ипи уңа иде.

СӘЛАМӘТЛЕК КЕНӘ БУЛСЫН – БӘХЕТНЕ ТАБАРБЫЗ!

Рәмзия Хәкимуллина:

– Шулай килеп чыкты инде, мин Картлар һәм инвалидлар йортына бик иртә – 23 яшемдә үк килеп эләктем. Язмышым шундый булды. Монда хәзер дусларым бар – мин кешеләрне яратам. Тагын сәламәтлекнең кадерен беләм. Аек акыл белән уйлый алуыма, кулларым-аякларым хәрәкәтләнүенә сөенәм. Дөрес әйтәләр: сәламәтлек кенә булсын, ә бәхетне табарбыз!

КИНО ҺӘМ АРАЛАШУ КӘЕФНЕ КҮТӘРӘ

Ирина Әдһәмова:
– Яхшы кино яратам! Ул елмайтырга да, кәефне күтәрергә дә сәләтле. Кызыклы кеше белән сөйләшкән кебек рәхәт була.

Журнал
ТАТАРСТАН
Татарстан
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
и история РКП(б)
ТАТАРСТАН

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

АМЕРИКАДАН КАЙТКАН ТАТАР РИЗЫГЫ

Татарның милли ризыклары турында сөйләшә башласак, табынны ит, бәрәңге, камырдан башка күз алдына китерүе кыен. Сүз дә юк, алда санап кителгән өч ризык безнең көндәлек туклану рационында һәрвакыт бар. Тик алардан башка да кичке аш әзерләп була бит. Әле нинди генә! Татарстанның атказанган артисты Айгөл Хәйри моны раслап күрсәтте.

«ИРЕМ ЯРАТКАНГА...»

Телефоннан сөйләшкәндә, Айгөл Америкадан алып кайткан бик тәмле ризык рецепты турында сөйләде. Ит белән баклажан салаты икән ул.

– Америкага баргач, бер татар ханымда яшәдек. Шунда ул ризыкны беренче тапкыр ашап карадым. Һәм гашыйк булдым. Хәзер ул безнең гаиләбезнең яраткан ризыгы, – диде.

Айгөл әлегә декрет ялында. Тормыш иптәше Салават белән кызлары Җәмилә (6 яшь) һәм Җәлилне (1 яшь) үстерәләр. Без килгәндә хуҗабикә фатирында үзе генә иде.

– Минем бүген – ял көнем, кызыбызны – каенанама, улыбызны үз әниемә җибәрдем, – диде.

Җырчының зәвык белән эшләнгән аш бүлмәсенә узабыз. Монда һәр нәрсә – үз урынында. Савыт-сабадан башлап өстәл-урындыкка кадәр зәвыклы, затлы. Айгөлнең өе дә нәкъ үзе кебек икән, дип уйлап куйдым.

Без килгәнче ул барысын да әзерләп өстәлгә тезгән иде.

– Бу салатны көзен дә бик еш әзерлим, – диде Айгөл. – Чөнки бакчада яшелчәләрнең мул вакыты. Хәер, кышын да пешерәм инде. Ирем Казахстаннан булганга, яшелчә ризыкларын бик яратып ашый. Алар чынлап та тәмле, җиңел, файдалы. Ул як халкының яшелчәләргә өстенлек бирүе, бәлки, анда аларның күпләп үсүе белән бәйледер.

Бактың исә, баклажан салаты борынгы рецепт икән. Ул Азия халык ашларында гына түгел, Америка татарларында да мәхәббәт яулаган. АКШ на милләттәшләребезнең кайчандыр Төркия, Япония кебек илләрдән күченеп килгәннәрен исәпкә алсак, әлеге ризыкның ни өчен дөнья буйлап таралганлыгын да бик яхшы аңларбыз.

Исеме салат булса да, Айгөл әзерли торган ризыкны кайнар килеш тә, суытып та ашарга мөмкин. Икенче аш урынына да бирергә була. (Ул турыда соңрак).

Җырчы, иң беренче эш итеп, суганны ярым түгәрәкләп турады. Аннан сарымсакны вак итеп бүлгәләде. Һәм, зур казанга сыек май агызып,

Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Лилиана Вәлитова

АЙГӨЛ ХӘЙРИДӘН БАКЛАЖАН САЛАТЫ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак (6 кеше өчен):

1. Баклажан – 5–6 данә (зурлыгына карап)
2. Сыер ите – ярты кило
3. Кишер – 2–3 баш
4. Суган – 1 баш
5. Татлы борыч – 2 баш
6. Сарымсак – 4–5 тырнак
7. Томат пастасы – 2 бал кашыгы
8. Сыек май – 100 мл
9. Тоз – ярты бал кашыгы
10. Кара борыч, кызыл борыч – тәменчә



чит илләрдә Татарстан исеменнән чыгыш ясыйсың. Бу бит үтә җаваплы эш... – дим.

– Әлбәттә, җаваплы. Гадәттә бик нык дулкынланам. Һәр барган илдә үзебезнең милләттәшләребез белән очрашу минем өчен сәхнәгә чыгып җырлау гына түгел, ә шул җыр-моңнар аша үзебезнең тарихыбыз, гореф-гадәтләребез белән уртаклашу да. Алар шундый ватанпәрвәр кешеләр. Сәхнәгә чыкканда күз яшьләремне көчкә тыям. Шуңа да милләттәшләребез белән күрешү минем өчен зур бәхет. Һәм нәкъ менә шул мизгелдә үземнең дөрес юлдан баруыма инанам.

– Кайларда булдың?

– Санап китсәң, бик күп инде... Казахстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Азәрбайҗан, Кувейт, Словения, Төркия, Швеция, Польша, Франция, Финляндия, АКШ, Колумбия...

Айгөл баклажанны турап бетерде дә казанга салды. Һәм татлы борычны озынча итеп кисә башлады. Җырчы ике төрле борыч алган: кызыл һәм сары.

– Мөһим түгел, сарысы да, кызылы да ярый, – диде хуҗабикә.

Айгөл борычларны шулай ук казанга салды. Яшелчәләрнең барысын бергә яхшылап болгатты. Аннан казанга тоз, төелгән кара, кызыл борычларны салып, янә бутады. Тагын әле томат пастасы да өстәде. Шулар барысы бергә бер сәгатьләп пешәргә тиеш икән.

– Әчкелт-төчкелт ризык була бу, – диде хуҗабикә. – Безгә килгән кунаклар аны һәрчак мактап ашый.

– Көндәлеккә нинди ризыклар әзерлисең? – дим Айгөлгә.

– Иртән һәрвакыт ботка ашыйбыз. Төрлесен пешерәм. Мисал өчен, кызыбыз Җәмилә сөтле дөге боткасы ярата. Ирем белән ясмык боткасы яратабыз. Гөмбә ашлары да пешерәм. Рационны гел төрләндерергә тырышам...

суган, сарымсакны салды. Алар кыза торган арада кишерне ярым түгәрәкләп турый башлады.

– Кулың кулга йокмый. Ризык пешерү синең өчен көндәлек эш ахрысы? – дим.

– Әйе. (Елмая). Гастрольләрдә булмаганда өч төрле төшке аш әзерлим. Һәм бу миңа бик ошый. Әнием дә бик тәмле пешерә. Аның гөбәдия, чәкчәк, пәрәмәчләрен ашап туеп булмый. Әнидән күреп мин дә бәлеш, өчпочмак кебек милли ризыкларыбызны хәстәрлим, анькына охшатырга тырышам. Ә менә кияүгә чыккач, Азия кухнясын өйрәнергә туры килде. Ни өчен дигәндә, ирем камырдан бигрәк, әчкелт, кырку ризыклар ярата. Алма-Ата шәһәрендә туып-үскән егет ул.

«КҮЗ ЯШЬЛӘРЕМНЕ КӨЧКӘ ТЫЯМ»

Айгөл казанны ачты. Суган белән сарымсак йомшап, саргаеп киткән иде. Шуның өстенә пешкән, «саламлап» туралган итне салды.

– Озакка китмәсен, дип, сез килгәнче итне пешереп, әзерләп куйган идем, – диде хуҗабикә. – Итне пешермичә, майда кыздырырга да була. Алай да әзерләгәнем бар. Тик пешкән ит белән ризыгыбыз йомшаграк, әйбәтрәк чыга дип күрәм.

Тураган кишерне салды. Аннан баклажанны урталай кисеп турый башлады.

– Айгөл, сине республиканың йөзе дип әйтергә дә буладыр. Төрле рәсми чараларда еш җырлыйсың,

«КАЗАНГА МУЗЫКАЛЬ ТЕАТР КИРӘК!»

Күпләр беләдер дип уйлыйм, Айгөл галим, язучы, публицист Әнвәр Хәйринең кызы. Әтисе 66 яшендә, яңа планнар, идеяләр белән янып йөргәндә, кинәт кенә вафат булды.

– Әтиемнең эшләгән эшләре бихисап күп иде. Яңа ачышлар, яңа планнар, дисеңме... Ни кызганыч, тормышка ашмаган эшләре калды. Үземне күпмедер дәрәҗәдә аның дәвамчысы итеп тә хис итәм. Озын көйләргә, борыңгы җырларга

мәхәббәтем нәкъ әтиемнән күчкән, дип әйтә алам. Шуңа сөенәм: әтиебез Җәмиләне күреп тәрбияләргә өлгерде. Үз үлемен сизгән кебек, бер минут буш вакыты булуга, Җәмилә белән уйнады. Иртә, кич дип тормый, аның белән урамга чыгып китә иде.

Алда әйтелгәнчә, Айгөл әлегә декрет ялында. Аңа кадәр Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә студентларга белем биргән. Шулай ук ул – консерваториянең опера студиясе солисты да. Күпләр тагын беләдер дип уйлыйм: җырчы 2012–2017 елларда Г.Камал исемендәге театрда эшләде. «Зәңгәр шәл» спектаклендә Мәйсәрә ролен башкарды.

– Казанга музыкаль театр кирәк, – диде Айгөл. – Консерватория ел саен дистәләгән талантлы татар егет-кызларын чыгара. Аннан алар нишләргә белми аптырап йөри. Без Казан дәүләт консерваториясенең опера студиясендә музыкаль комедияләр, опералар куеп карадык: «Башмагым», «Кара пулат» – халык бик теләп йөрде. «Башмагым»ны Салих Сәйдәшев исемендәге зур концертлар залында да куйдык. Ләкин анда сәхнә арты да, оркестр чокыры да юк. Декорацияләр, реквизитлар барысы да шартлы гына иде. Үзебез ничек булдыра алдык, шулай җиһазладык. Шуңа күрә, махсус зал булмый торып, музыкаль театр эшләү бик авыр. Анда бит акустика да бик зур әһәмияткә ия. Музыкаль театр сәхнәсе таләп итә торган тагын бик күп нечкәлекләр бар. Декорацияләрне кинәт кенә алыштыру, әйтик, бер яссылыктан икенчесенә күчерү мөмкинлекләре һ. б.лар. Әгәр үзебезнең монументаль бинабыз булса, күпме җырчылар, композиторлар, дирижерлар, режиссерлар, оркестрлар үзләрен шунда сыный алырлар иде. Бик кызганыч… Безнең бит шундый уйныйсыбыз, классикларыбыз калдырган мирасны хәзерге буынга җиткерәсебез килә. Бүтән шәһәрләргә барып, заманча техника белән җиһазланган биналарны күргәч, чын күңелдән кызыгып кайтабыз…

«КАЗАНДА ЯШӘРМЕН ДИМӘГӘН ИДЕМ...»

Әнә шундый шактый җитди темаларга сөйләшеп торган арада казан турында оныта да язганбыз. Айгөл, урыныннан сикереп торып, плитә янына йөгерде.

– Төбенә утырмасын!

Хуҗабикә яшелчәләрне кашык белән баскалап карады.

– Иң мөһиме: кишер белән татлы борыч каты булмасын, калганнары аның пешә инде, – диде.

Җырчы бу салатны кичтән ясап куя икән. Иртәгәсен генә ашыйлар.

– Хәзер Салават кайтып җитә. Токмач та пешереп алыйм әле, туклыклырак булсын, – диде Айгөл.

Бактың исә, токмачны аерым пешереп, өстенә әлеге баклажан салатын салсаң, шулпасыз лагман була икән.

– Пеште, әзер, – диде Айгөл һәм казанны уттан алды. Аш бүлмәсенә борыч, яшелчәләрнең татлы исләре таралды.

Ул да түгел, ире Салават кайтып керде.

Салават Табаев дигән исем җыр дөньясындагы кешеләргә яхшы таныш. «Моң» мәктәп-студиясе һәм продюсерлык үзәген оештырган музыкант, җырчы-башкаручы ул. Айгөлнең музыкаль продюсеры булып та санала. Салават – филолог, культурология белгече, белемле, фикерле кеше. Белеме буенча телче булса да, тормышы гел музыка белән бәйле булган икән. Хәзер дә шулай.

– Профессионаллар юк… – диде Салават. – Дөресен генә әйткәндә, мин Казан турында югарырак фикердә идем. Ләкин безгә моң, белем, зәвык кебек төшенчәләр җитешеп бетми. Айгөлне очратмаган булсам, мөгаен, биредә яшәмәс тә идем…

Мин исә керфек астыннан гына Айгөлне күзәтәм: ире сөйләгәндә ник бер сүз кыстырып карасын. Татар хатыннарына хас булганча, тыныч кына табын әзерләп йөрде.

– Әйдәгез, рәхим итегез! – дип, барыбызны да табын артына чакырды. Авыз итәбез… Нәкъ лагман! Төелгән кызыл борыч белән сарымсак – әчкелтем, ә татлы борыч баллырак тәм биргән бу сыйга. Менә шулар кушылмасы аппетит уята һәм экзотик төсмер өстәгән дә.

– Америка татарлары бу салатка бер чили борычы да сала, – диде Айгөл. – Мин алай эшләмим, авызны яндыра торган була. Без бит ул кадәр зәһәр ризык ашарга өйрәнмәгән.

Зыялы, зәвыклы кешеләр янәшәсендә менә шундый кичке аш булды. Дөресен генә әйткәндә, ризыкка болай «гашыйк булганымны» хәтерләмим. Миңа калса, һәр хуҗабикәнең аш-су дәфтәренә теркәлергә лаеклы рецепттыр ул!

1. Ваклыйбыз!

2. Турыйбыз!

3. Агызабыз!

4. Салабыз!

5. Кушабыз!

6. Салабыз!

7. Кисәбез!

8. Өстибез!

9. Турыйбыз!

10. Кушабыз!

11. Ваклыйбыз!

12. Салабыз!

13. Болгатабыз!

14. Өстибез!

15. Кушабыз!

16. Табынга бирәбез!

facebook.com/protatarstan

Реклама 16+

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Беренче бишьеллыклар республика йөзен **НИЧЕК** үзгәрткән

Күмәкләшү өчен **НИНДИ** бәя түләнгән

Беренче татар опералары **КАЙДА** туган

Әдәбиятның соңгы морзасы **КЕМ**

Лашманчылар **КАЙДА** төпләнгән

КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ МӘШҺҮР ХАТЫННАРЫ: **СӨЕМБИКӘ**

Татар тарихында дәүләт башлыгы булып торган бердәнбер хатын-кыз, Сөембикә-ханбикә, халкыбыз хәтерендә бүгенгә көнгәчә каһарманлык, ватанпәрвәрлек, иманга тугрылык сыйфатларын чагылдыручы символ рәвешендә кабул ителә. Аның турында күпсанлы легенда һәм риваятьләр, бәет һәм җырлар иҗат ителгән. Сөембикә образы шигърияттә һәм проза әсәрләрендә, рәссамнәр һәм сынчылар иҗатында урын тапкан. Әлеге образ сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗат итүче осталарыбызны бүген дә илһамландырып тора. Чөнки аның язмышы тарихыбызның бәхетле мизгелләрен дә, кайгы-хәсрәтләрен дә, киләчәккә юнәлдерелгән өмет-хыялларын да – барысын да сыйдырган.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Түбән Идел белән Җаек (Урал) елгалары арасында, хәтта тагын да ераграк – Арал диңгезенә кадәр сузылган иксез-чиксез далаларда нугай кабиләләре күчмә тормыш алып барган. Алтын Урда таркалган чорда нугайлар дәүләт булып оешалар. Хакимнәре – Идегәй нәселеннән чыккан бәкләр, морзалар. Җаекның түбән агымында, Каспий диңгезенә килеп җитәрәк бер урында барлыкка килгән Сарайчык аларның башкаласы була. Нугайлар Казан ханнары белән тыгыз элемтәдә торган. Алар арасында никах бәйләнешләре дә гадәти хәлгә әверелгән. Башта Тимер бәкнең кызы Нурсолтанны Хәлил ханга кияүгә бирәләр. Аның вафатыннан соң Нурсолтан, борынгы йола буенча, Ибраһим ханга кияүгә чыга. Мөхәммәд Әмин Муса бәкнең кызы Фатыймага өйләнә. Муса бәкнең олы улы Йосыф морза – Сөембикәнең атасы.

Танылган дин белгече һәм тарихчы галим Ризаэддин Фәхреддин фикеренчә, Сөембикә 1519–1520 еллар тирәсендә туган. Гомер

буе дала-кырларда, табигать кочагында көн күргән нугайларның асыл сыйфаты – бернәрсә белән дә чикләнмәгән азатлыкка, иркенлеккә, мөстәкыйльлеккә омтылыш. Бу сыйфат аларга ата-бабадан килгән. Сөембикәнең дә иркенлек вә азатлык сөюе, гомер буе беркемгә дә буйсынырга теләмичә яшәве – туган халкының холкы-табигате чагылышыдыр.

СӨЕМБИКӘ ҺӘМ ҖАНГАЛИ

Элек-электән ил башында торучылар кызларын-улларын шундый ук дәрәҗәгә ирешкән кешеләрнең балалары белән никахлаштырырга омтылган. Үзенә күрә бер сәясәт булган ул: хакимнәр туганлашкан, димәк, алар идарә иткән ил-дәүләтләр арасында сугышлар булмаган, тынычлык, дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнашкан.

1531 елда Казан тәхетенә Мәскәү тәкъдиме белән Касыймнан килгән 15 яшьлек Җангалине утырталар. Ул – татар тарихына бары тик тискәре шәхес, сатлыкҗан буларак кына кереп калган Шаһгалинең бертуган энесе. Икесе дә – Шәех-Аллаһияр малайлары, әниләре Шаһисолтан – нугай бәге Ибраһимның кызы. Аңлашыла ки, урыс кенәзләре туендырып торган Касыйм ханнары Казан мәнфәгате өчен көрәшмәгән, Мәскәү ягын кайгырткан.

Җангали дә шундыйлардан була. Ул Казан тәхетендә бераз утырып алган абыйсының сүзеннән чыкмый. Мөстәкыйль сәясәт алып бару өчен әле яшь тә була җитмәсә. Ә Мәскәү кенәзе бик мәкерле эш йөртә. Аның максаты бер: Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән ханлыкларны үзенә буйсындыру. Мәскәү Касыймнан китереп утыртылган Җангали аша Казан белән үзе теләгәнчә идарә итә алачак. Әгәр дә аны берәр нугай сылуына өйләндереп тә куйсаң? Әйе, Казан аша Нугай Урдасына да юл салырга мөмкин. Ә нугайлар Кырым ханнарын үз итмиләр, гел сугышып торалар. Мәскәү өчен ике туганны сугыштыру файдалы ич! Үсмер кыз, гүзәлләрнең гүзәле Сөембикә үзе боларны әлегә белми, әлбәттә. Әмма аның язмышы шул сәясәт белән турыдан-туры бәйле булачак.

1533 елда Җангалине Йосыф бәк кызы Сөембикәгә өйләндерү мәсьәләсен хәл итәр өчен Мәскәүгә махсус илчеләр китә. Эш уңай юнәлеш ала. Шул ук елны никах һәм туй мәҗлесе үткәрелә. Сөембикә өчен бөтенләй яңа тормыш башлана. Казан – гүзәл, бай кала. Биек таш йортлар, манаралары күккә ашкан мәчетләр. Хан сарае һәм адым саен аны баш иеп сәламләүче сарай әһелләре. Әмма Сөембикә үзен ялгыз хис итә. Ул бик күзәтүчән, үткен, эшнең асылына тиз төшенүчән бикә. Беренче күрүгә үк Җангалине ошатмый – хыялындагы егеткә һич тә туры килми ул. Казан тиклем Казанның ханы бик тә горур, һәр сүзен үлчәп сөйли торган, акыллы һәм... кул астындагы түрәләрнең котын алып торырлык гайрәтле һәм каты куллы ир булырга тиеш бит, югыйсә. Ә Җангали – беркатлы һәм җебегән бер кемсә. Йомшак холыклы. Үз шәүләсеннән үзе куркып йөри. Сарай түрәләре арасында барлыкка килгән капма-каршы төркемнең үзара көрәшен дә күрми, күрсә дә – аңламый. Дошманнары көннән-көн артып тора. Әнә, хөкүмәт башында торучы Гәүһәршад һәм аның яраннары Булат Ширин белән Табай бәкләр ни генә кыланмый! Аларның һәркайда сүзе үтә, чынбарлыкта ил белән хан түгел, алар идарә итә. Ахыры хәерле булмастыр моның. Җангалинең ил-дәүләт өчен бер файдалы гамәл кылганы юк. Кыла да алмас, чөнки Мәскәү ни кушса, шуны эшләп ята. Ул Казан тәхетенә лаек түгел.

Шулай булып чыга да. 1535 елның 25 сентябрендә Казансу буенда Җангалинең үле гәүдәсен табып алалар.

СӨЕМБИКӘ ҺӘМ САФАГӘРӘЙ

Җангалинең фаҗигале үлеменнән соң, Казан тәхетенә яңадан Сафагәрәйне чакыралар. Бу вакытта аңа 26 яшь була. Өйләнгән, дүрт хатыны бар. Сафагәрәйгә



Казан түрәләре иреннән тол калган Сөембикәне димлиләр. Йола шулай куша. Ата-бабаларының гореф-гадәтен белгән Сөембикә моңа күңеле белән әзер була, ризалыгын бирә.

Сөембикә белән Сафагәрәйнең саф мәхәббәте легендаларга кергән. Ул мәхәббәт беренче күрешүдән үк башлана һәм аларның соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. Сафагәрәй бар яклап та Җангалинең киресе булып чыга: кыю һәм тәвәккәл, табигать биргән акылы бар, үз сүзен сүз итә алырдай көчле рухлы, гайрәтле ир. Тагын бер өстенлеге: ул Мәскәүдән еракта туып үскән һәм тәрбияләнгән. Җангали кебек Мәскәү патшалары өчен җан атмый, Казан халкы өчен тырыша.

Сафагәрәйнең икенче идарә чоры шактый уңышлы башлана. Казанның югары катлау әһелләре йогынтысында ул Мәскәүдән дә, Кырымнан да бәйсез сәясәт корырга омтыла. Ләкин Мәскәү хөкүмәте Казанга дәгъвасыннан баш тартмый. Хәер, Кырым ханы да Казан җирен үзенеке дип саный. Сафагәрәй рус җирләренә яу чаба, Түбән Новгород, Муром, Кострома тирәсендәге шәһәр-авылларны туздырып ташлый. Мәскәүдә бу вакытта инде тиздән «Явыз» кушаматын алачак Иван IV идарә итә. Җавап йөзеннән ул да сугышка әзерләнә башлый, Казанның Мәскәүдән элеккеге – Мөхәммәдәмин һәм Җангали чорындагы бәйлелеген кайтарырга ниятли. Кырым ханы Сәхибгәрәй – Сафагәрәйнең абыйсы – бу хәлләрне ишетеп, Мәскәүгә хат яза, Иван IV Казанга сугыш белән килгән очракта, рус җирләренә басып керәчәген әйтә. Бу шартларда Сафагәрәй Кырым яклы булырга карар итә. Кырымнан чыккан кешеләрне үз тирәсенә туплый, казанлыларга ышанып җитми.

Казан түрәләре тагын үзләренең кемлекләрен күрсәтеп алалар – Сафагәрәйгә каршы астыртын көрәш башлыйлар. 1541 елда хөкүмәт башында торучы Булат Ширин Гәүһәршад ризалыгы белән Мәскәүгә илчеләр җибәрә. «Мәскәү патшасы Казанга үзенең гаскәрен җибәрсен, бергәләп кырымлыларны куарбыз, Сафагәрәйне кулга алып, сезгә тапшырырбыз», – дип белдерә илчелекнең башлыгы Чабык морза. Сугыш әлегә булмый кала, чөнки Мәскәүнең үзендә хәлләр катлауланып китә. Мәскәү яклы, үзенә каршы торучы Казан түрәләренә Сафагәрәй каты бәрелә: кайберләрен җәзалап үтертә һәм, бер документта язылганча, «күп кенә кенәзләрнең мал-мөлкәтләрен талап ала, ул байлыкны Кырымга озата».

Әкренләп тынычланалар. Мәскәү дә вакытлыча комачауламый. Сафагәрәйнең Казан өчен нык торуын, аның кырыс холкын сизеп алганнардыр, күрәсең. Әмма бу тынычлык озак дәвам итми. Кырымнан килгән түрәләрне үз янына туплаган Сафагәрәйнең эчке сәясәте күпләрдә ризасызлык тудыра. Казанлылар тагын бер хыянәткә баралар: 1545 елда Иван IV галиҗәнапларына мөрәҗәгать итеп, аннан Казанга яу белән килүен сорыйлар. Яу белән чынлап та килаләр, тик ул уңышлы булмый. Бу хәлгә ризасызлык белдереп, Казан морзалары ханга каршы үзләре корал күтәрә. 1546 елның гыйнварында Сафагәрәй – Кырымга, Сөембикә исә атасы янына, Нугай Урдасына качып китәргә мәҗбүр була.

Тәхеткә яңадан Шаһгали утыра. Күпкә түгел, чөнки халык ризасызлык күрсәтә. Беләләр ич кем икәнен. Сафагәрәй дә тик ятмый, берничә айдан соң яхшы гына коралланган нугай гаскәрләре белән Казанга кайта. Бернинди каршылыксыз кабул итәләр. Тормыш әкренләп үз җаена керә. Шатлык өстенә сөенеч дигәндәй, тиздән хан белән ханбикәнең көтеп алган уллары туа. Сабыйга Үтәмеш Гәрәй дип исем кушалар.

Шулай язгандыр инде: Казан тагын тузгытып ташланган кырмыска оясын хәтерләтә башлый. Гаеп, кем әйтмешли, атта да, тәртәдә дә була. Сафагәрәй, элеккеге сәясәтен дәвам итеп, җирле түрәләрне кыерсыта, иң мөһим дәүләт урыннарына Кырым кешеләрен билгели. Аңа каршы торучылар йә һәлак булалар, йә Мәскәүгә ка-

чып котылалар. Иван патшадан янә Казанга яу чабуын сорыйлар. Яу оештырыла, әмма көтелгән нәтиҗәне бирми. Сафагәрәй аптырап кала. Ничек инде шулай? Ул, барлык көчен җыеп, Казан иленең мөстәкыйльлеге өчен тырыша, урыс патшасына баш иярга теләми, мондагылар исә капма-каршы сәясәт алып баралар.

1549 елның мартында Сафагәрәй үтерелә. Аңа әле кырык яшь тә тулмаган була.

СӨЕМБИКӘ ҺӘМ ҮТӘМЕШ ГӘРӘЙ

Сөембикә һич көтмәгәндә ике яшьлек улы Үтәмеш Гәрәй белән тол кала. Ләкин ул үзен тиз кулга ала. Казан халкын билгесезлектә калдырырга ярамый, җебеп төшмәскә, тәвәккәлләргә, кыю адымнар ясарга кирәк! Мәрхүм иренең васыяте һәм ата-бабадан калган йола буенча хан тәхетенә Үтәмеш Гәрәйне утырталар. Үсеп балигъ булганчы, аның исеменнән Сөембикә үзе идарә итеп торачак. Тиз арада яңа хөкүмәт төзелә, җитәкчесе итеп Сафагәрәй белән бергә Кырымнан килгән хан гвардиясе башлыгы Кошчак углан билгеләнә.

Ханбикәнең дәүләт хезмәтендәге тәүге адымнары түрәләр арасында бераз тынычлык урнаштырыр кебек иде. Тик кая ул! Үтәмеш Гәрәйнең тәхеткә утыртылуыннан риза булмаган түрәләр хакимият өчен көрәшне туктатмыйлар. Сафагәрәйнең Кырымдагы өлкән улы Булат Гәрәйне хан итеп куярга сорап, Бакчасарайга илчеләр җибәрәләр. Сәхибгәрәй, Сөембикә яклы булгандыр күрәсең, ризалыгын бирми. Мәскәү патшасы да тик ятмый. Казанны тулысынча буйсындырырга форсат килде, дип, Явыз Иван хәлиткеч сугышка әзерләнә. Сөембикә тарафыннан солых белән Мәскәүгә җибәрелгән илчелек уңышка ирешә алмый. 1550 елда Казанга зур һөҗүм ясала. 1551 елда Иделнең аргы ягында, Зөя тамагында, рус крепостена нигез салына. Шул тирәдәге халыкны, татарын-чирмешен, Мәскәү патшасына тугрылык сакларга ант иттерәләр.

Сөембикә югалып калмый. Казан халкы белән киңәш тотып, саклану чараларына керешә. Шәһәр ныгытмалары яңартыла. Корал җитештерүче остаханәләрдә көне-төне эш кайный. Әмма хәлләр катлаулана бара. Халык арасында Кошчак белән Сөембикә, Үтәмеш сабыйны юк итеп, тәхетне үз кулларына алмакчылар икән, дигән коточкыч ялган хәбәр тараталар. Нахак гаепләүләргә түзеп тора алмыйча, Кошчак хатынын, ике баласын һәм энесен ияртеп, өч йөзләп гаскәре белән Казаннан чыгып качарга мәҗбүр була. Чулманга җитәрәк, качакларны куып тоталар, исән калган кырыклап кешене, шул исәптән Кошчак угланны да, әсир итеп Мәскәүгә озаталар, барысын да җәзалап үтерәләр.

Сөембикә ялгызы кала. Яңа хөкүмәт сайлана. Аның әгъзалары тарафыннан Зөя каласына, русларга, Колшәриф җитәкчелегендә илчелек җибәрелә. Максатлары – бернигә карамастан, Казанны рус баскыннарыннан саклап калу. Ике арада солых төзелә. Аның бер шарты буенча, Сөембикәне һәм аның улы Үтәмеш ханны, әсирлеккә төшереп, Мәскәүгә озаталар. Бу 1551 елның август аенда була.

СӨЕМБИКӘ ҺӘМ ШАҺГАЛИ

1552 ел фаҗигасеннән соң Казан ханлыгы яшәүдән туктый, аның җирләре Мәскәү дәүләтенә кушыла. Шаһгали сугышчылары белән Мәскәүгә кайтып китә. Явыз Иван Сөембикәне Шаһгалигә көчләп кияүгә бирә.

Йосыф бәк әле Сөембикәне Мәскәүгә алып киткәнче үк аңа ярдәм кулы сузарга омтыла, кызын һәм оныгын әсирлектән коткарып калу максаты белән ике тапкыр үзенең гаскәрен Казанга җибәрә, әмма ике тапкырында да уңышсызлыкка очрый. Тиздән Йосыф бәк белән Явыз Иван арасында хат алышу башлана. Мәскәү патшасыннан Йосыф бәк бары тик бер нәрсәне генә гозерләнеп сорый: азат итсен ул Сөембикә белән Үтәмеш сабыйны тоткынлыктан, кайтарып җибәрсен икесен дә атасы янына, Нугай далаларына. Хатлары катгый һәм ачулы була. Бик тә гадел һәм үтәү өчен җиңел таләпләр югыйсә. Иван патша Йосыф бәккә, һич тә борчылма, Сөембикә оҗмахта яши, тормышыннан бик канәгать, дип, матур-матур, ләкин асылда чеп-чи ялган җавап хатлары яза.

Ә Сөембикәнең башында бер уй: ничек яшәргә? Нишләргә? Ире белән – алыш-биреше, эч серләрен бушатырлык ахирәте юк. Ул ялгыз. Көннәр, атналар буе берни дәшми яшәвен белә. Әгәр дә моны яшәү дип әйтергә ярaса, билгеле. Тиздән Мәскәүдән коточкыч хәбәр килеп ирешә: сабыен чукындырганнар, Александр дип исем кушканнар. Киләчәккә соңгы өмет тә сүнә. Яныр-көеп яшәүнең мәгънәсе калмый. Соң чиккә җиткереп мәсхәрәләнгән Сөембикә күзгә күренеп сула, саргая, ашаудан кала һәм, яшәү газабын кичерә алмыйча, 1557 елда якты дөнья белән хушлаша. Бу вакытта аңа нибары 38 яшьләр чамасы гына була.

«Татарстан» журналының махсус проекты

«БУЫННАР»

Бер елдан бераз гына артык вакыт калып бара: тиздән Татарстан Республикасына 100 яшь тула. Түгәрәк һәм әһәмиятле юбилей – гасыр гына түгел, тарихның бер чоры! Республиканың адашы һәм аның игезәк туганы – «Татарстан» журналы уртак юбилей датасына махсус «Буыннар» проектын әзерләде, ул анда безнең Татарстаныбызның зур тарихын язган кешеләр турында сөйли.

«Буыннар» проектының беренче чыгарылышында без узган йөзьеллыкның 20 нче елларында Татарстан тарихын башлаган кешеләр һәм вакыйгалар турында сөйләгән идек инде*. Бүгенге язмабыз – 30 нчы елларга караган буыннар турында. Гомерләре бөек парадокслар вакытына туры килгән кешеләр турында. Искиткеч энтузиазм һәм каттый репрессияләр, индустриальләшү төзелешләре һәм ГУЛАГ концлагерьлары, стахановчылар хәрәкәте һәм оятсыз шикаятьләр, күмәкләшү һәм җир хуҗаларын массачыл рәвештә үз ватаннарыннан куу чорында яшәгән кешеләр алар. Ул чорда яшәгәннәрнең күбесе үзләре һәм киләчәк буыннар өчен яңа бәхетле тормыш төзүләренә ихластан ышанган, күбесе бу ышанычларыннан соңгы сәгатьләренә кадәр, хәтта НКВД диварлары эчендә дә аерылмаган...

Бу бөек экспериментта агымы, карасымы, – нәрсәнең өстен чыгуы турында хөкем карары чыгарырга ашыкмыйбыз. Вакытны сайлап алмыйлар – безнең ата-бабаларыбыз, үзләренә нинди гомер тигән булса, шуны яшәгәннәр. Үз бәхетләре һәм борчулары белән. Һәм киләчәк буынга һич кенә дә көчсез ил тапшырып калдырмаганнар.



* «Татарстан», №7, 2018.

БЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫКЛАР БУЫНЫ

Узган гасырның 30 нчы елларында нәрсәләр барлыкка китерелгән һәм нәрсәләр җимерелгән? Зур тарихта нинди кешеләр үз эзләрен калдырган да гаилә архивлары гасырның нинди «билгеләрен» саклый?

1 нче ТАРИХ

ВАКЫТ, АЛГА!

Индустриальләшү республиканы ничек үзгәрткән

2 нче ТАРИХ

ӘЙДӘ, ИПТӘШ, БЕЗГӘ – КОЛХОЗГА.

Күмәкләшү өчен нинди бәя түләнгән

3 нче ТАРИХ

ПРОЛЕТАРИАТ ДИКТАТУРАСЫ ӨЧЕН АРИЯ.

Татар операсы ничек туган

4 нче ТАРИХ

ЯҢА ТОРМЫШ ТӨРЛЕЛЕГЕ.

Татарстан Язучылар берлеге нинди планнар корган

Фото: ТР Милли музей архивыннан алынды

ЭШЧЕЛӘР ҺӘМ КРЕСТЬЯННАР ДӘҮЛӘТЕН НЫГЫТУ

Төрле вакытта Татарстанга күп төрле сәяхәтчеләр килгән, алар Казанны һәм аның әйләнә-тирәсен төрлечә тасвирлаган: кем – картиналарында, кем – шигырьләрдә, кем – прозада, кем – фотографияләрдә, кайберәүләр яхшы сүз белән генә дә... Шуларга нигезләнеп, без, әйтик, шәһәребезне XIX гасыр гравюраларында – инглиз рәссамы Эдвард Турнерелли күзләре белән, ә XX гасырның 30 нчы еллары фотографияләрендә – Америка профессоры Франк Уитсон Феттер карашы аша күрә алабыз... Ә Казанның никадәр күренешләре һәм вакыйгалары Татарстан Республикасының Милли Музее архивларында саклана!

Бүген безнең «Буыннар» проекты турыдан-туры шушы архивлардан узган йөзьеллыкның 30 нчы еллар фотографияләре белән тулыланачак. Нәкъ шушы елларда ТАССР үсә, нәкъ шул вакытта ил һәм республика тарихында күмәкләштерү, индустриальләшү, специальләшү кебек дигән яңа сүзләр һәм төшенчәләр барлыкка килә.

Димәк, артка борылып карыйбыз. Хәзерге вакытта бөтен дөньядан туристлар килергә омтылган шәһәребез 70 ел элек нинди булган соң?

Казан. «Авиастрой». М.И. Калинин төзелеш мәйданында (1930 нчы еллар).

Казан. Кинофабрика төзелешендә Каюмов иптәшнең ташчылар удар бригадасы (1930 нчы еллар).

Казан. Мех комбинаты төзелеше (1930 нчы еллар).

Казан. 4 нче номерлы Синтетик каучук заводы төзелеше (1930 нчы еллар).

Казан. Ленин исемендәге Культура сарае урнашкан Казансу ярларын төзекләндерү.

Казан. Лобачевский урамын төзекләндерү.

Лаеш районының «Кызыл җирбиләүче» колхозы. Язгы чәчү вакытында бригадалар һәм звенолар арасында социалистик бәйгеләр уздырыла торган була.

Өч республика –Татария, Мордовия һәм Чувашия – арасындагы соцбәйге буенча килешү төзү. 1938 ел.

Бауман урамы. Щетинкинның элеккеге номерлары.

Казан. Горький исемендәге Культура һәм ял паркы. 1935 ел.

Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә библиографы В. Недорезов 30 нчы елларда яшәгән Татарстан кешеләренең тормышын саннарда һәм суммаларда тасвирлаган. Менә нинди булган ул:



Казан Кремле. Сөембикә манарасы.

Казан. 1 Майны бәйрәм итү көннәрендә Кремльнең Спас манарасы. 1930 нчы ел.

ХАЛКЫ

- 30 нчы елларда Казан халкының саны – 230 мең, 1/3 өлеше – татарлар.
- 41382 кеше – эшчеләр,
- 24168 – хезмәткәр,
- 8168 – хезмәт күрсәтүче кече персонал (җыештыручылар, каравылчылар һ.б.),
- 5322 – мөстәкыйль җитештерүчеләр,
- 23330 – башка төр хезмәт ияләре.

ТОРАК

- 30 нчы елларда Казанда 42 769 корылма булган.
- Алардан 13430ы – торак йортлар.
- Торак фондының 2/3 өлеше – дәүләтнеке.
- Йортлар нигездә берәр катлы, агачтан җиткерелгән, уңайлыклар – минималь.
- Фатирларда яшәүчеләрнең нибары яртысы гына электр яктылыгыннан файдалана алган, йортларның ¼ ндә генә су уткәрелгән, 3%ында канализация булган, 4%ы үзәктән җылытылган.
- Бер кешегә – 4 кв. метр торак, 1 кв. метр яшеллек туры килгән.
- Торак йортлар аз төзелә, аның каравы предприятиеләр күп: «Авиастрой», «Машинострой», «Грэсстрой»...

ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ҺӘМ ТРАНСПОРТ

- Урамнарның 40 процентына гына таш җәелгән.
- Урамнарның һәр километрына 1,5 фонарь туры килгән.
- 6 трамвай маршруты булган, аларда 111 трамвай вагоны хәрәкәт иткән.
- 22 шәһәр автобусы.
- Шәһәрдә 200 автомашина һәм 250 дән артык олаучы эшләгән.

ХЕЗМӘТ ХАКЫ

- 11932 елда – эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең айлык хезмәт хакы дәрәҗәсен 101 сумга җиткерү карала. Әлегә алар түбәндә күрсәтелгән хезмәт хакын алган:
- Тегү фабрикасында майлаучылар – ай саен 60–70 сум.
- Кинотасма фабрикасын төзүчеләр: балта осталары көненә – 12 сум 25 тиен, бетончылар – 6 сум 90 тиен, арматурачылар – 9–11 сум, ярдәмче эшчеләр – 5 сум 68 тиен.
- «Машинострой»да төзүчеләрнең удар бригадасы – айга 100–150 сум.
- «Авиастрой»да йөк ташучылар – көн саен 30–40 сум.
- Каравылчы, җыештыручы, йомышчыларның (курьерларның) хезмәте аена 30–60 сум белән бәяләнгән.
- Укытучыларның хезмәт хакы 98–169 сумны тәшкил иткән.
- Югары мәктәп укытучылары, техник бүлек җитәкчеләре, инженерлар 200 дән 600 сумга кадәр хезмәт хакы алган.

АЗЫК-ТӨЛЕК

- 30 нчы елларда Казанда, төрле ларёк һәм базарларны санамаганда, 700 дән аз гына артыграк кибет эшләгән.
- Арыш ипиенең килосы – 9, бодай ипиенең килосы 20 тиен торган. Әмма карточкага бирелгән. 1929 елда ипигә генә түгел, иткә, керосинга һәм башка азык-төлек һәм сәнәгать товарларына да карточкалар кертелгән.
- Һәрбер эре предприятиенең эшчеләр өчен ябык кооперативлары, махсус ашханәләре һәм паёк системасы булган.
- Мехкомбинат төзүчеләр ашханәдә ике итле ризык өчен 47 тиен түләгән, ә ударниклар шуңа өстәп бушлай өченче ризык та (эремчек, кесәл яки бер стакан кофе) алган. Монда үз нормалары бар – бер кешегә көненә 200 г ипи һәм 80–100 г ит.
- Махсус белгечләр өчен коммерция тибындагы ашханәләр дә эшләгән. Анда, мәсәлән, итле ризык 1 сум 65 тиенгә тәшә торган булган.
- Ит дәүләтнеке булган сәүдәдә һәм кооператив сәүдәдә 1–2 сум торса, базарда бер килосы 6–7 сумнан йөргән. Йомырканың дистәсе кибеттә – 90 тиен, базарда – 3 сум 50 тиен, атланмай шул ук тәртиптә – 3 һәм 10 сум. Базарда бер капчык арыш – 20–30 сумга, бер чирек сөт – 3 сумга, эремчекнең кадагы 3,5 сумга сатылган. Җәй көне өлгергән карбыз – 5–6 сум, бакча җиләгенең килосы 3 сум торган.
- Кооператив ларёкта ысланган бәртәс балыгының килосын 7 сумга, мәрсин балыгын 9 сумга сатып алып булган.

БАШКА ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТЛӘР

- Керосинның литры – 12 тиен, ситсының метры – 30 тиен. Исле сабынның бер кисәге 65–90 тиенгә сатыла торган була. Барысы да – карточкага.
- Хатын-кызлар өчен шевиот пәлтә кооперативларда – 135 сум, ирләр костюмы – 130 ар сум, балалар костюмнары – 40 ар сумга сатылган.
- Ситсы һәм сатин күлмәкләр – 5–8 сум, чалбар – 10–15 сум.
- Диван һәм өстәлләр 200 әр сум.
- Велосипед 600–800 сум торган. Рояль – 1400 дән 3000 сумга кадәр.
-
- Баланың чәчен алу – 35 тиен, өлкән кешенеке – 80 тиеннән 1 сум 80 тиенгәчә.
- Идел аша моторлы көймәдә чыгу өчен 50 тиен түләргә кирәк булган. Паромда кечү һәм шулай ук йөк белән (автомобиль) – 70 тиеннән 10 сумга кадәр.
- 1932 елдан ике маршрут буенча пассажирлар һәм йөк ташучы авиалинияләр ачыла: «Мәскәү – Казан – Свердловск» һәм «Мәскәү – Казан – Владивосток». Мәскәүгә очу вакыты – 4 сәгатькә, Владивостокка очу 30 сәгатькә сузылган. Казаннан Мәскәүгә очу өчен тарифлар бер килограмм авырлык өчен 1 сум 40 тиеннән исәпләнгән. Казанда аэрофлот әнә шундый бәяләрдән башланган.

1932

ӘЙДӘ, ИПТӘШ, БЕЗГӘ – КОЛХОЗГА...

Күн авылында ныклы хуҗалык алып баручы урта хәлле крестьян Мифтах Бикмөхәммәтов ике бәла-казадан гына курка – янгыннан һәм корылыктан. Көн-төн эшли, хәер, яшәвен дә начар яшәми. Ике аты, сыеры, тавыклары бар, өендә күкеле сәгате эленеп тора... Кешенеке кирәкми, үземнекен дә бирмим, дип көн күрә ул. Өченче бәла – күмәкләшү дигән зәхмәтнең килеп чыгасын кем белгән бит?

Автор:
Әскәр Сабиров

Рәхмәт яугыры, күршеләре кичтән кисәтеп өлгерә:

– Мифтах абый, иртәгә сиңа киләчәкләр. Яшерә алганыңны яшер…

Ә кая яшерергә соң? Соңгы чиккә кадәр менә шулай тик торганнан, бер сәбәпсез, кулак дип язып, бөтенесен талап чыгасыларына да ышанмый ул. Алай да ике тавыгын суя – башка беркайчан мондый тәмле шулпа ашарга насыйп булмый инде аларга…

Уполномоченныйлар иртәнге якта килеп керә. Хуҗага кәгазь төртеп, терлекләрне алып чыгып китәләр. Аннан соң өйдәге әйберләрне ташый башлыйлар. Бернәрсәне дә онытмыйлар. Мендәрләр, хуҗалык кирәк-яраклары, сәгать, он, өйдәге азык-төлек – барысын да алып чыгып китәләр. Хәтта ашка салырга дип әзерләп куйган умачны да...Йорт бушап калгач, хуҗаларның үзләрен урамга куып чыгаралар. Биш бала белән. Иң өлкәне – Разыяга – унике яшь, кечесе Зәкәриягә бер яшь кенә тулып киткән була…

– Хәзер безгә кая барырга инде, ачтан үләргәме?

– Теләсәгез кая китегез. Дүрт ягыгыз – кыйбла, үлә дә аласыз…

Бу хәлләр 1932 елның җәендә була. Гәҗитләрдә, авыл советы диварларында – җете кызыл төстәге плакатлар… Аларның кайберләрендә алсу битле комсомолкалар: «Әйдә, иптәш, безгә колхозга!» – дип елмаялар. Икенчеләрендә өрлектәй егетләр теш арасыннан гына: «Батраклар, фәкыйрьләр һәм урта хәллеләрнең көчен бергә туплап, кулакны изик», – дип чакыралар.

Яңа тормышта бөтен кешегә дә урын табылмый.

КУЛАК, УРТА ХӘЛЛЕ – АЕРМА ЮКМЫ?

Харап, фаҗига икән – кулак урынына күп балалы урта хәлле крестьянны сөргәннәр... Үлүләре хак түгел, бәлки, әле исән дә калырлар. Бөтен җирдә күмәк хуҗалыкларга берләшү барганда аерым бер кешеләр турында уйлап торырга вакыт юк. Татреспубликада ВКП(б) Үзәк комитеты каршында кызарып торырга күнекмәгәннәр: аерым хуҗалыкларны колхозларга җәлеп итү бурычын партия кушканча ашкынып башкаралар.

Урыннарда әлеге ашкыну тәмам ярсу, шашуга әйләнә. Ятларны куркыту өчен үзләренекенә дә эләгә. Хәтта Мәскәүдән килгән Френкель һәм Грушкин иптәшләр дә ВКП(б) Үзәк комитетының оештыру бюросына аңлатма язуы әзерләгәндә теш сызлагандай чырайларын сыталар: «Яңа Чишмә районының Ямаш авылында урта хәлле саналган Бухохаров Андрейга (1918 елдан 1921 елга кадәр Кызыл Армиядә хезмәт иткән, ике мәртәбә яраланган, гаиләсендә 4 кеше) партячейка секретаре һәм аның белән бергә тагын 2 коммунист кереп, 9 пот икмәген, арбасын алып чыгып киткәннәр... Ямаш авылы буенча 30% хуҗалыкны кулакларга керткәннәр. Волчья слободада 19 урта хәлле крестьянга хаксыз рәвештә каты задание бирелгән, аларның мал-мөлкәтләре тартып алынган, кешеләрнең үзләрен өйләреннән куып чыгарганнар. Тымытык районының Сукаеш авылында барлык аерым хуҗалыкның 50%на, кулаклар белән бергәттән, каты задание бирелгән...»

Татреспубликага җибәрелгән ҮК инструкторлары, сыйнфый юнәлешне бозган кайбер фактларны тарих өчен теркәп куйсалар да, гомумән алганда, вазгыятькә җитди йогынты ясый алмыйлар. Урыннардагы түрәләрнең кайберәүләренә, арттырып җибәрүләр өчен, күп дигәндә, партия линиясе буенча шелтә чәпиләр. Яисә кул астында эшләүчеләрнең муен тамырына берне тондыралар –– шуның белән шул. Мондый шелтәләр булды ни, булмады ни.

Ә менә икенче бер нәрсәләр өчен җәзалыйлар яисә мактыйлар. Әйтик, колхоз төзелешендәге

уңышлар яки уңышсызлыклар өчен. Икмәк әзерләү өчен. Илдә индустриальләшү башлана, шәһәрләргә икмәк күбрәк кирәк була башлый. Бу яктан Татария большевикларына тел-теш тидерерлек түгел. Френкель һәм Грушкин, хәлләрне җентекләп өйрәнеп, «икмәк әзерләүнең шактый артуын» билгеләп үтәләр: 1929 елда 7 миллион пот икмәк тапшырыла, 1930 елда – 17 миллион пот, 1931 елда исә инде – 34 миллион пот! Нәкъ менә френчларга орденнар өчен тишек тишәр вакыт…

Дөрес, һәр миллион потны җыю торган саен авыррак була бара. Бай «келәтләрдән» икмәкне башлыча 1930 елда ук кырып-себереп алып бетерәләр, ул вакытта Татариядә 15 меңгә якын хуҗалыкны кулаклар исемлегенә язып, кешеләрне туган нигезләреннән сөрәләр. Ә калган биш мең сыйнфый дошман «оясын» бер елдан соң тузгытып бетерәләр.

Шунысы билгеле: 1927 елда Татариядә 518 027 крестьян хуҗалыгы була, шуларның дүрт проценты кулак исәпләнә. Сыйнфый дошманны авыл җирендә 1932 ел башына юкка чыгаралар булып чыга. Бу очракта аннан соң кем белән көрәшкәннәр икән? Кемнең игенен, терлеген төяп алып киткәннәр, җирен, малмөлкәтен тартып алып, кемне хәерче иткәннәр?

КОНЦЛАГЕРЬ, МАХСУС ПОСЕЛЕНИЕ ЯИСӘ ИҢ ЮГАРЫ ҖӘЗАМЫ?

Җиде айга мәҗбүри эшләргә җибәрергә – Казан район суды 1932 елда Каймар авылы гражданкасы Шмелёвага каты хезмәт заданиесен үтәмәгән өчен шундый кырыс карар чыгара. Колхозга кермәгән, урта хәлле, хәер, тырышырга кирәк иде! Ә инде җәза чыгарылган кешенең сукыр карчык булуын гадел суд, баштанаяк революцион эшләргә чумуы сәбәпле, гафу итегез, күреп өлгермәгән.

Гражданка Шмелёва, мөгаен, соңгы көченә мәҗбүри эшләргә дә йөрер иде, ләкин әлеге очрак, бәхеткә, аның кадәр үк өметсез булып чыкмый. Юк, карчыкның сукыр яисә хәлсез булуы аркасында түгел. Кинәт кенә карчыкның өч улы да Гражданнар сугышында үзләре теләп Кызыл Армия сафларына язылганнары ачыклана, ике улы якты киләчәк өчен башын салган, «революция каршындагы зур хезмәте өчен» үлгәннәрнең берсенең исеме хәтта пассажир пароходына бирелгән…

Революцион законнарны бозуның әлеге очрагы турындагы хәбәр, башка бик күп фактлардан аермалы буларак, иң югарыга кадәр барып җитә. Сукыр карчыкта кызылармиячеләрнең әнкәсен күрә алмаганнарга, мөгаен, күрсәтмә җәза бирелгәндер, бәлки, хәтта җаваплы вазыйфаларыннан да колак какканнардыр алар. Сәяси сукырлыкларында ачыктан-ачык үкенгән якты киләчәкне төзүчеләр, әлбәттә, әле ике еллап элек кенә дә партия сәясәтен ничек җиңел һәм артык көч түкмичә тормышка ашырганнарын сагынып искә алганнардыр.

Ул чакта ВКП(б) ҮКның 1930 елның 30 гыйнварындагы «Тоташ күмәкләшү районнарында кулак хуҗалыкларын юкка чыгару буенча чаралар турында»гы Карары яңа тормыш төзү өчен көрәшүчеләрнең иң рәхимсезләренә юл ача. Партия барлык кулакларны өч категориягә бүләргә әмер бирә. Беренчесенә контрреволюцион актив кертелә, икенчесенә – контрреволюцион активның калган өлеше, иң байлардан, өченчесенә – калган кулаклар… Ә алга таба – барысы да бик гади, инструкция буенча һәм артык хисләргә бирелмичә. Беренче категориягә кергәннәрне кулга алу көтә, аларның язмышын ОГПУ, ВКП (б) өлкә (край) комитеты һәм прокуратура вәкилләре кергән махсус өчлек хәл итә. Сайлау вариантлары зур түгел: концлагерь, иң югары хөкем… Гаиләләрне Төньякка, Себергә, Уралга, Төркестанга, махсус поселениеләргә сөрү көтә. «Калганнар» категориясенә кергән кулакларга язмыш елмая дияргә дә буладыр – бар мал-мөлкәтен тартып алып, власть аларга хәтта туган республикада да калырга рөхсәт итәләр.

Ят сыйныфка кертелеп, лагерьларга һәм махсус поселениеләргә озатылган татарстанлыларның төгәл санын атау кыен. Бары тик шунысы гына билгеле: ил күләмендә партия тарафыннан «беренче категория»ле 60 мең кулакны «аерып алу» буенча планны ОГПУ инде 1930 елның октябренә ике мәртәбәдән артыграк итеп үти.

БАЙЛЫК КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ БУЛАРАК КӘҖӘ, АРБА ҺӘМ УТЫН ЧАНАСЫ

Татариядә арттан сөйрәлергә күнекмәгәннәр. Кулакларны сөрү буенча план шулай ук арттырып үтәлә – шөкер, тиешле активлык күрсәткәндә урыннарда кулак дип теләсә кемне «язарга» мөмкинлек була.

Татар Томбарлысы авылында да активистлар табыла. 1930 елның 2 июлендә Баулы волосте башкарма комитеты президиумы утырышында әлеге авыл кешесе И. Газизуллинны кулак дип сөрү турында беркетмә раслана. «Байгура»ның документка теркәлгән мал-мөлкәте исемлегендә иң кыйммәтлеләре атала: «1.Ызба 2.Амбар 3.Ат 4.Кәҗә 5.Арба 6.Утын чанасы». Шунысы да язылган: ат, кәҗә, арба һәм утын чанасы колхоз өчен конфискацияләнә.

Аның каравы хакимиятнең күмәк хезмәткә кушылырга теләмәүчеләргә йогынты ясарлык күпме ысулы була! Нәтиҗә – күзгә күренерлек. 1930 елның мартына Татариядәге крестьян хуҗалыкларының 83 проценттан артыгы колхозларга кергән санала. Күмәкләшү темплары буенча республика ил буенча өченче урынга чыга.

Ә аннан соң бер урында кирегә тәгәрәү. «Правда» газетасында Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе һәм ҮКның «Колхоз хәрәкәтендә партия линиясен бозулар белән көрәш турында»гы карары басылып чыгуга, крестьяннар колхоздан бер-бер артлы алныартны карамый кача башлый. 1930 елның 1 октябренә Татариядә күмәк хуҗалыкларның өлеше ун проценттан да кимрәккә кала. Крестьян хәзер инде колхозга язылуның ирекле булуына чынлап торып ышанган, күрәсең.

Большевиклар чыннан да сүз белән ышандыруга һәм икътисадый методларга басым ясый башлыйлар. Соңгылары хәтта репрессияләргә (сүз уңаеннан, аларны шулай ук беркем дә тыймый) караганда, нәтиҗәлерәк булып чыга. Бигрәк тә Тымытык районында тырышалар, монда аерым хуҗалыкларга авыл хуҗалыгы салымын 5–10 мәртәбәгә арттыралар. Аерым хуҗалыкларның күпчелеге салымны түли алмый, һәм аларның мал-мөлкәтен бурычны каплау хисабына саталар. Көзен аерым хуҗалыкларга уңышны җыярга ирек бирмиләр – иген белән нишләргә кирәклеген колхоз хәл итә. Ә аннан соң аерым хуҗалыкларның бөтенләе белән җирләрен, атларын тартып алалар. Фәкыйрьлекнең чигенә җиткәннәргә кая барырга? Менә шул юл белән район җиңел һәм җайлы гына 100 процентлы күмәкләшүгә ирешә дә.

Сүз белән үгетләү көченә килгәндә исә, һәр район диярлек үзенең ныклы аргументын кулланырга тырыша. Әлмәт башкарма комитеты уполномоченные Шәриф Булгаков, мәсәлән, тал чыбыгы һәм дилбегәнең теләсә кайсы сүздән дә көчлерәк булуына ышана. Аның күрсәтмәсе буенча Сөләйдә крестьяннарның яртысын диярлек шул ысул белән кыйнап ташлыйлар.

1931 елның көзенә индивидуаль хуҗалыкларның 62 проценты күмәкләшә. Колхоз төзелешендә яңа ыргылыш кулакларны сөрүнең чираттагы этабы белән туры килүен күрү кыен түгел.

КРЕСТЬЯН ӨЧЕН АВЫЛ ҮГИ АНАДАН ДА КАТЫРАККА ӘЙЛӘНӘ

1932 елның феврале. Кызыл командир – укчы полк взводы командиры ярдәмчесе Иван Дмитриев туган ягы – Бөгелмә районына ашыга. Дмитриев өч елга беренче мәртәбә ял ала, туганнарының хәлен белергә, шул ук вакытта авылда колхоз төзелешенең ничек барганын үз күзләре белән күрергә тели. Авылның киләчәге күмәкләшү булуына ул Совет властена ышанган кебек чын күңелдән ышана. Ләкин авылында күргәннәр сугышчыны шаккатыра. Дмитриевның «Правда»га Сталин исеменә юлланган хатында – ачыктан-ачык югалып калу күренә: «Минем гаилә Татреспубликада, Бөгелмә районындагы «Кызыл доброволец» колхозында яши. Өемнән хат алганда, мин аларның иписез, ач утыруларына ышана алмадым һәм беркайчан да ышанмадым... Ләкин 1932 елның 27 февраленнән 7 апрелена кадәр мин ял алдым һәм Бөгелмә шәһәренә кайттым, анда орлыклар артыннан килгән әтине очраттым. Мин аны көчкә таныдым... Өйгә кайттым, әни миңа нәрсә ашатыр дип күзлим. Табынга ниндидер калдык-постыктан әзерләнгән боламык чыгарылды. «Сез нәрсә ашап торасыз соң?» – дип сорадым мин. «Менә шуны ашыйбыз инде, монысы да һәрвакыт булмый әле», – диделәр миңа... Район оешмалары үткәргән эш хәтта хәрби коммунизм шартларын да арттырып җибәрә. Сандыкларны актаралар, чүлмәк, мичләрдә эзләнәләр, крестьянның соңгы киемен, самоварын, мендәрләрен талап алалар, утын сарайларын ваталар, үзләрен өйләреннән куып чыгаралар... Бөгелмә районында һәм, гомумән, Татреспубликаның күп районнарында авыл үги анадан да катыракка әйләнгән. Кешеләр, үз өйләрен ташлап, кайсы кая кача...»

Халыкны җирдән аерып, булдыклы, эшчән хуҗаларны репрессияләп, калганнарны көчләп колхозга берләштереп, хакимият нәрсәгә ирешергә тиеш иде, шуңа ирешә. «Беркемнеке дә булмаган» җирдә эшләргә атлыгып тормаган, усалланган, ярымач халык массалары пәйда була. Икмәк әзерләү планын үтәүдән баш тартучылар, барыбер тартып алыначак икмәкне үстерергә теләмәүчеләр массасы оеша. Шуңа реакция дә шундый: шәһәргә качу, массакүләм протестлар.

АЧЛЫК ҺӘМ КҮРСӘТМӘ ПРОЦЕССЛАР

1932 елның февралендә Әлмәт районы прокуроры ТАССР Юстиция наркоматына яшерен сводка җибәрә. Фактларның берсе: Кодаш авылында аерым хуҗалык алып баручылар «70–80 кешедән торган халык төркеменең башында колхоз амбарларын таларга һәм орлыкларны бүлергә килә. Төркем, ишекләрне җимереп, бөтен орлыкны алып китәргә тели һәм авыл советы рәисен кыйнарга омтыла. Әлеге эш буенча барлыгы 6 кеше хөкем ителә, шуларның 4есе – хатын-кыз. Ике урта хәллегә карата 74нче маддә буенча 1 ел һәм 8 айлык социаль яклау чарасы кулланыла, хатын-кызларга – мәҗбүри эшләр».

Репрессия чаралары турында хәбәр итүче прокурор сүзләрендә аның әлеге вазгыять каршында көчсезлеге дә күренә: «Орлык җыю,



алда хәбәр итүемчә, күтелгән нәтиҗәләрне бирмәде. Район буенча барлыгы 35% җыелды. Мин шәхсән үзем 12 авылдагы җыенда катнаштым һәм көн тәртибенә орлыклар турындагы сорауны куйдым. Гражданнар орлык тапшыру түгел, үзләре дәүләт ярдәм итмәсә, икмәксез калулары турында ачыктан-ачык белдерәләр. Кодаш авылында фәкыйрьләр һәм урта хәлләләр атларын суя башлаганнар, бу гамәлләрен ачлык белән аңлаталар».

Һәм алга таба нәрсә? Алга таба – һәрвакыттагыча. Колхоз төзелешендәге уңышсызлыкларда контрреволюцияне һәм кулакларны гаепләү кулайрак. Районда ашыгыч рәвештә суд-тикшерү бригадасы төзелә, ул «усал ният белән терлекләрне суючы һәм орлык тапшырудан баш тартучы кулакларны ачыклый һәм күрсәтмә процесслар оештыра».

Хәер, хәтта коммунистик идея күзләрен томалаган активистлар да авылдагы коточкыч вазгыятьне күрми кала алмый. Революцион җәза бирүләрне гаять зур тиз белән башкаручы прокурор да, Сөләй, Кодаш, Урсалы авылларында кешеләрнең ачтан интегүләрен, ә терлекләрнең азык булмау сәбәпле кырылуларын югарыга хәбәр итеп, болай дип яза: «Минем тәкъдим буенча Сөләйгә салам, печән җибәрелде. Хәзер район башкарма комитеты терлек азыгын көйләү буенча эшли. Ихтыяҗ кискен торган колхозларга әзрәк хәлләләрдән азык җибәрү буенча чаралар күрелә».

Ә «әзрәк хәлләләр» күпме соң алар? Әмма большевиклар чигенергә иялəшмәгән. Колхозларга кертелгәннәрне ничектер эшләргә мәҗбүр итәргә, кызыксындырырга кирәк. Алай итмәгәндә – һәлакәт, җиңелү.

УДАР ХЕЗМӘТ ПАТЕФОНЫ

1935 ел, көз, Ютазы районы. Колхозчы Захар Егорович Тимошин бәхетеннән нишләргә белми. Чәчүгә тырышып әзерләнгәне һәм «дирбияне яхшы ремонтлаган өчен», аңа 60 сумлык сәгать тапшыралар. Комбайнчы Шитов та хәзер хәлле кеше. 270 гектар бодай урганы өчен, ул күрелмәгән затлы әйбер – патефонга ия була. Колхозчы Шәмсия Хәсәнова язгы чәчүгә яхшы әзерләнгәне өчен, тагын да кыйммәтлерәк бүләк – тегү машинасына лаек дип табыла.

Массакүләм репрессияләрдән, крестьян чыгышларыннан һәм авылның хәерчелеккә төшүеннән әле күп вакыт үтми, шулай да колхозлардагы үзгәрешләр инде күзгә күренә. Эш итү тактикасын үзгәртеп, большевиклар барыбер күмәк хуҗалыкларны дәүләт өчен гарантияле азык-төлек тәэминатчылары итүгә ирешәләр. Вазгыятьне нәрсә бәрабәренә үзгәртергә мөмкин була соң? Мөгаен, егермебишмеңчеләр хәрәкәте дә (ул вакытта Татариягә колхозлардагы эшне оештыру өчен 400 эшче җибәрелә), партияле колхозчы-агитаторларның тырышлыгы да үз ролен уйнамый калмагандыр. Шулай ук колхоз строеның өстенлекләре турында армый-талмый сөйләп килгән газеталарның да. Әмма менә нәрсә мөһимрәк: тоташ мәҗбүриләүгә алмашка уйланыбрак эшләнгән чыбыркы һәм прәннек сәясәте килә.

Крестьянга тыйнак кына сайлау хокукы бирелә. Илдә тоташ дефицит һәм карточка системасы, ә яхшы эш өчен хәзер инде күлмәклек, сәгать яисә савыт-саба алырга була, хезмәт көне өчен – берничә килограмм ашлык. Начар эшләгән, ашлык югалткан өчен – корткыч һәм күмәк хуҗалык милкен талаучы келәймәсе сугыла, шулай ук 10 елга сөргенгә сөрергә дә мөмкиннәр...

Тагын бер стимул – социалистик ярыш (дөрес, ул нәтиҗәлелеге буенча капиталистик көндәшлеккә җитә алмый әле). Ләкин иң мөһиме: хәзер авылдан алып кына калмыйлар. Машина-трактор станцияләре оештырыла, трактор һәм комбайннар саны арта. Татария белән Мәскәү өлкәсе арасында килешү төзелә, аның буенча колхозларга һәм совхозларга эре предприятиеләр шефлык итә. Техника, акча, кадрлар белән булышалар. Бушлай түгел, әлбәттә, – бөтен авыл хуҗалыгы продукциясе (үз ихтыяҗларына һәм экспортка киткән өлештән кала) Мәскәү өлкәсенә озатыла.

1934 елның гыйнварында Татарияне Ленин ордены белән бүләклиләр. СССР ҮБК Президиумы карарында хәбәр ителгәнчә: «Төп авыл хуҗалыгы эшләрен (чәчү, урыпҗыю, орлыкка салу) башкарудагы, колхозларны һәм совхозларны ныгытудагы һәм дәүләт каршындагы бурычларны үтәүдәге гаять зур уңышлары өчен».

Икенче бишьеллык ахырына республикада 3,8 меңнән артык күмәк хуҗалык исәпләнә инде.

СҮЗ АХЫРЫНДА

Урта хәлле исәпләнгән бабам Мифтах Бикмөхәммәтов 1932 елда кулак буларак сөрелсә дә, бәхетле билет тартып чыгара. Казанга килеп җитеп, милициягә эшкә урнаша һәм тартып алынган – дөресрәге, таратып бетерелмәгән мал-мөлкәтен кире кайтаруга ирешә... Бу турыдагы документ бүгенгә кадәр гаилә архивында саклана. Авылга бабай башка әйләнеп кайтмады, гәрчә гомере буена җирне, крестьян тормышын сагынып яшәсә дә. Мөгаен, үз туган нигезләреннән куылган дистә меңләп башка булдыклы кешеләр кебек үк. ГУЛАГ лагерьларында харап булган, махсус поселениеләрдә исән кала алган, Магнитканы төзегәннәр кебек үк. Күпләгән язмышларны пыран-заран китергән бөек социаль экспериментның нәтиҗәсе аянычлы: колхозлар утызынчы елларда ничек тиз төзелсә, туксанынчы елларда шулкадәр үк тизлек белән юкка да чыкты...

Җиргә чын хуҗа әле бүген дә фаҗигале рәвештә җитми.

МИЛЛИ ХОЛЫКЛЫ КЛАССИКА

1939 ел. «Качкын» операсы премьерасына нибары ике атна калган. Бертуктаусыз, көне-төне эш кайный. Бу искиткеч җаваплылык таләп итә, чөнки нәкъ менә шул спектакль белән Казанда яңа опера театры ачылачак.

Автор:
Катерина Котова

Инде иртәнге сәгать унбер тулган, әмма «Качкын» операсы авторы Нәҗип Җиһанов караватыннан торырга уйламый да. Ул шулкадәр арыган ки, хәтта репетициягә бармаска булган. Аның уйлары бер генә нәрсә тирәсендә бөтерелә – моңарчы күрелмәгәнчә гауга, «республика күләмендә истерика» күтәелә – премьерада кем җырларга тиеш? Җиһанов фикеренчә, элекке казанышлары булган кеше түгел, бәлки остарак артист җырларга тиеш – бу турыда инде ул театр директоры белән дә, сәнгать җитәкчесе белән дә, һәм хәтта сәнгать эшләре буенча башлык белән дә сөйләшеп куйган. Рәйханә – Кайбицкая, Булат – Артёмов, Кирәмәт – Насретдинов... Ул менә шушы состав җырласын өчен тырыша. «Әгәр эшкә Совнарком тыкшынмаса, бу состав һичшиксез җырларга тиеш!» Ихтимал, Совнарком тыкшынмагандыр,чөнки театрда беренче кичәдә сәхнәдә Кайбицкая белән Насретдинов балкый...

Мансур Мозаффаровның «Галиябану» операсында Галия Кайбицкая Галиябану ролендә.

Менә ул Татар опера һәм балет театрының иң җете артефакты – «Качкын» операсы афишасы. 1939 елның 17 июнендә ул шул спектакль белән ачыла. Игътибарны кызыклы детальләргә юнәлтәсе килә. Беренчесе: башта театр исемендә «балет турында» бер генә сүз дә булмый, афишада исә балет труппасы бар. Икенчесе: яңа опера театрының үз бинасы булмаганга, премьераны Зур драма театрында (хәзерге Качалов исемендәге) күрсәтәләр. «Гаять зур мәдәни чара булмәдәге бер почмакны яллап торучы хәлендә, бивуакта урнашкандай үткәрелә», – дип язган премьера турындагы тәнкыйть мәкаләсендә танылган публицист һәм критик Давид Заславский. Театрның үз йорты 1956 елда гына булачак әле. Өченчесе: тамашачылар талон буенча кергән, һәм бу да гаять катлаулы шул чорның чагылышы булып тора...

Афишалар һәм фотолар Татар дәүләт опера һәм балет театры архивыннан алынды

Сүз уңаеннан, шул авыр чорда Казан Җиһановсыз кала язган – аның Совет Татарстаныннан китәргә сәбәпләре шактый җыйналган. Спектакльгә әзерлек бер үк вакытта бик илһамландыргыч та, бик катлаулы да булган. Җиһанов, театр сәхнәсендә үз әсәре туугa сөенү белән беррәттән, администрацияне ваемсызлыкта, үз эшенә салкын карауда гаепләгән. Директор урынбасарын «кызган баштан түгел, бәлки аңлы рәвештә» оятсыз һәм ахмак дип атаган. Әлеге бәрелеш кимендә шелтәгә тарта, әмма Җиһанов моннан курыкмый, киресенчә: «Шул вакытта инде мин үземнең кирелегемне тулы куәтенә күрсәтәчәкмен һәм эш йә шелтәле фәрманның юкка чыгарылуы белән бетәчәк, яки алар минем икенче опера вәгъдә итүемне онытырга мәҗбүр булачаклар, ә бәлки, мин бөтенләй Казаннан ук китеп барырмын», – дип язган ул үзенең беренче хатыны Симурка – Серафима Алексеевнага.

Әйе, яңа театрда вазгыять шактый томанлы була. Спектакльләр кыен матди шартларда әзерләнә. Премьерага кадәр диярлек театр Фәнни хезмәткәрләр йортында сыенып яши, андагы тамаша залы тулы канлы репетицияләр үткәрергә мөмкинлек бирми. Музыка уен кораллары җитешми. Кая әле уен кораллары! Беренче вакытларда музыкантларга да, артистларга да кытлык була, бигрәк тә балет артистларына, шунлыктан еш кына вокалчыларга биергә дә туры килә.

Дәвере шундый була, әмма ул чактагы бөтен авырлыкларның сәбәбен бик гади аңлаталар. «Халык дошманнары халык иҗаты, халык талантларының тере чишмәләрен берничә тапкыр күмәргә маташты. Буржуаз милләтчеләр татар операсын булдырмас өчен әллә ниләр эшләргә әзер иде», – дип раслый «Комсомолец Татарии» газетасы, Татар дәүләт опера театры булдырылу фактын исә «Партиянең Ленин – Сталин милли сәясәте тантанасы» дип атаудан тайчынмый.

Бәхеткә, ул заман матбугатында объектив тәнкыйтьне дә очратып була. Премьерадан соң икенче көнне «Правда» газетасы: «Качкын» – чыннан да, бу сүзнең иң яхшы классик мәгънәсендә опера, бу музыкаль драма спектакле түгел... Бу, һичшиксез, театрның уңышы, өметләндергеч башлангыч», – дип яза.

ТАЛАНТЛАРНЫ – СТУДИЯГӘ!

– Ул чакта Муса та, мин дә бу очрашуның безнең тормышта нинди әһәмияткә ия булачагын фаразламадык әле, – дип язачак үзенең истәлекләрендә күп еллар узгач Нәҗип Җиһанов. – Җәлил мине күзәткән, композитор буларак язган әсәрләремне тыңлаган, мин исә, үз ягымнан, аны шагыйрь буларак күбрәк өйрәнә башладым. Безне татар профессиональ музыка мәдәнияте язмышына карата уртак мөнәсәбәт берләштерә иде.

Ике олпат иҗади шәхес – Муса Җәлил һәм Нәҗип Җиһанов арасындагы дуслык татар мәдәниятенә «Алтынчәч», «Илдар», «Шагыйрь», «Җәлил» операларын бүләк итә... Әлеге дуслык исә Мәскәүдә башлана – 1934 елда республиканың иң яхшы иҗади көчләре башкалага укырга җибәрелә. Ул вакытта Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында Татар опера студиясе оештырыла. Бер генә максат белән – яңа татар опера театры өчен кадрлар әзерләү. Анда консерваториянең әйдәп баручы профессорлары, күренекле театр әһелләре укыта. Ә студентлар арасында Казан музыка техникумын тәмамлаучылар да, һәм инде тәҗрибәле артистлар да, шулай ук дирижерлар, композиторлар, драматурглар бар. Менә, мәсәлән, инде татарның беренче «Сания» операсында балкыган Сара Садыйкова, танылган Мансур Мозаффаров, һәркем яраткан Салих Сәйдәшев... Студияне Хәмит Төхфәтуллин җитәкли, композитор Җәүдәт Фәйзи – уку-укыту бүлеген, Муса Җәлил әдәби бүлек мөдире була.

Московская Государственная
ФИЛАРМОНИЯ
Сезон 1938-39 г.

15 декабря

БОЛЬШОЙ ЗАЛ
КОНСЕРВАТОРИИ

КОНЦЕРТ
СТУДЕНТОВ ВЫПУСКНИКОВ
ТАТАРСКОЙ ГОСУДАРСТВЕННОЙ
ОПЕРНОЙ СТУДИИ
при
МОСКОВСКОЙ ГОСУДАРСТВЕННОЙ КОНСЕРВАТОРИИ

В ПРОГРАММЕ:
Фрагменты из опер
„Ирек" — Н. Жиганова
„Качкын" — Н. Жиганова
„В бурю" — Т. Хренникова
„Мать" — В. Желобинского
„Фауст" — Ш. Гуно

МУЗАФАРОВА М. | ХАБИБУЛИНА З.
Джаудат ФАЙЗИ | САЙДАШЕВА С.

УЧАСТВУЮТ (по алфавиту)

Байрашева З. С.	Коренева Е. А.	Альмеев У. А.	Минаев Н. Н.
Булатова М. З.	Сакаева Р. Н.	Артемов А. И.	Насретдинов Ф. Х.
Брегман А. В.	Садыкова С. Г.	Булат М. К.	Обухов В. А.
Девишева С. С.	Сенкевич С. В.	Верниковский Л. С.	Пустоветов А. М.
Забирова Х. С.	Степанченок И. П.	Даутов Н. К.	Сейфутдинов А. А.
Измайлова А. С.	Рахманкулова М. М.	Маев Л. С.	Ростовцев Г. Н.
Измайлова З. С.	Рахматулина Н. К.	Маннапов Ф. С.	Рудаков Н. Р.
Кайбицкая Г. Н.	Алеев М. З.	Мелехов А. С.	

Брук Е. Н., Жив, Р. И., Шнеерсон З. Б.,
Домбаева Е. А., Бендерский С. Д. Бушелева Л. П.

Начало в 8.30 веч.

Менә ул дәвернең тагын бер артефакты – Татар дәүләт опера студиясен тәмамлаучылар концерты афишасы. 1938 елның 15 декабрендә Мәскәү дәүләт консерваториясендә опералардан өзекләр күрсәтелә, алар арасында яшь композитор Нәҗип Җиһанов каләменнән әле генә чыккан «Качкын» да була. Сүз уңаенда, аның өчен авторлык гонорары дүрт мең сум тәшкил итә. Опера студиясе белән килешү нигезендә, яңа милли опера ансамбльле, хор һәм балетлы, шулай ук «татар музыкасы характерына ия булырга» тиеш була.

Беренче татар операсы «Сания»нең авторлары һәм башкаручылары (1925 ел). Сулдан уңга утыралар: Г.Айдаровский, А.Литвинов, В.Виноградов, Г.Әлмөхәммәтов, С.Габәши. Басып торалар: Л.Гаврилова, С.Садыйков, Г.Кайбицкая, А.Хисамов.



Опера һәм балет театрында куелган беренче балетның афишасы, ни кызганыч, сакланмаган. Әмма, аерым бер тарихи фактларга таянып, без аны торгызып карый алабыз. Ул «Тщетная предосторожность» була. Дизайн-версия авторы Леонид Гобәйдуллин.

Опералардан өзекләр кую һәм башкару өчен студиядә укучылар янына төрле театрларның режиссерлары килә. Алай гына да түгел, казанлылар башкаладагы бер генә премьераны да калдырмый. Мейерхольд театры, Революция театры һәм, ниһаять, Зур театр – боларның барысы да алар өчен ачык! Студиядә укучылар еш кына үзләре дә башкаланың иң яхшы мәйданчыкларында концертлар белән чыгыш ясый. Дәрес, бу бөтен кешегә дә бердәй җиңел бирелми. Әйтик, киләчәктә атаклы опера җырчысы булачак Мөнирә Булатова сәхнәдән шулкадәр курка ки, хәтта киңәш сорап... невропатологка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Бер концертта Булатова «Сагыну» җырын башкарырга тиеш була. Куркудан үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә җиткән кыз көчкә җырлап чыга: моннан соң мәңге чыкмаячак ул сәхнәгә! Тик шул вакыт Мөнирәне кабат сәхнәгә төртеп чыгара башлыйлар. Булатова карыша һәм нәтиҗәдә залга аркасы белән килеп чыга. Аның беренче тапкыр «бис»ка җырлавы менә шулайрак була*.

Ә менә Усман Әлмиевкә Станиславскийның үзе каршында җырлау бәхете тәти. Очрашу Константин Сергеевич өендә – Леонтьев тыкрыгындагы ике катлы борынгы йортта була. Станиславский Мәскәү консерваториясе профессоры Друлякина сыйныфы студентларын колонналы гаять зур репетицияләр залында каршылый. «Чал чәчле, мыеклы, озын буйлы, кычкырмыйча һәм салмак кына сөйләшә». Шәкертләрнең кайсы ариядән өзек, кайберләре икәү җырлый. Әлмиев «Евгений Онегин» операсыннан борынгы француз җырын башкара. «Сез француз малае кебек җырладыгыз», – дигән «вердикт» чыгара театр сәхнәсе мэтры**.

Башкорт студиясеннән соң Татар студиясе Мәскәү консерваториясе каршындагы икенче милли студия була. Аннары гына Төркмән, Казах, Кыргыз, Үзбәк студияләре формалаша... Сәнгать белгече Лилия Салихова язуынча, ул елларда милли опера булу факты милли мәдәниятнең «сыйфат билгесе» санала, Европа үрнәгендә милли опера театрлары ачылу исә социалистик строй, аның милли сәясәте казанышларын күрсәтә торган үзенчәлекле «витрина» әйләнә.

1939 ел Советлар Союзының байтак республикаларында милли операны үстерү өчен башлангыч ноктага әйләнергә тиеш була. Әмма куелган бурычны барысы да үти алмый. Татарстан исә булдыра.

ПАРТИЯ ТҮГЕЛ, КЕШЕ

Ә менә яңа театрда куелган беренче балетның афишасы, ни кызганыч, сакланмаган. Тик без аны, мәгълүм тарихи фактларга нигезләнеп, яңарта алабыз. Бу Герольд музыкасына «Тщетная предосторожность» классик спектакле премьерасы була. Һәм ул инде 1939 елның 9 сентябрендә куела.

Гаҗәп хәл, әмма «Тщетная предосторожность» балетына матбугат әллә ни игътибар бирми. «Халык иҗаты чишмәләре» яки «партиянең грамоталы милли сәясәте» дип лаф ормыйлар. Ихтимал, сәбәбе сугыш якынлашудадыр, газеталар Европадагы кайнар яңалыкларны җиткерергә ашыга. Монда инде балет кайгысы түгел. Ә бәлки эш яңа театрда беренче балет спектаклен кую идеясенең партиянеке түгел, бәлки конкрет бер кешенең, ягъни театрның беренче баш балетмейстеры Гай Таһировныкы булудадыр.

Театрдагы коллегалары кебек үк, Гай Таһиров та Мәскәүдә укыган, тик опера сәнгатенә түгел, балетмейстерлык осталыгына өйрәнгән. Зур театр балетмейстеры Евгения Долинская аның педагогларыннан берсе була. Нәкъ менә ул Гай Хаҗи улын беренче спектаклен куюга әзерли, аны «җыярга» ярдәм итә. Шунлыктан «Тщетная предосторожность» балетын сайлау бер дә очраклы түгел.

Сүз уңаенда, балет труппасының беренче исемлегендә нибары унбиш исем бар. «Качкын» премьерасына кадәр Таһиров аны 25 артистка җиткергән. Әмма бу да бик аз, шунлыктан беренче балетны куйганда төп проблема кадрлар кытлыгы була. Гай Хаҗи улы аны хәл итә ала – бераз вакыттан соң татар балетының үз йолдызлары кабына.

Аларның иң беренчеләре – Бари Әхтәмов һәм Таһиров ярдәмендә 29 яшендә пуантларга баскан Анна Гацулина! Җиңү алдыннан, 1945 елда куелган беренче татар балеты «Шүрәле» спектаклендә Сөембикә ролен нәкъ менә Анна Федоровна башкарачак. Гали батыр ролендә Бари Әхтәмов бииячәк. Әмма бу инде бөтенләй башка вакыйга...

* Гүзәл Сәйфуллинаның «Счастье сцены. Личность и судьба Мунирры Булатовой» китабыннан.
** Усман Әлмиевнең «Еллар һәм җырлар» хатирәләреннән.

Материалны әзерләүдә ярдәм итүләре өчен редакция Татар дәүләт опера һәм балет театры музей фонды саклаучылары Галия Акчуринага һәм Рәмзия Такташка, шулай ук композитор Нәҗип Җиһановның оныгы, аның музей-йорты директоры Алексей Егоровка рәхмәтен җиткерә.

«ҖИҢҮЧЕЛӘР БУЛЫП ЧЫКТЫК БЕЗ...»

Алар – чынлап та җиңүчеләр. Башлары ни күрсә, рухлары нинди михнәтләр аша узса да, сүзләре белән җиңеп чыгалар. Бүген татар язучылары тарихының шанлы да, канлы да елларына кайтып килик...

КАЛӘМ ӘҺЕЛЛӘРЕН – БЕР ТҮБӘ АСТЫНА

СССР Язучылар союзы төзелү 1934 елдан саналса да, аның башлангычы 1932 елга – ВКП (б) Үзәк Комитетының 23 апрельдә чыгарган карарына барып тоташа. Язучылар союзын оештыру мәсьәләсе, нигездә, шул елны ук хәл ителә. 1934 елга кадәрге калган 2 елда әзерлек хәстәре күрелә. Үзәктә һәм республикаларда бу юнәлештә кызу эшләр башлана. Шул ук елның маенда Татарстан совет язучыларының Бердәм союзын төзү буенча Галимҗан Нигъмәти җитәкчелегендә оештыру комитеты булдырыла. Комитетның максаты – төрле төркемнәргә бүлгәләнгән (ТАПП, СУЛФ, «Юлаучылар» һ.б.) язучыларны бер максатка юнәлтеп берләштерү. Сүз уңаеннан: башлангычы «Безнең юл» булган әдәби журнал да ул елларда, бүлгәләнеп, «Яңалиф», «Атака» исемнәре белән чыккан. Алар урынына уртак «Совет әдәбияты» исемле журналның чыга башлавы – әнә шул берләштерүнең тагын бер чагылышы.

Әзерләделәр:
Луиза Янсуар,
Гадел Хәеров

Их!
Шәһәр гудоклары безне чакрып,
Көрәш таушы белән үкерсә,
Очкын атлар безгә ВКПның
Чакру әмрен тагын китерсә,
Без шәһәргә кире кайтырбыз!
Еллар!..
Авыр еллар,
Сезнең кулыгызда
Күрәчәкне бик күп күрдек без,
Буржуй халкы белән сугышып алдык,
Ертык чалбар киеп йөрдек без!
Әй, сез,
Килер кешеләр!
Әле безнең хатыннарның
Каннарында аккан «түрәләр»,
Менә
Сезгә бабай булыр кешеләр
Шулай итеп газап күрәләр!
Белегез!
Сыйнфый көрәш тарихында беренче кат
Җиңүчеләр булып чыктык без,
Үзебез өчен дүрт кат чүкеч суксак,
Сезнең өчен биш кат суктык без!

Һади Такташ, «Әйдә, энем!»

СССР Язучылар союзының нинди максат белән, нинди социаль нигезгә салынуын аңлау өчен шул чорның атмосферасын күз алдына китереп карыйк. Октябрь инкыйлабы узуга – унбишләп, СССР төзелгәнгә ун еллап вакыт үткән. Советлар Союзында моңарчы күрелмәгән хәл – сыйныфларсыз җәмгыять төзелә. Шәхси милек юк дәрәҗәсендә, күмәк хуҗалыклар төзелгән, авылның хәлле кешеләре сөргенгә җибәрелгән. Актив рәвештә «иске дөньяны җимерү» бара. Кул белән генә түгел, сүз көче белән дә җимерергә кирәк була башлый «иске тормыш»ны. Үзләре яшәргә теләгән җәмгыятьтә үзләре күргә теләгән халык массасы кирәк була ул чор хакимнәренә.

Һәм менә 1934 ел, 17 август. Мәскәү. Союзлар йортының Колонналар залы. Әдәбиятлар тарихында моңарчы мондый җыелышның булганы булмый әле. Гомумән, матур әдәбият иҗат итүчеләрнең махсус танылыкка һәм «язучылар берлеге әгъзасы» дигән рәсми статуска да ия булырга мөмкинлекләре хакында берәүнең дә башына килеп карамый. Җитмәсә, аерым бер идеологиягә хезмәт итәр өчен яратылган булулары...

Яңа көч алып килгән совет системасының башында торучыларныкына килә һәм алар бу мәсьәләне бик зирәк хәл итә: нишләп әле бу каләм тибрәтүчеләр өерен бер түбә астына җыймаска да идарә итмәскә, ди, үзләре белән? Ә язучының дәрәҗәсе һәм халык аңына тәэсир итү куәсе көчле була ул чакта...

Һәм менә 52 милләт вәкилен тәшкил иткән 591 делегат. Кунак сыйфатында төрле кыйтгалардан килгән 40 чит ил язучысы. Со-

Фотолар ТР Язучылар берлеге, ТР Милли музее архивларыннан, Равил Фәйзуллинның «Татарстан Язучылар берлеге» китабыннан алынды

вет язучыларының I Бөтенсоюз оештыру съезды 2 атнадан артык дәвам итә: 17 августта ачыла һәм 26нчыябылу утырышы белән 1 сентябрьдә тәгәлләнә.

Татарстанда бу вакытта солтангалиевчеләрне «фаш итү» тәмамланган гына, татарның иң акыллы, зыялы катлам вәкилләре юк ителгән, куркытылган. Әдәбият дөньясындагы иң эре, олпат фигуралар аренадан китеп бара. Гаяз Исхакый – эмиграциядә, Һади Такташ инде исән түгел, Галиәсгар Камал шулай ук вафат, Галимҗан Ибраһимов – авыру, Казаннан еракта – Кырымда яши, Газиз Гобәйдуллин – Бакуда, Гадел Кутуй, Нәкый Исәнбәтләр, «җидегәнчелек»тә гаепләнеп, әдәби хәрәкәттән читләштерелгән, Гомәр Бәширов, Салих Баттал, Әмирхан Еникиләр әле яшь, башлап язучылар гына санала, канат ныгытып өлгермәгән... «Чистартулар» инде башланган булса да, татарның язучылары әле җитәрлек була. 1934 елның беренче яртысында СССРның төрле почмакларында – республикаларда, өлкәләрдә язучыларның корылтый-съездлары уза, җирле оешмалар төзелә, ил күләмендә узачак зур съездга вәкилләр – делегатлар сайлана. Язучыларның бездәге беренче съезды I Бөтен Татарстан съезды дип атала. Съезд Татар дәүләт академия театры бинасында 1934 елның 25 июлендә ачыла һәм, Мәгариф хезмәткәрләре йортында 4 көн дәвам иткәннән соң, 29 июльдә ябыла. Беренче оештыру съезды, шул заманга хас булганча, тантаналы һәм патетик рухта үтә: почетлы президиум, плакатлар, котлаулар, алкышлар...

Съездны кыскача кереш сүз белән Кави Нәҗми ача. Язучылар союзын оештыру комитеты рәисе Гаяз Ризвановның 3 сәгатьтән артыкка сузылган доклады тыңлана. Съездда Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Кәрим Тинчурин, Риза Ишморат, Фатих Кәрим докладлары тыңлана. Гази Кашшаф, Хәбра Рахман, Гомәр Толымбай, Фәтхи Бурнаш, Әхмәт Фәйзи, Мирсәй Әмир, Шамил Усманов, Ибраһим Салахов, Хәсән Туфан, Муса Җәлилләр катнаша. Оештыру эшләре түбәндәге нәтиҗәләр ясап тәмамлана: Татарстан Язучылар союзының беренче идарә составына 9 кеше сайлана. Болар: Кави Нәҗми (рәис), Кәрим Тинчурин, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай, Хәсән Туфан, Ләбиб Гыйльми, Гаяз Ризванов, Вадим Красный, Кәшшаф Төхфәтуллин

Татар язучылары, журналистлары һәм сәнгать әһелләре милли республикалар буйлап сәяхәт иткәндә (1929 ел). Беренче рәттә (сулдан уңга): Газиз Иделле, Мирсәй Әмир, Гадел Кутуй, Һади Такташ, Демьян Фәтхи; икенче рәттә: Закир Гали, Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Кави Нәҗми; өченче рәттә: Зариф Бәшири, Исмәгыйль Рәми, Гавриил Беляев, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Лев Рубинштейн, Галиәсгар Камал, Салих Сәйдашев, Шакир Шамильский.

Язучы Кави Нәҗми. 1934–1937 елларда ТАССР Язучылар берлегенең беренче рәисе була.

Беренче әдәби журнал «Яңалиф»нең тышлыгы. 1932 ел. 1965 елдан журнал «Казан утлары» исеме белән йөртелә башлый.

Иосиф Сталин белән Максим Горький Кызыл мәйдандагы скверда. 1931 ел.

(секретарь). Бөтенсоюз съездына 12 делегат җибәрергә дип карар кылына. Бу 12 делегатның 9ы – югарыдагы идарә әгъзалары, тагын өчесе – Ибраһим Гази, Галимҗан Нигъмәти, Фатих Сәйфи-Казанлы.

ЯҢА РЕАЛИЗМ ТУДЫРУЧЫЛАР

Совет язучылары союзы оешу турыдан-туры Максим Горький исеме белән бәйле. Ул – аның идея авторы, фактик нигез салучысы.



ДЕЛО

№

Стенограмма I заседания съезда Татарских писателей от 25 июля 1934 года

Начато ... 1934 г.
Окончено ... 19 г.
На 47 листах

Татарстан язучыларының I съезды стенограммасы.

Оештыру комитеты рәисе буларак, совет язучыларының I Бөтенсоюз съездын ул ачып җибәрә. Беркетмә тәртибе буенча, ВКП (б) Үзәк Комитеты секретаре Андрей Жданов нотыгыннан соң төп докладны да Максим Горький ясый.

Ул көннәрнең язма рәвештәге иң ышанычлы шаһиты – съезд стенограммасы. 50 басма табакка якын күләмле документ. Чыгыш ясаучыларның саны 224 кә җиткән чөнки. Максим Горький докладында бик тә гыйбрәтле менә мондый юллар бар: «Мы не имеем право игнорировать литературное творчество нацменьшинств только потому, что нас больше. Ценность искусства измеряется не количеством, а качеством. Если у нас в прошлом – гигант Пушкин, отсюда еще не значит, что армяне, грузины, татары, украинцы и прочие племена не способны дать величайших мастеров литературы, музыки, живописи, зодчества...»

Максим Горькийның татарларга һәм татар әдәбиятына карата аерым бер җылы мөнәсәбәте булуы турында еш искә алырга яраталар. Аның язмышында Казанның зур урын биләвенә дә бәйлиләр бу факторны. Әлеге дә баягы съезд докладында гына да ул татар милләтен телгә алмый калмый. Създда шулай ук милли әдәбиятлар буенча украин һәм белорус вәкиләреннән соң, өченче итеп сүз Татарстан Язучылар берлеге рәисе Кави Нәҗмигә бирелә. Милли әдәбиятларның хәле, торышы хакында Максим Горькийның үз докладын санамаганда, доклад белән тагын 9 халык вәкиле чыгыш ясый. Болар – украин, белорус, грузин, әрмән, азәрбайҗан, үзбәк, төркмән һәм таҗик союзларын тәкъдим итүчеләр. Ә инде делегатларның милли составы ягыннан караганда хәл болайрак була: руслар – 201, украиннар – 30, грузиннар – 28, татарлар – 19 (бу санга башка өлкәләрдә яшәүче татарлар да кергән), әрмәннәр – 19, үзбәкләр – 12, төркмәннәр – 5... Икенче бер гаҗәпләндерә торган фактор: яңа әдәбиятны төзүче каләм ияләренең чагыштырмача яшь булуы. Делегатларның уртача яше – 35, 5 яшь була. 20–30 нчы еллар – феминизм дулкыны, эмансипациянең уянган чоры дип карасак та, хатын-кыз әдипләр мәсьәләсе кискенлеге белән җәлеп итә – нибары 21 хатын-кыз делегат.

Бу съездда шулай ук совет әдәбиятының үзәк принцибын тәшкил итәчәк нигез буларак «социалистик реализм» да кабул ителә. Уставта менә нәрсә диелгән: «Социалистический реализм обеспечивает художественному творчеству исключительную возможность проявления творческой инициативы, выбора разнообразных форм, стилей и жанров».

Съезддан рухланып, канатланып һәм яңа өметләр белән сугарылып кайта язучылар. Эшкә тотыналар. Язучылар съезды оешып, анык бер эш ысулы билгеләнгәч, әдәби хәрәкәттә җанлану сизелә башлый. 1934 ел тоташтан оештыру эшләренә багышлана: «Кызыл Татарстан»да СССР Советы язучылар союзының Уставы басыла. Июнь аенда Совет язучылары союзына кабул итү Үзәк Комиссиясенең утырышы була. Совет язучылары союзына кандидат итеп Шамил Усманов, Риза Ишморат, Афзал Шамов, Галимтан Мөхәммәтшин, Таҗи Гыйззәт, Әхмәт Ерикәй, Нур Баян тәкъдим ителә. Соңрак Язучылар союзы башлангычы белән төрле секцияләр оештырыла, яшь язучылар белән эшләү буенча консультация бюросы төзелә. Союзның шул чордагы эшчәнлегендә тәрҗемә эшенә, нигездә, русчадан татарчага тәрҗемә итүгә бик зур игътибар бирелә. СССР язучыларының I съездында ил халыкларының әдәбиятларын тәрҗемә аша пропагандалау төп мәсьәләләрнең берсе итеп куелган була. Шулай итеп, 1934 елда Татарстан Язучылар оешмасы каршында тәрҗемәчеләр секциясе эшли башлый. Сүз уңаеннан, «Совет әдәбияты» журналының шул еллардагы тупланмаларын алып карасаң, басманың күп өлеше тәрҗемә әсәрләрдән гыйбарәт икәнлеген абайларга мөмкин. Күрәсең, беренчедән, бездә өстән төшерелгән директива арттырыбрак үтәлгән, икенчедән, язучыларга «яңа реализм» тудыру юнәлешендә әле канат ныгытырга, үз эзен табарга кирәк булгандыр...

Съездда катнашучылар. Беренче рәттә (сулдан уңга): Кави Нәҗми, Алексей Толстой, Максим Горький; икенче рәттә: Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан, Гомәр Толымбай, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти.

Ә аннан массакүләм «чистартулар»ның тагын бер дулкыны күтәрелә. Язучылар съезды узып, оештыру эшләре тәгәлләнеп, барысы да үз җаена салынгач кына, каләм әһелләре баш өстендә кабат канлы айбалта уйнаклый башлый. 1937–1938 еллар тарихта бүген дә иң дәһшәтле битләрнең берсе булып кала бирә. Язучыларның лидеры булып, Союзны оештырып йөргән күпчелек әдипләр кулга алынып, төрмәләргә утыртыла. Әле бер ел элек кенә 25 еллык иҗат бәйрәмен уздырган Кәрим Тинчуринны алалар, Галимҗан Ибраһимовны ябалар. Ибраһим Салахов, Шамил Усманов, Гомәр Толымбай, Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Фәтхи Бурнаш, Гали Рәхим, Җамал Вәлиди, Сәгыйть Сүнчәләй, Фатих Сәйфи-Казанлы, Кави Нәҗми, Фатих Кәрим, Мирсәй Әмир, Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан...

«БЕЗ ЯШИБЕЗ, ТОЙМЫЙ-ТОЕМЛАМЫЙ АЯК АСТЫБЫЗДА ИЛ БАРЫН...»

Мандельштамның атаклы ул шигъри юллары шагыйрьне башта төрмәгә илтеп тыга, аннан һәлак үк итә.

...Его толстые пальцы, как черви, жирны,
А слова, как пудовые гири, верны,
Тараканьи смеются усища,
И сияют его голенища.
А вокруг него сброд тонкошеих вождей,
Он играет услугами полулюдей.
Кто свистит, кто мяучит, кто хнычет,
Он один лишь бабачит и тычет,
Как подкову, кует за указом указ:
Кому в пах, кому в лоб, кому в бровь, кому в глаз...

Асылда, мондый кискен юллар язып тору да кирәкми, тора-бара язучыларны төркемләп-төркемләп алып китә башлыйлар. Бер-берләренә каршы котырту, допрос вакытында ялган язу күрсәтеп иманнарын какшату, кыйнау, психологик басым астында ялган беркетмәләргә кул куйдыру, яла ягу... «Черек күл» сүзе әле бүген дә үзенең дәһшәтле күләгәсеннән ахыргача арынмаган, өлкән буын анда чакырылуның азагы юкка чыгу белән тәмамланырга да мөмкин икәнлеген яхшы хәтерли. Үз совет системасы изеп ташлаган каләм ияләренең язмыш сәхифәләре тоташ канлы эздән гыйбарәт. Мәсәлән, «кызыл идея»гә, совет хөкүмәтенә чын күңеленнән ышанган Шамил Усмановның фаҗигасе. Игътибарның иң үзәгендә торган язучыларның берсе Кави Нәҗми була: Язучылар союзы рәисе, каләм әһелләренең лидеры бит... Тормыш иптәше Сәрвәр Әдһәмованы да кулга алып, лагерьга озаталар. Протоколларга караганда, баштарак нык, үз позициясендә торган Нәҗмине сындыру өчен үтемле ысуллар табыла. Ниһаять, 1940 нчы елда Яңа елга таба төндә азат итеп кайтаралар үзен. Кайтканда ул ярымтере иде, дип искә ала якыннары. Урамда халык бәйрәм итә – Яңа елны каршылый, ә тәмам сындырылган, эштән чыгарылган язучы кабинетында сабыйларча үксеп елый. Ни турында уйлый ул шул мизгелләрдә? «Таракан мыеклы» берәү турындамы? Бәлки... Хәер, тиз арада үзен кулга алып, «яңа тормыш»ның тәрбия ысулларын үзләштерүен исбат итәргә, халык белән бер сафка басарга кирәк була аңа. «Язгы җилләр» әсәренә тотына ул. Киләчәктә бу әсәр Сталин премиясенә лаек дип табылачак. Ә язучы үзе, аңлашыла инде, тулаем акланачак.

Максим Горькийның I Бөтенроссия совет язучылары съездында әйтелгән нотыгыннан өзек:

«Безнең съездның мәгънәсе һәм әһәмиятенә хакында үземнән берничә сүз әйтергә рөхсәт итегез. Безнең халыкларның таралып яткан әдәбияты барлык илләрнең революцион пролетариаты каршында тулы бер бөтен буларак күренергә, яңгырарга тиеш. Безгә тугандаш булган, шулай ук революцион фикер йөрткән башка илләрнең вәкилләре алдында да. Безнең, үзебез алардан күбрәк булганга карап кына, кече милләтләрнең әдәбиятларын инкарь итәргә хакыбыз юк. Сәнгатьнең көче микъдар белән түгел, ә сыйфат белән үлчәнә. Әгәр безнең үткәнебездә гигант Пушкин булса, бу әле әрмәннәр, грузиннар, татарлар, украиннар һәм башкалар әдәбият, музыка, рәсем сәнгате өлкәсендә бөек осталар бирә алмый дигән сүз түгел...»

I Бөтенроссия совет язучылары съезды делегаты Кави Нәҗми съезд вакытында Максим Горькийның дачасына чакырылган була. Аның истәлекләреннән өзек:

«Без анда Башкортостан язучылар берлеге рәисе Афзал Таһиров белән бергә бардык. 50–60 чакрымлап барганнан соң, машина иске парк эченә керде һәм озакламый колонналар белән бизәлгән ике катлы йорт каршына килеп тукталды. Горький безне каршыларга үзе чыкты. Бик дустанә мөнәсәбәттә иде. Ул безне инде башка кунаклар җыелып өлгергән бакчасына дәште, барысы да диярлек съезд делегатлары һәм кунаклары иде анда. Бераздан верандада язучылар оешмаларының алдагы эш стратегиясе турында сүз кузгалды. Милли-әдәби басмалар турында сүз алып барылды, Мәскәүдә СССР халыкларының театрларын булдыру, Октябрьнең XX еллыгына әзерлек.... Әңгәмә төн уртасына кадәр дәвам итте, әле аннан ары да. Өстәл артына утыргач, төрле халыклардан булган язучылар бер-берләренә бик тиз ияләшеп китте, бу дуслар һәм фикердәшләр бәйрәменә әверелде.

Горький мине үз янына чакырып алып, татар әдәбияты, республикабыздагы милли мәктәпләр торышы турында әңгәмә корды. Ул татар әдәбиятының хәле турында гел сорашып тора иде, безгә – татар язучыларына мөнәсәбәте бик хәерхаһлы булды. Ул безне гади һәм анык язарга өйрәтте. Болай ди иде: «Мин татар поэзиясе белән прозасының коры канлы булып үсеп китүен телим».

Равил Фәйзуллинның «Татарстан язучылар берлеге» китабына нигезләнеп әзерләнде.

ӘДӘБИЯТНЫҢ СОҢГЫ МОРЗАСЫ

Аны еш кына оста зәркәнчегә тиңлиләр. Ашыкмый-кабаланмый гына, тирәннән уйлап-уйланып, һәр сүзен үлчәп яза торган әдип иде, диләр. «Еники көнгә ике генә җөмлә язган», диюләрендә дә хаклык бардыр, минемчә. Югыйсә әле үзе исәндә үк тере классикага әверелгән ул иҗатта психологик тирәнлек белән сәнгатьчә камиллек ничек шул дәрәҗәдә бертигез үрелеп бара, яши алыр иде...

Әзерләде:
Луиза Янсуар

МОГИКАННАРДАН СОҢГЫ ДӨНЬЯ

Безнең буын каләм әһелләре еш кына: «Әдәбият-сәнгать мохитендә Еникиләр җитми бүген», – дип кабатларга ярата. Бу – затлылык, гаделлек, кешелеклелек, садәлек җуелып бара дигән сүзләргә бәрабәр. Котылгысыз тизлектә глобализм көчәрендә зырылдап әйләнгән дөньяда әдәбият өлкәсенә дә җимергеч төшенчәләр кереп урнашып бара. Югары кимәлдәге сәнгатьле сүз, тел һәм эстетика, зәвык беренчел кадерен, абруен җуя. Урталыкка курс алына. Теләгән һәркем яза, социаль челтәрләрдә текстларын тарата һәм аларны, сәнгати дәрәҗәсе бик түбән сыйфатта булса да, «әсәр» дип атаудан тайчанмый. Әдәбият турындагы күзаллаулары шулай ук шактый уртакул булган затлар авторлыкка, язучылыкка дәгъва итә. Бу «каләм әһеле»нең дәрәҗәсе төшү, кризис кичерү күренеше дигән сүз. Рухи-психологик идеология кысаларыннан азат булып, сатучылык һәм кәсепчелекне әләм итеп яшәүгә күчкән Россиядәге «сәер капитализм» шартларында сәнгати курс белән баручы җитди каләм әһелләре «үткән дәвер калдыгы», авыр хәрәкәт итүче динозаврлар, соңгы могиканнар рәвешендәрәк кабул ителә хәзер...

Еникилар чоры дигәндә, без әнә шул югалып барган абруйга һәм шәхескә сусыйбыз. Аксакаллыкка. Иманга. Үз кыйбласына тугрылыкка. Морзалык төшенчәсенең төп асылына. «Морза» титулы бит ул, беренче чиратта, аксөяк, дворян, дигән сүз. Ә тарихтан яхшы беләбез: инкыйлаблар һәм илдәге өзлексез «чистартулар» нәтиҗәсендә кырып ташланган борынгы затлы нәсел, катламнарның хәкарәт итмәслек какшамас кануннары булган. Ул кануннар хакына кеше, иманына хыянәт итмичә, кайчак каны белән дә җавап биргән.

Затлылык сүзенең тамыры ук – «зат» сүзеннән, шунысын да онытмыйк. Димәк, билгеле бер затның, шәхеснең үз чорында, яшәгән вакытында хәлиткеч роль уйный алуы да, үзе һәм башкалар өчен җавап тотуы да, дигән сүз бу. Еникиләр чорындагы әнә шул җаваплылыкны бүгенге каләм әһелләреннән күпмебез үз җилкәсенә

«ТАЯНЫРЛЫК РӘТЛЕ КЕШЕ ИДЕ»

– Минем өчен таянырлык рәтле кеше иде ул. Үзе дә мине шулай санагандыр, дип уйларга җөрьәт итәм. Чөнки «Юлчы» җыентыгының титул битенә шул хакта язган иде. Халык өчен ул исән чагында ук тере классик булды. Гәрчә аның да иҗат юлы шома гына була алмады. Тәнкыйтьчеләрнең тискәре мөнәсәбәтенә түзеп яшәде ул. Авторитар тәнкыйтьнең бертуктаусыз изүенә карамастан, үз мәсләген үзгәртмәде. Үтә кызыл әсәрләргә таба борылмады.

Ул «иҗат азатлыгы» дигән сүзләрне еш кабатлый иде. Миңа карата да әйткән сүзләрен хәтерлим: «Дөньяны үзең күргәнчә тасвирлау хокукы». Бик тырышсалар да, аны шул хокуктан мәхрүм итә алмадылар. Еникинең барлык уңышлары әхлакый ныклык белән аңлатыладыр, дип уйлыйм. Аның иҗаты чит тәэсирләрдән азат.

Әхсән Баянов

Фотолар: Татарстан Язучылар берлеге, «Сөембикә» журналы архивыннан

алырлык кодрәткә ия? Без аларның рухы һәм иманы алдында да җавап тотарга әзерме?

«МОРЗАЛАР КАРГАЛЫСЫ»

Әмирхан Еники (Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникеев) 1909 елның 17 февралендә (яңа стиль белән 2 мартта) элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязендә (хәзерге Башкортостанның Благовар районы) Яңа Каргалы авылында туа. Булачак язучының бабалары бу җирләргә Тамбов губернасыннан XVIII гасыр ахырында күчеп утырган: «Безнең борынгы төп җирләр Россиянең үзәгендә, тагын да конкретлаштырып әйткәндә, Темников дигән шәһәр тирәсендә икән – без әнә шуннан чыккан халык», – дип яза Әмирхан Еники үзе.

Каргалының бер катлау кешеләрен «морзалар» дип атап йөрткәннәр. Бу зур дәрәҗәле исем булган, титул рәвешендә исәпләнгән. Тирә-юнь авылларны да, бер бөтенгә җыеп, «морзалар Каргалысы» дип атаганнар.

«Тамбов җирендә чакта авылның исеме «Иди» булган, диләр. (Ә борынгы исеме Сары-Кылыч булган, Алтын Урда заманында руслар шулай дип үзгәрткән, имеш; хәзер Мордва Республикасына керә). Каргалының ярты халкы диярлек Еникеевлар иде. Гомумән, бу авылда һәркемнең фамилиясе ата-бабасыннан күчеп килгән фамилия – бездә үз атасының исемен фамилия итеп алу бөтенләй булмаган. Шуңа күрә Каргалыда фамилияләр күп түгел. Иң күбесе Еникеевлар, аннары Терегуловлар, аннары инде Янгуразовлар, Утяшев, Сундюковлар һ.б.китә. Кемнәр соң ул Еникеевлар?

Кайчандыр, ерак заманда Бихан исемле бер князь (бәк) яшәгән. Шушы Биханнан торабара Кугушев, Кутуев, Муратов фамилияләре үрчеп, тармакланып чыккан. Ә Кугушевлардан берсенең исеме Еникей булган икән, димәк, болай була: Бихан, берничә буын аша Кугуш, аңардан Еникей. Бу Еникейдән тагын биш ир бала туган: Алакай, Идей, Терегол, Усангали, Иртуган...

Әлбәттә, фамилия тарихы ул – буыннар тарихы, әмма бик озын тарих. Шуңа күрә бик кысыпҗыеп кына мин үзем турында болай дип әйтә алам: ерак гасырлар түреннән, гүя Азов диңгезе томаннары эченнән чыгып, Ука-Мокшы елгалары буена күченеп килгән, шунда төпләнеп күпмедер заманнар үзенә-үзе хуҗа булып яшәгән, соңыннан исә төрле тарихи һәм иҗтимагый сәбәпләр аркасында төп урыннарын ташлап, башкорт җирләренә күчеп утырырга мәҗбүр булган «төмәннәр»нең бер гаиләсендә 1909 елның иске стиль белән февраль аенда мин дөньяга килгәнмен...»

Бәләкәй Әмирхан якты дөньяга унынчы бала булып килә. Аңа кадәр әнисе Бибихәдичәнең һәм әтисе Нигъмәтҗанның тугыз баласы сау-таза булып туып та, берсе дә исән калмый. Кайсы кызамыктан, кайсы чәчәк авыруыннан, кайсы эч авыруыннан китеп баралар. «Шуннан соң мин менә унынчы бала! Мине корбаннар чалып, нәзерләр әйтеп, Алладан сорап алганнар. Мин һичшиксез яшәргә тиеш булганмын! – дип яза әдип. – Атакайның Дәүләкәнгә күчүе беркадәр шул теләк белән дә булмадымы икән? – чөнки балалары тормаган иске урынны (Каргалыны) ташлап китүне үзләренчә хәерлегә юраулары бик мөмкин. Яңа урында бит яңа өметләр дә туа...»

Атасы бу фактны китап битенә менә ничек теркәп куйган: «Бән морза Нигъмәтҗан Әхмәтҗан улы Еникеев алдым ошбу каләм шәрифне 1908 елда 28 гыйнварда Эткол ярминкәсендә. Бәһасе 65 тиен көмеш, һәм ушандук каләми шәрифне 1909 елда 16 февральдә пәнҗешәмбе көн дөньяга килмеш углым Әмирханга һибә кылып бирдем. Алла Тәгаләдән озын гомер, бәхет һәм тәүфыйк сорап, ошбу әлмөхәссәр шәрифне хәтем көтеп кылырга насыйп итсен иде. Амин».

Әмирхан Еники язучы, драматург Туфан Миңнуллин белән.

Язучының әнисе Бибихәдичә бик сабыр, акыллы хатын була. Алар ире белән бик килешеп, бер-берсен яратышып яшәгән. Әтисе Нигъмәтҗан крестьян эшеннән читләшеп, сәүдәгәрлек кыла башлаган була улы тугканда. Әтисе турында болай искә ала Еники: «Ни дәрәҗәдә оста сәүдәгәр булгандыр – монысы икенче мәсьәлә. Ул бит, асылда, хис кешесе иде, җыр, уен-көлке яраткан һәм җан иясен дә бик ярата иде. Бервакытта да аның кулы җан иясенә күтәрелмәде – атка да ул сөеп, сыйпап кына дәшә иде. Кирәк чагында без тавыкны да күршеләрдән суйдыра иде...»

СӘҮДӘГӘР БАЛАСЫ

Яңа урынга – Дәүләкәнгә күченгәч, тагын бер уллары – Илдархан дөньяга килә. Бу ике угланны кан калтырап, саклап калырга тырышып үстерәләр.

Әмирхан Еники Уфада «Тулпар» редакциясендә кунакта. 1990 нчы еллар.

Әмирхан гаиләдәге тигезлек, ярату атмосферасында тәрбияләнә, аның иреген чикләмиләр, әтисе белән әнисе үз ихтыярларын такмыйлар. Ике углан да ирек төмен тоеп, шул ук вакытта затлы, яхшы тәрбия дә күреп үсәләр.

Әмирхан балачактан матур әдәбиятка тартыла, тора-бара театр белән кызыксынып китә. Ул Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын яратып укуы турында искә ала: «Коръәннән дә калынрак бу роман мине тәмам йотты, әсир итте, без аңардан аерыла алмас булдык, тиз генә бетмәвен, уку рәхәтенең бер дә өзелмичә дәвам итүен теләдек».

Шулай бервакыт Дәүләкәнгә татар артистлары Нәгыймә Таҗдарова, Маһирә Мирвәлиева, Нури Сакаев, Шакир Шамильскийлар килеп чыга. Гастрольдә йөргән бу атаклы шәхесләр Еникиләр йортында берничә кич куна. Еники алардан тәмам бихуш була. Җитмәсә, яшь малайга суфлер вазыйфасын йөклиләр. Бу очрашуны гомере буена исендә тота. Инде танылган әдип булып өлгергәч, шәхесләрнең истәлегенә багышлап китаплар да яза Еники.

«Соңгы китап»тагы факт буенча, Еникиләр гаиләсе Дәүләкәндә 1918 елның җәендә яши башлый: «Яңа йортка – инде үзебезнең йортка 1918 елның июнь башында күчендек. Мактанудан булмасын, йорт үзе дә, утырган җире дә бик әйбәт. Күрү белән яраттык без аны. Төп урамның уртарак бер төшендә, мәчетмәдрәсәгә дә якын, базардан да ерак түгел... Йортыбыз калай белән япкан, ике катлы, түбән каты җиргә кертеп таштан, ә өске каты бүрәнәдән салынган. Урамга өч тәрәзәсе карый, парадный дигән ишеге дә бар. Капка-коймасы кызылга буялган, шуңа күрә аны «кызыл йорт» дип тә йөрткәннәр».

1925 елда 16 яшьлек Әмирхан, газетадагы игъланны күреп, Ка-

занга, үзе истәлекләрендә язганча, «рәссамчылык, һәйкәлтараш, гаймарәт остаханәсенә» (архитектура-сәнгать остаханәләре – ред.) укырга килә. Өйдән зур акчаларга, ярдәмгә өмет итә алмаса да, аның исем-аты шунда ук тарала: «сәүдәгәр баласы килгән». Моны белеп алганнан соң, Әмирханны стипендиягә билгеләнүчеләр исемлегеннән сызалар.

Аптырап, каңгырап йөргән көннәрнең берендә ул «Шәрык» китапханәсенә килеп керә. «Шура», «Аң», «Сөембикә», «Ак юл» кебек газета-журналлар алып укый. Монда йөрергә иялəшеп китә. Китапханә мөдире Вафа Бурнаш (язучы Фәтхи Бурнашның энесе) Әмирханга китап кибетенә эшкә урнашырга ярдәм итә. Шулай итеп, Әмирхан әдәбият мохитенә килеп керә, әдәби җыеннарда, утырышларда катнаша башлый. Һади Такташ, Гадел Кутуй, Гомәр Толымбайский, Садри Җәләл кебек әдипләр белән аралаша, үзе дә кулына каләм ала. 1926 елда аның башкорт тормышыннан алып язылган «Озын көй тыңлаганда» исемле беренче хикәясе дөнья күрә.

Шул елның көзендә Әмирхан Еники университет рабфагына укырга керә. Үзен, кабат сәүдәгәр малае дип атап читләштерерләр, кагарлар, дип өркеп, кустарь баласы булярак күрсәтә. Әйбәт кенә укып йөргәндә, Дәүләкәннән килгән яшьләр: «Син үзенең чыгышыңны яшерәсең, әйтмәсәң, без сине рабфактан кудыртабыз», – дип янаелар. Әмирхан Еники, бу сүзләрдән соң академик ял алып, Донбасска китеп бара. Донецкида наданлыкны бетерү курсларында шахтерларны укыта. Биредә дә каләмен ташламый, «Кара күмер илләрендә» дигән шахтерлар тормышын сурәтләгән очерклар шәлкемен яза.



Язучы үзенең эш бүлмәсендә.

«ЯРАКЛАШУ ЮЛЫ – МИНЕМ ЮЛ ТҮГЕЛ...»

1928 елда Әмирхан Еники Казанга әйләнеп кайта. Хикәяләр иҗат итә, аларны матбугатка тәкъдим итә. Әмма берсе дә зур әдәби вакыйга булып китә алмый. «Бер каты бәхәстә, – дип яза ул истәлекләрендә, – миңа турыдан-туры әйттеләр: «Синең нәрсә уйлавыңда безнең эшебез юк, нәрсә уйласаң да, син без таләп иткәнне язарга тиешсең», – диделәр. Бу нәрсә минем аңыма сеңми... Мин үзем инанганны, үзем аңлаганны язарга тиеш дип йөри идем, юк, ярашу, яраклашу юлы минем юл түгел...» Замандашлары, каләмдәшләре фаразынча, аның әдәбиятка килүе шуңа да 10–15 елга сузыла.

1928 елда Әмирхан Еники Казан мех комбинатына эшкә керә. 1930 елда Хезмәтне фәнни оештыру институты семинарларында укып йөри. Аны уңышлы тәмамлый, белемгә сусавы бик көчле була, аспирантурада кала. Ләкин Казандагы бу институт ябылып, Свердловскига күченгәч, яңа гына гаилә корып җибәргән Еникинең дә планнары үзгәрә. Бакудагы

«ӘФСЕНЛЕ КӨЧЕН ЯХШЫ БЕЛӘ...»

– Әмирхан Еники турында сүз әйтү бер үк вакытта читен дә, рәхәт тә. Читен, чөнки ул бик катлаулы, үтә дә нечкә күңелле художник. Әйтә белмичә әйтсәң, тота белмичә кулдан төшереп ваткан хрусталь ваза кебек, аның иҗатын чәлпәрәмә китерүең дә мөмкин. Рәхәт, чөнки аның иҗаты уйланырлык азык, күңелгә шатлык, колакка музыкаль аһәң бирә.

Яшь, зифа буйлы, кара чәчле, мөлаем егет, ул әдәбиятка ничектер кыяр-кыймасрак килеп керде һәм хәзергә хәтле, башы пеләшләнә башлагач та, уннарча повесть һәм бик күп талантлы хикәяләр авторы булгач та, безнең барыбызның да, иң әһәмиятлесе, киң катлау укучыларның ихлас мәхәббәтен казанганнан соң да, шулай кыяр-кыймас кына барган кебек. Аның бу тыйнаклыгы үзенең көчен белмәгәнлектән түгел, юк, ул үзенең әфсенле көчен бик яхшы белә, аның бу тыйнаклыгы халык алдындагы бурычын тирәнтен аңлавыннан. Юк, әдәбият уйнар өчен түгел, әдәбият дан казану, акча эшләү мәйданы да түгел, әдәбият – энә белән кое казу, әдәбият – кеше күңелен тәрбияләү, әдәбият кешеләрне яхшы булырга, көннән көн яхшырак була баруга этәрү коралы. Без менә шул бөек бурычны үтибезме? Барыбыз да бертигез үтибезме? Әмирханның тыйнаклыгы, минемчә, әнә шул сораулардан килеп туадыр кебек.

Фатих Хөсни

«Азеркино» трестында, Маргиланда наданлыкны бетерү курсларында эшләгәндә Еники бик күп кешеләр белән аралаша, тормыш тәҗрибәсе туплый...

Сугыш башлану турындагы хәбәрне ул Ташкенттан Казанга кайтып килгәндә поездда ишетә. Төньяк-Көнбатыш фронтының резервта торучы гаскәрләренә килеп эләгә. Сәламәтлеге начар булу сәбәпле, аны алгы сызыкка җибәрмиләр.

Әнә шул кырыс, кискен шартларда, үлем белән күзгә-күз калганда язучы тугандыр, дип исәпли

Әмирхан Еники песие Аппак белән.

«Безнең өстә әле хәрби кием дә юк. Гражданский киемнәрдән йөрибез. Август кичләре суык була башлады. Менә бер төнне машина белән кием-шинельләр китереп бушаттылар. Тартыша-тартыша үзебезгә кием сайлый башладык. Кайсы озын, кайсы кыска. Һиһаять, мин дә үземә ярагандай бер шинельне сайлап киеп алып, билемне буып җибәрдем. Икенче көнне яктыда карасак, бу шинельнең чабулары – тотош кан. Шул шинельне киеп байтак йөрдем әле мин. Күрәсең, ул үлгән кеше киеме булган инде...»

ул үзендә. Олы тарихи панораманы сурәтләүне, эпик формада иҗат итүне өнәмәве дә Еникине үз чорының күпчелек әдипләреннән аерып тора, ул детальләр, нюанслар аша кеше психологиясенең, күңеленең иң тирән төпкелләренә төшә алган язучы.

1941–1945 елларда әдип хәрәкәттәге армиянең хуҗалык һәм каравыл частьларында рядовой солдат булып хезмәт итә. Армиядән кайткач, берникадәр вакыт «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр, аннары Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар бүлеге мөхәррире булып эшли, 1950–1952 елларда Казан авиация техникумында татар теле укыта. 1953 елда ул бөтенләе белән профессиональ язучылык хезмәтенә күчә.

Аерым журналистик язмалары һәм «Дус кеше» (1929), «Пожар» (1929), «Никуличева һәм аның иптәшләре» (1934), «Көзнең бер кичендә» (1939) шикелле повесть, хикәяләре белән сугышка кадәр үк матбугатта исеме күренгәләсә дә, Әмирхан Еники үзенчәлекле язучы буларак, нигездә, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда формалаша. Аның «Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Бер генә сәгатькә» (1944), «Ялгыз каз» (1944), «Мәк чәчәге» (1944), «Кунакчыл дошман» (1945), «Тауларга карап» (1948), «Кем җырлады» (1956) кебек хикәяләре татар психологик прозасын яңа баскычка күтәрә.

Тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын анализлауда психологик тирәнлеккә омтылу 1950–1970 еллар иҗатында әдипкә тагын да зуррак уңышлар алып килә. Язучының «Рәхмәт, иптәшләр!» (1951–1952), «Саз чәчәге» (1955), «Йөрәк сере» (1957), «Рәшә» (1962), «Вөҗдан» (1968), «Без дә солдатлар идек» (1971), «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) исемле повестьлары, «Ялгызлык» (1957), «Туган туфрак» (1959), «Матурлык» (1964), «Төнге тамчылар» (1964), «Коръән хафиз» (1964), «Әйтелмәгән васыять» (1965), «Курай» (1970), «Тынычлану» (1978) кебек хикәяләре заманны борчыган әхлакый-этик проблемаларны кыю рәвештә күтәрүе белән бергә, сәнгатьчә камил эшләнүләре җәһәтеннән дә аерым игътибарга лаек.

Без Еникине нигездә психологик проза остасы буларак кабул итәргә гадәтләнгәнбез. Әмма аның

«ЗУР ЭШЛӘРГӘ ДӘРТЛӘНДЕРӘ...»

– Күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли аның әсәрләре... Гүяки алар каләмне язу карасына түгел, ә бәлки хискә – моңгасагышка манып язылганнар. Аның әсәрләрендә, моң-сагыш белән бергә, сине сафландыра һәм пакьләндерә торган, сине баета, зур эшләргә дәртләндерә һәм канатландыра торган рухи көч тә бар... Шуңа да җаныңны кая куярга белми бәргәләнгәндә кулыңа Әмирхан Еники әсәрләрен аласың.

Укыган саен укыйсы килеп тора аның әсәрләрен. Күбрәк укыган саен, иҗатының сихри көченә соклану хисе арта, шуның сәбәпләрен беләсе, ачасы килү теләге көчәя. Шуның белән бергә, тормышның үзе кебек үк гади һәм табигый, тормышның үзе кебек үк катлаулы да аның иҗаты. Бер-ике әсәрен санамаганда, Еники әсәрләренең идеясе бервакытта да «мин монда!» дип, алга чыгып кычкырып тормый. Идея образга тәмам сеңеп, аңа кушылып, эреп беткән була. Язучы укучы аңына юлны аның йөрәге аша сала белә. Бу – бары олы художникларга гына хас бер сыйфат булса кирәк.

Фәрваз Миңнуллин

иҗатында юмор-сатира, әдәби тәнкыйть, очерк, публицистика, мемуар жанрлары да зур урын били. Гомумән, юмор-сатира Еники язу стиленең мөһим хасиятләреннән берсе булып, аның элементлары теге яки бу күләмдә язучының һәрбер әсәрендә диярлек очрый. Автобиографик материалларга нигезләнеп язылган «Соңгы китап» исемле документаль повесте – без бүген, модага ияреп, «нон-фикшн» дип йөрткән жанрның уникаль бер үрнәге.

Еники – әдәби тәрҗемә остасы. Шактый гына рус язучыларының, Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим» һәм башка повестьларын, СССР әкиятләрен татар теленә нәкъ менә аның тәрҗемәсендә укыдык без. Аның үзенең дә төп әсәрләре рус теленә һәм башка милли телләргә тәрҗемә ителгән.

Әмирхан Еники 2000 елның 16 февралендә Казанда вафат була, Яңа бистә зиратына җирләнә.

«Курай дисәм, Еникине уйлыйм...», – дип язган иде аның турында кайчандыр шагыйрь Зөлфәт. Шул шигырьдә бик тә гыйбрәтле мондый юллар бар:

Кызганам мин
бездән соңгыларны–
Сәер
Алар кичәр дөньялар.
Бу кыңгырау чыңын ишетмәс тә,*
Ишетсә дә
тоймас бит алар!

Аксакаллы туры килде язмыш...
Безнең гомер
монда үтәчәк,
Шушы моң бетәрме?
Бетә икән,
Димәк,
дөньясы да бетәчәк.

Юк, ышанып булмый!
Сүнәр көннәр
Килмәс...
Казан төнен кабыза.
Асыл курай булып,
милләт өчен,
Һаман моңлан, Еники морза!

**Әмирхан Еникинең «Җиз кыңгырау» әсәренә ишарә.*



Фото: Флера Карташова һәм Резеда Тюменева архивыннан.

Әмирхан Еники – Хезмәт Кызыл Байрагы (1979) һәм «Почет Билгесе» (1957) орденнары иясе. 1984 елда аңа «Юлчы» хикәяләр җыентыгы һәм русча тәрҗемәдә басылган «Повести и рассказы» (1982) китабы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирәләр. 1989 елда «Татарстанның халык язучысы» дигән исемгә лаек була.

«ҮЗ ГАМӘЛЕНӘ ХУҖА ЗАТ»

– Әмирхан ага гомере буе үз гамәленә үзе хуҗа булган зат. Сабыр-тыйнак кына, кабаланмыйча, очар биеклекләрне анык белеп, узгынчы сәяси-конъюнктур хәрәкәтләрдә буталмыйча, талантының кодрәтен, шәхес буларак үз дәрәҗәсен белеп яшәде, иҗат итте. Бу очракта чыгышы ягыннан мәгълүм ыру-токымнан, затлы нәселдән булуы да шактый ук әһәмиятле булса кирәк. Һәр иҗатчы, телиме-теләмиме, таныймы-танымыймы, ул – барыбер Вакыт галиҗәнаплары белән алышка чыккан зат. Чарасызлыкны, Вакыт кодрәтенә беркемнең, бернәрсәнең дә каршы торалмаганын белсә дә, Иҗатчы, Вакытның «ялына ябышып булса да», хезмәтләре белән Аңа үз исеме белән мөһер суга...

Иҗаты һәм яшәү рәвеше белән килер буыннарга, бигрәк тә каләм ияләренә, бик тә кирәк әхлакый сабаклар бирде Әмирхан агабыз. Шуларның берсе (гәрчә аксиома кебек мәгълүм булса да) –язучы нинди генә заманда, нинди генә шартларда яшәп иҗат итсә дә, вөҗданына тугры калып, көндәлек мәшәкатьләрдән өстен торып, тормыш дөреслеген язарга тиеш. Бу – Аның язучылык кредосы иде, күпләр өчен өлге булыр сыйфаты.

Равил Фәйзуллин



Фредерик Бакман – швед язучысы һәм блогер. 1981 елның 2 июнендә Стокгольмда туа. Хельсинборг шәһәрендә үсә. Дин тәгълиматын үзләштерә, әмма озакламый укуын ташлый да йөк машиналары йөртүче булып эшкә урнаша. 2006 елда газета-журналлар өчен мәкаләләр яза башлый. Ел ярымнан соң фриланска күчә.

2009 елда өйләнә, әти була, аның тәүге блогы да «Туй блогы» дип атала. 2010 елда ул Кышкы Олимпия уеннарына багышланган сайтта блог алып бара. Шуннан бирле бу блог даими эшли.

2012 елда Бакман язучы буларак дебют ясый. «Вторая жизнь Уве» китабы бүгенге көнгә кадәр дөньякүләм билгеле бестселлерлар исемлегеннән төшми. Берничә мәртәбә өстәмә тираж белән бастырылды.

БЕЗ КЕМ ЧЫНБАРЛЫГЫНДА ЯШИБЕЗ?

Автор:
Луиза Янсуар

Бу юлы без рейтинг күрсәткечләре буенча соңгы ике елда иң популяр һәм күп укылган китапларга тукталырга булдык. Һәм – аларны контрастта карарга.



«КЕШЕ НӘРСӘ ӨЧЕН КӨРӘШКӘНЕН БЕЛЕРГӘ ТИЕШ...»

ФРЕДЕРИК БАКМАН, «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ УВЕ»

Фредерик Бакманның сатылу буенча дөнья күләмендә лидерлар рәтенә кереп урнашкан бу китабы укыр өчен җиңел дә, авыр да. Ул бик гади һәм рәхәт тел белән язылган (безнең очракта, тәрҗемә ителгән, дияргә кирәк, билгеле), сюжет линиясе дә, композицион корылыш та – үтә гадәти. Автор бер генә нәрсәне дә катлауландырмый, чөнки ул тормышны катлауландыручыларын, бер урнашкан кагыйдәләрне, традицияләрне бозуларын яратмый торган гади бер зат турында яза. Әмма бу гадилекнең аргы ягында шулкадәр тирән, тормышчан фәлсәфә ята ки, син аның әнә шул үтә табигыйлегеннән әсәренеп каласың...

Йә, ярый, кем соң ул – Уве дигәнебез? Картаеп баручы гап-гади бер саран һәм мыгырдавык адәм, дияр иде, аны юлында очраткан һәркем. Андыйларга без үзебезнең урамнарда, подъездларда, җәмәгать транспортында, кибетләрдә дә даими юлыгып торабыз. Алай гына да түгел, өйләребезгә кайтып кергәч тә, маңгайга-маңгай бәрелешәбез. «Территориягә керү тыелган икән, димәк тыелган!» – дип, автомобиль каршына кулын бөеренә куеп килеп баскан урам себерүче дә булырга мөмкин ул. «Нигә товарга сыттама дип язгансыз икән, кайсы көннәрдә икәнен дә реклама буклетында күрсәтмисез!» – дип гауга куптаручы сатып алучы да... Роман укучылар арасында популярлык казанганнан соң, социаль челтәрләрдәге тасмада еш кына мондый гыйбарә килеп чыга башлады: «Безнең һәрберебез дә бераз гына Уве булса, бәлки, тормыш яхшырак якка борылыр, тәртипкә керер иде...»

Парадокс тоелса да, бу сүзләрдә хаклык бар. Тоташ хаоска әверелеп барган, кыйммәтләр асты өскә килгән бу буталчык дөньяда кешеләрнең ул мыгырдавык, сукранучан, эчпошыргыч, кысмыр, искегә ябышып яткан Увелар буыныңдагы тәртипкә, ышанычка сусаулары – гыйбрәтле күрсәткеч. Әйе, ул «иске кагыйдәләр» һәм «югалып барган кыйммәтләр» тарафдары, әйе, ул җәмгыятьнең уңайсыз бер элементы... Әмма сюжет барышында абайлап аласың: нәкъ менә шушындый «кечкенә кешеләр»гә таянып торган да җәмгыять. Ә хәзер һәрберсе әллә кем булган, әмма шапырынудан узмаган инфантиль бәндәләр... кыен вакытта әнә шул Уве кебекләргә таяна һәм тотрыклылыгын саклап кала ала. Ә менә Увелардан соң... кемгә таянырбыз? Бу сорау үзеннән-үзе калка. Дөрес, алар хәзерге яңа буын өчен көлке, әкәмәт тоела... Алар мыскыллауга гына лаек шикелле... Әмма теге буын намус эше итеп санаган дөреслеккә алмашка без нәрсә тәкъдим итә алабыз соң? Йә – ни белән мактана?!

Кеше үз тормышында нинди дә булса файдалы функция, вазыйфа башкарырга тиеш. Менә Уве, җәмгыять аңардан ни таләп итте, шуны бар көче белән үтәде. Эшләде, чирләмәде, өйләнде, кредитлар, налоглар түләде, намус кушканча яшәргә

Фотолар: livelib.ru сайтыннан алынды

тырышты, ахыр чиктә, гомере буена «дөрес» машинада – үз ватанында чыккан «сааб»та йөрде, аны чит маркаларга алышып, хыянәткә бармады. Йә, шушылардан соң җәмгыять аны ничек бәяләде? Ул гомере буена бер генә көнне дә калдырмый эшләгән конторага җитәкче урынга кереп кунаклаган ике «маңка малай», ягъни яңа босслар, аңа: «Сиңа ял итәргә вакыт, Уве, бар өеңә...» – диделәр. Һәм менә дүшәмбе иртәсе җитте. Пенсионер Увеның шушы көннән башлап бернинди файдалы вазыйфасы да юк иде инде...

Нәкъ менә дүшәмбе иртәсендә беренче тапкыр танышабыз без Уве белән. Ул озак еллар буена башкарган иҗтимагый вазыйфасы – үзләре яшәгән торак комплексының территориясендә тәртипме, юкмы икәнлеген контрольдә тотуны җиренә җиткереп үтәгән вакытта. Менә, йорты каршындагы территориядә хуҗасыз мәчене очратып уфтана ул, аннары күрше этенең тиешсез җирдә йомышлавын күреп алып, буза куптара, кирәкмәгән урында машина куйганнарын күреп алып, кайнап чыга, ә иң ачуын кабартканы – территориягә машина белән узып керүләре була... Җитмәсә, йөк машинасы! Җитмәсә, йөртүчесе, аны тар аралыкта тиешенчә бора алмыйча, Увеның почта баганасын җимерә. Инде йодрыкларын төйнәгән Увены бер генә нәрсә туктатып кала: машина йөртүченең нәкъ Уве кебек үк сукранган һәм көмәне борынына җиткән хатыны белән ике кечкенә генә кызы.

– Минем исемем Парване, – дип, авызы колагына җиткәнче елмая, кыяфәтенә караганда, йә һиндлы, йә иранлы булырга охшаган бу дегет сыман кара чәчле, янып торган кара күзле ханым. Һәм швед иренә – Патрикка – ишарә итеп, аның мәхлуклыгын кичерүләрен үтенә. Һәр нәрсәдә тәртип яратучан Увебыз, машинаны борып бирә дә, сукрануын дәвам итеп, өенә юнәлә. Аны анда бик тә җитди «эш» көтә чөнки – бу бер мәгънәсе калмаган тормыш белән, ниһаять, араны өзү. Ә менә кешеләр, мәхлуклар, гел кирәкмәгән гамәл кылып, Увены бүлдерәләр...

Ул ниятен тормышка ашырырга җай табып, инде урындыкка менеп кенә баса, ишектә тагын кыңгырау чылтырый. Дулап барып ачса, томырылып ике пар шомырт кара күз төбәлә үзенә:

– Әни сезне... ач булганга, шундый ачулы, диде. Менә сезгә шафран белән дөге, – дип, контейнер суза Парваненың кызлары. Уве ризыкны үзе белән алып керә дә, коридордагы элгечтә эленеп торган хатын-кыз пәлтәләренә йөзен яшереп:

– Бик читен миңа синнән башка... – дип пышылдый.

Ул пәйда булганчы, Увеның тормышы ак һәм кара төсләрдән генә тора иде. Соня аның тормышын кулына пумала алып буягандай итте: дөньяда булган бөтен башка төсләрне өстәде.

Һәм без үлгән хатыны Соняның каберенә көн дә чәчәкләр илтеп, аңа тормышның һәм кешеләрнең сәерлеге турында уфтанып сөйләшүче Уве белән дә танышабыз. Бер иртәдә җәбер күреп, яраланып, карга катып үлеп баручы йортсыз мәчене коткарып: «Ул песи – сиңа, син аңа кирәк!» – дип кырт кискән Парванега колак салган, ә аннары бу җан иясендә яшәү мәгънәсе тапкан, үлем турында уйлаудан туктаган Уве белән дә. Һәм менә көннәрнең берсендә үз гомерендә бала бәхетеннән мәхрүм булып, картайганчы инвалид хатыны Соняны тәрбия кылып яшәгән Уве кинәт, ике кара чутыр кызчыкның үзен «бабай» дип атауларын абайлап алып, телсез кала. Үз әти-әниләренә таяна алмаган һәм кайчандыр коррекция классына укырга бирелеп, «юньсез» саналган, җәмгыятьтән тибәрелгән үсмерләрнең аңарга ихтирам белән каравын тоеп та, чиксез гаҗәпләнә.

– Сезнең хатыныгыз мине юньсезгә санамый иде. Ул безгә Шекспирны өйрәтте, – ди бу малайларның берсе Увега...

Уве исә, маңгаен җыерып, әлеге «урам карачкылары»на үзенең кыска гына, гыйбрәтле хакыйкатен кистереп сала: «Ир-атны сүзе буенча бәяләмиләр, ә эше буенча». Ә аннан кинәт кенә кысмыр, кеше сөймәүчән Уве аларның берсен үз өендә яшәргә калдыра, көтмәгәндә-уйламаганда пәйда булган «оныгына» туган көненә бөтен җыйган акчасына айфон алып бүләк итә, алай гына да түгел, үз йортын Парване белән «мәхлук» Патрикның туачак сабыена мирас итә... Аның тагын бер бик гади-

гадәти дә, әмма ул чын күңелдән инанган хакыйкате бар чөнки: «Бу дөньяда һәрбер кеше нәрсә, йә кем өчен көрәшкәнен белергә тиеш». Аның дөреслеге кызы кебек якын булып өлгергән Парваненың: «Вакытны үләр өчен дә сарыф итеп була, яшәр өчен дә», – дигән сүзләренә гаҗәеп рәвештә туры килә...

Бүгенге җәмгыятьтә кеше картаеп өлгермәстән «искерә», кирәксезгә әверелә. Тулы бер ил белән үз эшен намуслы рәвештә җиренә җиткереп башкара белмәүчеләрне алкышлыйлар, күккә чөяләр. Бу җәмгыятьтә башка берәү дә диярлек үз кулы белән машина шиннарын алыштыра белми. Өенә чыбык суза. Идәнгә плитә җәя. Стеналарны акшарлый. Прицеплы машина белән идарә итә. Декларация тутыра... Болар, кешеләр өчен башка кемнәрдер эшләп биргәнгә, актуальлеген җуеп бара. Боларны хәзер «сатып алып» була... Кешелек җәмгыяте кайчан шундый өметсезгә әйләнде соң?!

Ә аннары экраннарга роман буенча швед режиссеры Ханнес Холм төшергән фильм чыкты. Һәм 2017 елда – Европа киноакадемиясе призын, аннары «чит телдә төшерелгән иң яхшы фильм» номинациясендә Оскар яулады. Уве ролен уйнаган швед актеры Рольф Лассгордка бу рольне уйнаганда, нәкъ герое кебек үк, 59 яшь иде. Фильм Россия кино тәнкыйтьчеләре рейтингы буенча төгәл 100 баллга ия. Бүгенге көннең Кинопоиск буенча «Иң яхшы фильмнары» исемлегенә керә.

«ХАКЫЙКАТЬНЕ КҮЗ БЕЛӘН КҮРЕП БУЛМЫЙ, БАРЫ ТОЕП КЫНА...»

МАРИША ПЕССЛ, «НОЧНОЕ КИНО»

Мариша Пессл бу романы белән соңгы ике елда китап рейтингларының иң югары баскычыннан төшми. «Ночное кино» Интернет аша иң еш заказ биреп алдыра торган китапларның берсе буларак билгеле. Сайтларда язылып укучылар исәбенә караганда да, рейтингның алдынгы урыннарында.

Беренче карашка, детектив, триллер жанрына тәгаенләнгән әсәр жанр дигән кысаларны гомумән җимереп ташлый, аларның берсенә дә сыешмый. Постмодернның матур традицияләрен дәвам итеп, уен, квест элементын төп нигез итеп алса да, эчтәлеге һәм күтәргән проблематикасы, колачы белән ул әдәбиятта мәгълүм булган фәлсәфи масштаблы роман-эпопеяларга барып тоташа. Классик әдәби традицияне югары бәяләгән, әдәбият буенча зәвыклы гуманитар белем алган Пессл өчен бу әһәмиятле булса кирәк: Борхес, Маркес, Кортасар, Сафон, Кафка, Хичкок, Линч, Кубрик... лабиринтларына ишарәне шунда ук тоясың. Пессл ачыктан-ачык зәвыклы укучы белән эш итә: китап азагында тезелеп киткән сылтамалар гына да шул хакта сөйли. Әмма Пессл шундый виртуоз ки, ул укучысының алдында ниндидер бизәк, паззлны уйнатып алуга, кубик-рубикны боруга, аны шунда ук яшереп тә куя, йә ачып та бирә. Һәм, гаҗәеп гармонияле рәвештә, әллә ни зур интеллектуаль багажга ия булмаган укучыга да үзен детектив белән триллер, ә тирәнрәк катламда драма һәм фәлсәфи роман кысаларында уңайлы хис итәргә мөмкинлек калдыра. Киеренкелек белән алдыра: һәр бит саен үзеңне ауга чыккан аучыдай, йә булмаса, кемдер тарафыннан эзәрлекләнгән җанвардай тоясың... китапны азга гына да калдырып булмый, ул физиологик яссылыкта тәэсир... хәтта әсир итү магиясенә ия.

– Бу китап шул дәрәҗәдә камил, киң колачлы һәм катламлы ки, аны бер генә кеше язган булуына ышанасы да килми. Мариша Пессл моны, чынлап та, берүзе башкарып чыккан икән, димәк, ул коточкыч эшчән булу белән беррәттән, үз эчендә күпсанлы һәм бик тә каршылыклы персонажларны «яшәтергә» дә сәләтле. Китап искиткеч күптавышлы, күпаһәңле... Кыскасы, бу – идеаль китап!

– Теодор Рошакның культ буларак кабул ителгән «Киномания»сенә римейк язуны максат итмәсә дә, Мариша Пессл, әлеге олпат романы белән, аның китабына сылтама ясамый калмый. Әмма римейк кына булыр өчен Пессл артык җитди колач алган. Бу китапны Стивен Кинг, Гиллиан Флинн һәм Стиг Ларссоннар күмәк утырып иҗат иткән диярсең... Һәм ул шуңа да моңа кадәр булган бер генә әсәр белән дә тулаем тәңгәл була алмый.

LiveLib китап порталы экспертлары бәяләмәсеннән.

Әйе, килешми мөмкин түгел: романның полифониясе һәм интертекстуаль чикләре чын мәгънәсендә чиксезлеккә алып чыгарга сәләтле. Мариша Песслның һәр персонаж, вакыйга белән бәйле сюжет тармаклары төгәл уйланган. Шулай ук – яңа дөньялары да. Без каһарманнарның чынлап та барлыгына, арабызда йөрүенә, Тормышның үзеннән булуына ышанабыз. Бакманның үтә тормышчан чынбарлыгыннан аермалы буларак, нигездә мистификация, шартлылыкка корылган тукыманы Пессл безгә шул дәрәҗәдә ышандырырлык итеп бирә ки – укучы, китапны куеп торып, чыннан да анда күрсәтелгән веб-сайтларны эзләргә керешә, сылтамалар буйлап уза, кинохроникаларны актара, исемлекләрне барлый, кешеләрне эзли... – кыскасы, автор тәкъдим иткән бу постмодернистик Уен кагыйдәләре белән ихластан килешә, «төнге фильмнар» остасы булган Бөек Мистификатор Кордова һәм аның кызы Александра дөньясында яшәргә берсүзсез ризалаша. Әйтерсең, ул бу чакыруны бик күптәннән көткән һәм аңа ихластан сусаган...

Кайчандыр, 90 нчы елларда, мондый эффектка «Твин Пикс» сериалы белән режиссер Дэвид Линч ирешкән иде. Аның сериалы куйган «Лора Палмерны кем үтерде?» соравына җавапны бөтен җир шары буйлап эзләделәр, сериал башваткычына миллионнар җәлеп ителде. Нуленче елларда мондый уенны «Остаться в живых» (Lost) сериалы белән Джеффри Джейкоб Абрамс һәм аның командасы кабатлады... Пессл кулланган алымнар нәкъ менә кино, сериал моделенә якын тора. Юкка гына аның романы кино индустриясенә багышланмаган да, иҗатның ничек итеп реаль тормыштан туенуы, аны үзенә буйсындыруы, кайчак хәтта, кешеләрне, чынбарлыктан йолып алып, харап итүе турында да сөйләми ләбаса...

Әсәр төн уртасында, йокы алмыйчамы, әллә эчкән баштан исәнгерәпме, йөгереп кайтырга чыккан журналист Скотт Макгрэтның истәлекләреннән, ягъни үткәнгә экскурстан башланып китә. Хронотоп: Нью-Йорк, төнге 02:32. Бу тәгаенләү шунда ук шикләндереп куя. Әмма баштарак син ул шикне куып таратасың... Ә инде әсәрнең барышында «юкка» икәнлеген абайлап аласың... ИГЪТИБАР: шулай итеп, автор безне интуициягә ышану парадигмасына чакыра! Ул уенын җиңел кораллар кулланып башлый да, авыр артиллериягә күчә.

Мариша Пессл Оклендтан ерак түгел урнашкан Кларксон шәһәрчегендә дөньяга килә. Әтисе Дженерал Моторс компаниясендә инженер булып эшли, әнисе йорт белән шөгыльләнә. Алар аерылышкач, балачагы Төньяк Каролинаның Эшвилл шәһәрендә үтә. Әнисе аңа интеллектуаль белем бирергә омтыла. Бу «белем» әдәбиятны су урынына эчүне генә күздә тотып калмыйча, чын мәгънәсендә, аксөякләрчә колачы белән аерылып тора. Үз эченә француз теле дәресләре белән атта йөрүне, рәсем ясау, классик музыка белән джазны үзләштерүне дә ала.

Төньяк-көнбатыш университетын тәмамлагач, Мариша Пессл Бродвейның Бернард исемендәге гуманитар колледжында укый. Биредә ул Фи-Бета-Каппа исемле элитар җәмгыятькә кабул ителә һәм колледжны инглиз әдәбияты буенча фәнни дәрәҗә алып тәмамлый.

«Некоторые вопросы теории катастроф» дип аталган беренче эре романы 2006 елда басылып чыга, 30 дан артык телгә тәрҗемә ителә. Икенче романы – «Ночное кино» – Нью-Йорк Таймс тарафыннан бестселлер дип игълан ителә. Бу романны Американың алдынгы басмалары (Cosmopolitan, Bookpage, Kirkus Reviews) «ел китабы» дип игълан итте.

Ничек кенә булмасын, һәрберебезнең Кордова белән бәйле үз тарихы бар.

Әйтик, күршедәге берәү, көтмәгәндә-уйламаганда, чардактагы ташландык тартмадан аның фильмын табып ала да бүтән караңгы бүлмәләргә гомерендә дә берьялгызы керергә кыймый башлый.



Кордовага төрлечә карарга мөмкин. Ачуланырга, кире кагарга, тәнкыйтьләргә, сокланырга. Кайта-кайта фильмнарын карап, мәгънәләр эзләргә. Аңа барыбер: без аңа нинди генә мөнәсәбәт белдермик, ул үз тормышын яши, эшен эшли бирә. Ул – без курыккан ярык, кара тишек, хәвеф, ялангач калган дөньябызның барыбыз да качып котылырга омтылган яшерен почмагы, анда карарга көчебез дә, оятыбыз да җитми...

Кордова белән бәйле тарихым икенче кабат бер яңгырлы октябрь төнендә башланды. Мин беркая да илтми торган әйләнә буенча чабып йөрүче әлсерәгән йөк атына әверелгән идем инде. Кайчандыр чабышкы булуымны оныта башлап... Һәм әнә шул төндә каршымда, җир астыннан килеп чыккандай, җете-кызыл палтә кигән таныш түгел бер туташ пәйда булды...

Ә икенче көнне газета-журналлар, Интернет-порталлар шау-гөр килә: 24 яшендә атаклы режиссер, Оскар иясе Станислас Кордованың кызы Александраның мәете Чайнатаундагы пакгаузларның берсендә табып алынган... Фильмнарын киң прокатка чыгармыйча, үзе дә моңарчы публикага күренмичә, йомылып яшәве белән билгеле Кордованың шәхесенә кызыксыну бермә-бер көчәя. Ул фанатлары катакомбаларда кача-поса карый, караганнан соң, аерым бер халәткә керә һәм, яңадан үзенә әйләнеп кайтмый торган тәэсир, көчкә ия булуы аркасында, «иблис белән килешү төзегән зат» дигән исем йөртә... Һәм менә бу исемнең тамырлары кайда барып тоташа икәнлеген ачыкларга керешә әсәр каһарманы.

Пессл безне параллель чынбарлыкка шулкадәр оста кертеп күмә ки, тора-бара без инде аның реаль тормыштан да чынрак булуына инана башлыйбыз. Крандагы су тамчысының өзелеп төшүе дә сискәндереп җибәрә. Ә җир асты кичүендә каршыга килгән капюшонлы берәүне күргәч, бармак очларының ук суынын сизәсең... Укып бетергәч тә, берара романнан әйләнеп кайттыңмы, юкмы икәнлегеңне ваемлый алмый йөрисең.

Әсәрнең каһарманы Скотт Макгрэт та нәкъ безнең белән бер халәт кичерә: бермәл үзенең Кордова фильмына тозакка эләгүен абайлап ала да, үзенә нәрсә янаганын белергә тырышып, кино белгеченә бара. Тегесе аңлатып күрсәтә: фәлән-фәлән билгеләр синең каһарманыңа фәлән хәтәр янаганны белдерә, ди. Фәлән-фәлән юллар белән чыгарга мөмкин булуына ишарәли Кордова фантазиясеннән.

Әмма әсәр азагында без аның фильмнан чыгуына да, Александраның үлеменә дә тулаем ышана алмыйбыз. Төп линиядән чыгарма булган параллельлар барлыгына да ымлый кебек автор. Әмма монысы инде – бөтенләй башка укылыш, димәк ки – бөтенләй икенче Тарих та.

Нәрсәдә соң Кордова иҗатының көче? Аның 15 коточкыч фильмы безне күзләребез белән аңыбызга беркайчан да тулаем ышанмаска өйрәтә. Чөнки күзләр дә, аң да һәрвакыт алдый. Димәк ки, дөньяны алар аша гына танып белү дә – төгәл һәм чынбарлыкның үзенә тулаем тәңгәл була алмый...

«Ночное кино» безгә Чынбарлыкны үз инануларыбызга бәйле рәвештә сайлап, үз иманыбызга тәңгәл рәвештә генә яшәргә кирәклегенә инандыра бугай. Куркыныч фильмнардан гадәти тормышның күпкә куркынычрак булуын ваемларга телибезме? Тәвәккәлли алабызмы? ҮЗЕБЕЗ ЯШӘРГӘ ТИЕШЛЕ ТОРМЫШНЫ сайламыйча, кайсы фильмнарда адашып йөрибез без, кемнең фантазияләрендә? Пессл бу сорауны сырты белән куя.

Ә без... Без җавап бирергә әзерме?

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

МАХСУС ПРОЕКТ

— 40нчы чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Василий Кудряшов, ТР Дәүләт Төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе, апрельдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Җаваплы төзүчеләр һәм актив озын гомер телибез

Азат Нигъмәтҗанов,
Казан башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте буенча беренче урынбасары

– Хөрмәтле Василий Александрович, юбилей көнегездә килеп ирешкән күп кенә җылы теләкләргә һәм котлауларга кушылырга рөхсәт итегез! Без Сезнең белән республикабыз башкаласы территориясендә барган төзелеш мәсьәләләре буенча уңышлы хезмәттәшлек итүебезгә ихластан сөенәбез.

ТР Дәүләт Төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе буларак, Сезгә төзелеп килүче объектларның куркынычсызлыгы буенча гына түгел, төзелеш эшләрен башкаручы белгечләрнең иминлеген саклау буенча да зур җаваплылык йөкләнә. Әлеге тармакта дәүләт акчаларын нәтиҗәле куллануга күзәтчелек итү нәкъ менә Сезгә тәгаенләнгән. Сез озак еллар буена алдыгызга куелган бурычларны уңышлы башкарасыз һәм хезмәтегез белән коллегаларыгызның үзегезгә карата булган ихтирамын арттыра гына барасыз.

Сез республикабызның беренче затларының ышанычын казандыгыз һәм хезмәтегез күп кенә дәүләт бүләкләренә лаек булды. Һөнәри югарылык баскычыннан Сез үзегез контрольлек иткән объектларда барган төзелеш эшләренең барлык этапларындагы җитешсезлекләрне дә күрә беләсез. Актив эшчәнлегегез нәтиҗәсендә төзелеш мәйданнарында хезмәт куркынычсызлыгын саклау кагыйдәләренә һәм нормаларына кагылышлы күпләгән кискен моментлар төзәтелде.

Бүгенге күркәм бәйрәмегездә Казан шәһәре башкарма комитетының төзелеш блогында эшләүче барлык хезмәткәрләр һәм шәхсән үз исемемнән эшегездә һәм шәхси тормышыгызда иминлек, актив озын гомер телим! Җаваплы, намуслы төзүчеләр белән эшләргә туры килсен! Күркәм эшләрегездә бары тик уңышлар гына юлдаш булсын!

Үзегезгә һәм якыннарыгызга – исәнлек-саулык, бәхет, тынычлык һәм иминлек!

Реклама

Фото Казан башкарма комитетыннан алынды

Татарстанлылар иминлеге хакына ышанычлы һәм сыйфатлы хезмәт

Николай Глазков,
«Татнефть» ГАҖ генераль директоры урынбасары

– Хөрмәтле Василий Александрович, «Татнефть» ГАҖнең капиталь төзелеш хезмәте коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез!

Соңгы елларда республикабыз төзелеш комплексының гаять зур темплар белән үз әйләнешен арттыруы шатландырмый кала алмый: торак йортлар салына, предприятиеләр һәм спорт объектлары төзелә, транспорт инфраструктурасы яңартыла. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә зур җаваплылык һәм киң күләмдәге эш тә йөкләнә. Төзелүче биналарның һәм корылмаларның сыйфаты һәм ышанычлылыгы, кешеләрнең иминлеге һәм заманча шартларда яшәү мөмкинлеге нәкъ менә Сез үзегез, Сезнең командагыз башкарган зур хезмәттән тора. Сез җитәкләгән структураның уңышлы эшчәнлеге, үз эшенә карата булган җаваплы мөнәсәбәте шикләнергә урын калдырмый.

Хөрмәтле Василий Александрович, юбилеегыз көнендә Сезгә һәм якыннарыгызга иминлек, ныклы сәламәтлек телибез! Йортыгызда гаилә җылысы сүрелмәсен, анда Сезне һәрвакыт бәхет, муллык көтсен!

Реклама

Фото «Татнефть» ГАҖнән алынды

Республиканың йөзен үзгәрткән тәҗрибә

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиапромы» КТ генераль директоры

Хөрмәтле Василий Александрович!

«Казан Гипронииавиапромы» КТ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне күркәм юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Төзелеш тармагы һәрвакытта да үзенә генә хас үзенчәлекле сыйфатларга ия булды. Әлеге өлкәдәге проблемалар көндәлек тырышлыкны тирән белем һәм профессионализмны таләп итә. Хезмәт биографиягез дәвамында Сез бу бурычларны уңышлы хәл итеп киләсез. Җаваплылык һәм ышанычлылык – Сезне характерлаган сыйфатлар әнә шулар! Ә бу сыйфатларга ия зат чын лидер һәм үз эшенең остасы.

«Камгэсэнергострой» ЖБ, «Промстрой» СМТ тресты һәм «ЕлАЗстрой» ААҖ кебек хөрмәткә лаек оешмаларда эшләү тәҗрибәсе, характер ныклыгы һәм намуслылык белән бергә, Сезгә алдыгызга куелган идарә итү бурычларын иң югары дәрәҗәдә хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Инфраструктура объектларын проектлау һәм төзү буенча Сезнең белән бергә тормышка ашырылган уртак тәҗрибәбез – «Алабуга» МИЗ – ел саен республикабызга яңа технологияләр китерә. Объектларда ирешелгән югары күрсәткечләр һәм резидентлар санының артуы нәкъ менә Сезнең хезмәтегез нәтиҗәсендә тормышка ашты.

Административ-эшлекле үзәк һәм «Форд-Соллерс» предприятиесе буенча эшләнгән эшләр Сезнең эштәге соңгы нәтиҗә белән кызыксынуыгызны, шуңа йөз тотуыгызны ачык дәлилли. Шулай ук төзелеш барган территорияләрдә экологияне саклауга игътибарлы мөнәсәбәтегез дә бездә һәрвакыт ихтирам уята.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш инспекциясендәге хезмәтегез профессиональ эшчәнлегегездә аерым бер урын алып тора. Безгә, Сезнең белән һәм коллегаларыгыз белән берлектә, Су спорт төрләре сарае, йөзү бассейннары, «Казан» Халыкара аэропорты, шәһәр яны тимер юл вокзалы, Ленин дамбасының һәм Казансу елгасы аша күпернең бер өлеше, Энгельгардт исемендәге Планетарий бинасы кебек 2013 елгы Универсиада объектларын һәм инфраструктурасын, шулай ук «Иннополис» объектларын төзергә насыйп булды.

Сезнең белән тандемда МДФ, табаклы пыяла, автомобиль пыяласы, «FORD» автомобильләре һәм автомобиль двигательләрен җитештерергә, «Химград» технополисында һәм «Алабуга» МИЗнда санитар-гигиена билгеләнешендәге кәгазь җитештерү заводлары кебек сәнәгать объектлары буенча бергә эшләргә туры килде. «Казан вертолет заводы» ГАҖ, «С.П.Горбунов ис. КАҖБ» ААҖ, «Радиоприбор» АҖ, «Серго ис. Завод» ЖБ» АҖ», «А.М.Горький ис. Яшел Үзән заводы» АҖ һәм «КПКБ» АҖ – бу оешмалар шулай ук Сезнең профессиональ игътибарыгыздан читтә калмады.

Сезнең кебек белгечләр бүген безнең тармакта һичкайчан булмаганча кирәкле. Бай тормыш тәҗрибәгез һәм җиренә җиткереп башкарылган эшегез республика алгарышына һәм аңа яңа үрләр яулауга юнәлдерелгән.

Уңыш һәм иминлек Сезгә һәрвакыт юлдаш булсын. Гаиләгездә тынычлык һәм җылылык көтеп торсын, якыннарыгыз белән бер-берегезне кайгыртып яшәргә насыйп булсын! Эшегездә уңышлар һәм җиңү шатлыклары телибез!

Казанский Гипронииавиапром

Адрес: Татарстан Республикасы, Казан ш., Дементьев ур., 1
Телефоннар: (843) 571-95-48,
Факс: (843) 571-96-56
Эл. почта: root@gap-rt.ru
Сайт: www.gap-rt.ru

Реклама
Фото «Казан Гипронииавиапромы» КТ нән алынды

Татарстанның төзелеш тармагы – ышанычлы кулларда

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Василий Александрович!

«Грань» төзелеш компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларны кабул итегез!

Татарстан Республикасының төзелеш комплексында эшләгән вакыт эчендә, бу тармакның үзенчәлекләрен һәм аның белән идарә итү кануннарын өйрәнеп, Сез гади хезмәткәрдән башлап югары даирә җитәкчесенә кадәр хезмәт юлы уздыгыз. Сезнең Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчелегенә килүегез аңлаешлы һәм көтелгән булды.

Һөнәри осталыгыгыз, оештыру сәләтегез һәм яңача фикерләвегез Сезгә хезмәткәрләр, партнерлар һәм предприятие җитәкчеләренең ышанычын яуларга мөмкинлек бирде.

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе төзелеш тармагында дәүләт контролен гамәлгә ашыра һәм республиканың әһәмиятле объектларын гамәлгә ашыруга да сизелерлек өлеш кертә. Сезнең контрольдә 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада объектлары сафка басты, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен модернизацияләү программасы тормышка ашырылды, Болгар шәһәрендә тиндәшсез объектлар торгызылды һәм төзелде.

Таләпчәнлегегез, тәвәккәллелегегез һәм лидерлык сыйфатларыгыз, командада эшләү осталыгы белән бергә, уңышка ирешүнең нигезе булып тора!

Сезгә чын күңелдән сәламәтлек, җаваплы вазыйфагызда уңышлар, киләчәктә дә нәтиҗәле хезмәт, көч-энергия, күңел көрлеге һәм ниятләрегезнең тормышка ашуын телим. Сезнең эшлекле сыйфатларыгыз катлаулы һәм мөһим бурычларны алга таба да уңышлы хәл итәргә булышсын, ә янәшәдә һәрвакыт ышанычлы дуслар һәм фикердәшләр булсын!

Фото «Грань» ҖЧҖ нән алынды

Ныклык һәм югары профессиональлек үрнәге

Руслан Нурмөхәммәтов,
«#Суварстроит» ҖЧҖ
генераль директоры

– Төзелеш тармагы гаять күпкырлы. Биредә барлык системаларның эше мөмкин кадәр камил итеп җайга салынырга тиеш, чөнки без миллионлаган кешеләрнең тормыш сыйфаты өчен җаваплы. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең эше һәрвакыт гражданнарның иминлеген тәэмин итүгә, республикабызның тотрыклылыгына һәм чәчәк атуына юнәлтелгән. Василий Александрович лаеклы җитәкченең бөтен сыйфатларын үзендә туплаган зат. Ул эшне шул рәвешле кора алган ки, оешмадагы һәр хезмәткәргә җаваплылык хисе һәм эшкә намуслы мөнәсәбәт хас. Һәм без моны көн саен үз тәҗрибәбездә күрә алабыз.

2018 елда «#Суварстроит» ҖЧҖ 8 объект төзелешен тәмамлады һәм төзелеш потенциалын 545 мең квадрат метрга кадәр арттырды. Объектларны сыйфатлы рәвештә файдалануга тапшыруны тәэмин итүдә Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе белгечләре ярдәм итә. Көтеп алынган фатир ачкычлары булачак ияләренә тапшырылганчы, инспекция белгечләре йортларны тикшерә, бәяли. Алар кабул иткән һәр карарда ныклык һәм югары профессиональлек сизелә.

Василий Александрович, Сезне чын күңелдән котлыйбыз, ныклы сәламәтлек, иминлек, игелек һәм Татарстан Республикасына файда китерү юлында яңа уңышлар телибез! Хезмәтегез өчен рәхмәт!

Реклама

Фото «#Суварстроит» ҖЧҖ нән алынды

АТКАЗАНГАН ИГЕНЧЕ ЮЛЫ

Нәҗип Бакиров, «Земля» «Республика кадастр үзәге» АҖ генераль директоры киңәшчесе, апрель аенда үзенең 75 яшьлеген билгеләп үтә.

Хөрмәтле Нәҗип Баһманович! Юбилей алдыннан тормышыгызның иң мөһим мизгелләрен искә алырга рөхсәт итегез.

Сез шактый авыр чорда – сугыш барганда Иске Кыязлы авылында тугансыз. 1944 елның 16 апреле – бар яклап нәтиҗәле гомер юлыгызның башы ул. 1961 елда сез Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетына укырга кергәнсез. Совет Армиясенең танк гаскәрләре сафларында үткән өч ел холык-ихтыярыгызны ныгыткан.

Хезмәт юлыгыз Вахитов исемендәге колхозда җаваплы вазыйфадан – баш агроном сыйфатында башланып китә. Тиздән сезнең җитәкче буларак уңышларыгызны күреп тә алалар. Аксубай районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы вазыйфасында Сез үзегезгә йөкләнгән бурычларны холыксыйфатыгызга хас җаваплылык хисе белән үтәдегез. Сез һәрвакыт алга, югарыга омтыласыз. Партия райкомында уңышлы эшләгәннән соң, Сезнең лидерлык сыйфатларыгызны танып, үзегезне ТАССР Югары Советына сайлаулары һич тә гаҗәпләндерми. Соңрак Сез Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе вазыйфасына билгеләндегез.

1998 елдан башлап, Сезне «Земля» республика кадастр үзәгенең абруйлы җитәкчесе буларак беләбез. Сез бинаны үзгәртеп коруга һәм яңадан җиһазландыруга күп көч керттегез, бу исә башкарыла торган эш күләменең тиз артуына һәм яңа икътисадый мәйданнарны яулап алуга китерде. Бүген Сезнең ярдәм белән безнең кадастр үзәге үз тармагында әйдәп баручы үзәкләрнең берсе булып тора һәм Татарстан үсешенә саллы өлеш кертә.

Сезнең практик тәҗрибәгез һәм һөнәри осталыгыгыз кадастр үзәге белән генә чикләнми. Сезгә Татарстан Хөкүмәте һәм Росреестр идарәсе төрле контрактларны ышанып тапшыра, Сезнең җитәкчелектә «Газпром» ГАҖ, «Төньяк көнбатыш магистраль нефть үткәргечләре» ААҖ, «Челтәр компаниясе» ААҖ һәм «Россия тимер юллары» ААҖ кебек компанияләрнең заказлары уңышлы үтәлде. Без Сезгә тиң булырга телибез, ару-талу белмәс хезмәтегез белән безне һәрдаим укырга, нәрсәгә дә булса өйрәнергә һәм үсешкә омтылырга рухландырасыз. Нәкъ менә шуңа күрә оешмабыздан чиктәш тармакларда һәм дәүләт хакимияте органнарында да бик югары бәяләнгән тәҗрибәле белгечләр үсеп чыкты.

Сезнең киеренке хезмәт белән беррәттән фәнни эшчәнлекне һәм гаилә тормышын бергә уңышлы алып баруыгыз да зур соклану уята. Бу чын мәгънәсендә зирәк һәм булдыклы кешенең генә хәленнән килә!

«Земля» Республика кадастр үзәге коллективы исеменнән Сезне түгәрәк гомер бәйрәмегез белән котларга, үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы саулык-сәламәтлек теләргә рөхсәт итегез! Ташып торган энергия һәм зирәк акыл киләчәктә дә ышанычлы юлдашыгыз булсын. Без сезгә ныклы җитәкчелек һәм кыйммәтле киңәшләрегез өчен рәхмәтле. Сез янәшәдә булганда барлык үрләрне яулый алуыбызга ышанабыз.

Хезмәтегезнең кадерен беләбез һәм чиксез хөрмәт итәбез!
«Земля» Республика кадастр үзәге» АҖ коллективы

Реклама

Фотолар «Земля» Республика кадастр үзәге» нән алынды.

ЛАШМАН: БИЕКЛЕКТӘН ТӨШМӘҮ...

«Татар авыллары» турындагы язмаларыбызны дәвам итеп, Чирмешән районына юл тоттык. Бередә бик тырыш, булдыклы, җиңел аралашучан халык яшәгәнен яхшы беләбез. Суган үстерүче, чана, көянтә ясаучылары белән Чирмешәннең даны еракларга киткән. Озын сүзнең кыскасы, районның иң зур авылы – Лашманга сәфәр кылдык.

Автор:
Руфия Фазылова

РЕСПУБЛИКАДА БЕРДӘНБЕР!

Лашманга барган көнне табигатьтә чын яз иде. Тоташ карлы-буранлы кышкы көннәрдән соң ялт итеп кояш чыгуны яхшы билге буларак кабул иттек. Бередә халык та кояшлы булырга тиеш, дип фараладык. Чынлап та шулай булып чыкты...

Лашман авылында 1216 кеше яши, 508 хуҗалык бар. Татарстан районнары буйлап шактый йөргәнгә күрә, сәфәргә баргач, гел чагыштырып карыйм: теге яки бу авыл башкалардан кай ягы белән аерыла? Лашманда әле дә урта мәктәп бар. Анда 175 укучы белем ала. Мәктәпнең үз бассейнына хәтле бар. Чирмешән районының беренче башлыгы – Лашманда туып-үскән Минсәгыйть Шакиров 2010 елда туган авылы мәктәбенә әнә шундый бүләк ясаган. Әйтергә кирәк, бассейны булган авыл мәктәпләре республикада бүтән юк, дип горурланып сөйләделәр. Без, анда керең, укучылар, укытучылар белән танышып чыктык. Һәм йомшак кына итеп әйткәндә, гаҗәпкә калдык: һәр авылда шундый мәктәпләр булса, яшьләр читкә китмәс иде. Сүз тәрбия, укучыларның ялын оештыру мәсьәләләренә кереп китте...

– Бездә бер генә тәмәке тартучы укучы да юк, – диде Лашман мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Илдар Мөбәрәкшин.

– Каян беләсез? – дип төпченәм.

– Беләм. Бездә спорт белән шөгыльләнмәгән малайлар юк чөнки. Менә карагыз...

Һәм стенадагы сурәтләргә ымлый... Көрәш буенча республика күләмендә узган турнирларда җиңүчеләр, үз чемпионнары да бар икән. Тренерлары – Рафик Хәниф улы Гатин. (Һәр ике укучының берсе көрәш белән шөгыльләнә, ахры, бередә, дигән фикер туды.) Спортзалга якынайганда тагын бер стенага күзебез төште: монысы – уктан ату буенча республика дәрәҗәсендәге җиңүчеләр. Республика мәктәпләрендә бик сирәк күренеш бу – Лашман мәктәбендә уктан ату буенча махсус түгәрәк эшли.

Физкультура укытучысы Фаиз Билалов үз эшенең фанаты.

– Физкультура укытучыбыз Фаиз Билалов үз эшенең фанаты, – диде директор урынбасары. – Мәктәптә уктан ату буенча түгәрәк булдыру – аның идеясе. Кызлар-егетләр 2013 елдан бирле уктан ату белән шөгыльләнә.

– Республикада физкультураны үстерүгә, балаларны спортка җәлеп итүгә зур игътибар бирелә.

Фото: Лилиана Вәлитова

Атнага өч тапкыр кергән физкультура дәресенең берсен укучылар бассейнда үткәрә.

Лашман – Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Наил Шәйхетдиновның туган авылы. Аның һәм авылның башка күренекле кешеләре турында истәлекләр мәктәп музеенда саклана.

Президентыбыз да әлеге сәясәтне хуплый, – диде Фаиз абый. – Балаларны кечкенәдән спортка тарту – бик дөрес юл. Узган ел мәктәпне тәмамлаган укучылар арасында уктан ату буенча спорт мастерына кандидатлар бар. Алар районда бездә генә.

Фаиз Билалов йөзү буенча да тренер. Атнага өч тапкыр кергән физкультура дәресенең берсен укучылар бассейнда үткәрә икән. Теләге булганнар дәрестән соң аерым килеп йөзә. Ата-аналар да балалары белән бергә йөзәргә килә ала.

– Бассейнда йөзү бушлаймы? – дим.

– Әлбәттә, – ди Фаиз абый. – Безнең мәктәптә түләүле бер генә түгәрәк тә юк.

– Ә бассейнны карау кем җилкәсендә? Ни дисәң дә, аның чыгымнары бар бит.

– Алар әллә ни зур түгел. Мәктәп сметасына кергән ул. Дәүләт хисабыннан түләнә.

Фаиз абый кайчандыр Лашман мәктәбендә директор вазыйфасын да башкарган. Аның кебекләр турында: «Аз сөйли, күп эшли», – диләр. Бассейнга йөзәргә ун километр ераклыкта урнашкан район үзәгеннән үк киләләр. Югыйсә, Чирмешәндә дә бассейн бар. Тик анда Фаиз абый кебек тренерлар юктыр, күрәсең...

«БЕРӘҮ ДӘ ЫШАНМАДЫ»

Лашман авыл җирлеге башлыгы Рәвхәть Фәттахов безгә авыл буйлап экскурсия ясады. Юлсыз бер урам да юк бирегә. Йортлар төзек, арада ике катлы, заманча итеп төзелгәннәре шактый. Үз эшләрен башлаган 13 шәхси эшмәкәр бар икән. Кайберләре авылдашларын да эшле иткән.

– Авылыгызның киләчәге бар, димәк, – дим Рәвхәть абыйга.

– Бар дисәк тә була... Тик Лашман картая шул. Без үскәндә мәктәптә беренче класска йөзәр бала укырга керә иде. Хәзер уннан да артмый. Мисал өчен, узган елны 11 бала туды, 19 кеше вафат булды. Аерма зур бит. Еллык хисап ясап утырганда, шул саннарга күңелсезләнеп карап утырдым.

Лашманда заманында кирпеч заводы, пекарня, районның «Сельхозтехника» оешмасы гөрләп эшләгән. Колхоз таркалгач, боларның барысы да юкка чыккан.

– Дөресен генә әйткәндә, нефтьчеләр килеп тә халыкны котыртты, – ди авыл җирлеге башлыгы. – Күп акча биреп, авыл кешесен җир эшеннән аерып алдылар. Колхозларда эшләүче калмады. Нефть өлкәсендә бүген 89 кеше эшли, артыгы аларга кирәк тә түгел. Авылда төпләнүчеләр үз нигезләрендә калды, билгеле, ә менә яшьләргә эш бик юк, шуңа читкә китәләр. Гөрләп торган Лашман бүген элеккеге дәртен югалта төште.

Рәвхәть абый авылның элеккегесе белән бүгенгесен чагыштыра.

– Сугым цехы ачу – күптәнге хыялым иде, – диде «Чирмешән» кулланучылар кооперативы җитәкчесе Альфрит Хәйрисламов.

Тик башка районнар, башка авыллар белән чагыштырганда, Лашман әле куәтле санала. Һәрхәлдә, безгә шулай тоелды.

Шәхси эшмәкәрләр унөч, дидек, шуларның икесе КФХ оештырган. Калганнары бүтән өлкәдә эшли: сәүдә, җитештерү...

Авыллар өчен шактый яңа юнәлеш – сугым цехында булдык. Аның рәсми исеме – «Чирмешән» кулланучылар кооперативы. Биредә малларны суеп кына калмыйлар, ә пилмән, кәтлит, мантый, тутырма, голубцы кебек ярымфабрикатлар да эшлиләр. Дөрес, ризык әзерләүгә әле өч ай элек кенә алынганнар. Шулай да ярымфабрикатларны халык яратып өлгергән инде. Киләчәккә планнары – казылык ясау.

– Сугым цехы ачу – күптәнге хыялым иде, – диде «Чирмешән» кулланучылар кооперативы җитәкчесе Альфрит Хәйрисламов. – Пенсия яшен арттырдылар, шулай булгач, әле эшләргә дә эшләргә безгә. Дөресен генә әйткәндә, минем бу эшләрне башкарып чыгасыма якыннарым да бик үк ышанмады.

– Мин дә ышанмадым, – дип көлде янәшәдә торган авыл җирлеге башлыгы.

– Ә ни өчен? Шулай тормышка ашмаслык эш идеме? – дим.

– Сугым цехы төзелешенең смета бәясе – 49 миллион сум. ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы бирә торган грантта катнашыйм дисәң, әлеге акчаның 40 проценты эшмәкәрнең үзендә булырга тиеш. Бу бит авыл кешесе өчен бик зур сумма.

Альфрит Хәйрисламов әнә шулай, бурычларга бата-бата, барыбер теләгенә ирешә. 19 миллион сумга грант ота, районнан өстәп 5 миллион 300 мең сум акча бирәләр. (Район башлыгы Фердинад Дәүләтшинга зур рәхмәтен җиткерде эшмәкәр.) Калганы – кредитлар, әҗәтләр...

– Әни бик рәхәт кеше, – ди Нәхтимә әбинең кызы Мәдинә апа.

– Эшемне әле башлап кына җибәрдем, әмма ихтыяҗ сизелә. Мал суярга аерым хуҗалыклар, шәхси эшмәкәрләр дә килә. Хәзер бит итне сатам дисәң, махсус келәймә кирәк, өйдә суярга ярамый. Үзебез дә итне, эшкәртеп, сатуга чыгарабыз. Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Казан кебек шәһәрләр белән дә элемтәләр булдырдык. Алла боерса, эш җайга салынырга тиеш. Мин шуңа ышанам.

«БУ ХӘТЛЕ КАРАУГА НИЧЕК ҮЛӘСЕҢ?!»

Лашманның иң өлкән кешесе – 101 яшьлек Нәхтимә әби Зыятдинова янында да булдык. Йөзгә җиткәч, кеше яңадан сабыйлыкка кайта, диләр. Әбинең нурлы, сөйкемле йөзен күргәч, моңа чынлап та инанасың.

Нәхтимә әби 8 бала табып үстергән. Бүген шуларның бишесе исән. 18 оныгы, 33 оныкчыгы, сигез оныкчыгының балаларын да күргән-сөйгән.

– Алланың рәхмәте, әни оныкларын да таный, алар белән сөйләшә, ә оныкчыклары килсә, сәгатьләр буе аларның уйнаганын карап, елмаеп утыра. Әни бик рәхәт кеше, – ди әбинең кызы Мәдинә апа.

Елмаю, дигәннән, әби без барында да балкып елмаеп утырды. Һәм тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: авыз эченнән гел дога кабатлап утыра. Нинди сорау бирсәң дә, гел канәгатьлек белән шөкер итә.

– Әни гомере буе намазда булды, әлегә кадәр авылдашларга Коръән тутыра, – ди Мәдинә апа. – Бер намазын да калдырмый.

– Йөзгә кадәр җитү өчен нишләргә кирәк? – дип сорагач:

– Безне хөкүмәт яшәтте, рәхмәт яусын, – диде. – Шушы зиннәтле йортта торам, ай саен пенсия килеп тора. Балаларым бер минутка да ялгызымны калдырмый. Ни теләсәм, шуны ашаталар, юып кидертәләр. Бу хәтле карауга ничек үләсең?!

Аның бу сүзләреннән соң барыбыз да көлеп җибәрдек. Хәер, әби дөрес әйтә. Бик яхшы тәрбия күреп яши ул. «Ветераннарга – торак» программасы буенча район үзенә йорт салып биргән. Газы, суы кергән, бәдрәф – өйдә. Ачлыкны, сугышны күргән әбигә бу зур булмаган йортның да «зиннәтле» тоелуы аңлашыла...

Әби инде дүрт ел урын өстендә икән, егылып аягын сындырган булган. Шуннан сөякләре ялганмаган.

– Йөрмәсә дә, әни утырып тора, шуышып та килә, – диде Мәдинә апа. – Бик бәләкәй бит ул, мунчага алып барырга да җиңел. Курчак кебек кенә йөртәбез...

Нәхтимә әби тормыш иптәше Мәгъсум бабай белән 56 ел гомер иткән. Ире сугышка киткәндә сабый бала белән кала ул. Мәгъсумы 1946 елда исән-имин әйләнеп кайта. Аннан тагын җиде балалары туа. Бабай 86 яшендә вафат була.

– Ике балам кечкенә чакларында үлде, – дип, шул вакытларны искә алды әби. – Берсе – кызамыктан, икенчесе балчыкка тончыгып харап булды. Урманга агачка киткәндә ба-

– Хуҗалыкны шушы сыерлар тартып бара, – ди яшь фермер Раушан Шәйхетдинов.

лалар ялгыз калган иде. И, ник калдырдым, дидем инде соңыннан...

Китәргә кузгалгач, әби кулымны учына алып, бик озак дога укыды, теләкләр теләде.

– Юлларда исән-сау йөр, балаларыңның игелеген күр, Аллаһы Тәгалә исәнлегеңнән аермасын, – диде.

Моннан да матур теләк, яхшы сүз буламы икән? Амин, әбекәем...

ЯШЬ ФЕРМЕР

Авылның иң яшь фермеры белән дә таныштык. Раушан Шәйхетдинов, дүрт ел элек Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлап, авылга кайткан. Һәм КФХ төзегән, 50 баш нәселле сыеры бар.

– Бу – колхоз чорыннан калган ферма бинасы, – диде Раушан. – Без аны ремонтлап чыктык. Ни өчен без, дип сөйлим, минем генә хезмәт кермәгән монда. Беренчедән, КФХны әти белән бергә төзедек, икенчедән, тагын бер партнерыбыз бар, Әлки районында яши ул. Бергәләп эшлибез.

Яшь фермер ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы бирә торган КФХ төзү өчен грант программасында катнашкан, шул акчага сыерлар алган.

– Документлар тапшырганда проблемалар булмады, районнан да бик булыштылар, – диде.

Шәйхетдиновлар КФХда рәсми рәвештә 8 кеше эшли. Монда барысы да җайга салынган: малларга игенне-печәнне сатып алмыйлар. 630 гектар җирләре бар. Җир эшкәртергә дә барлык техниканы булдырганнар.

– Печән, иген белән дә проблема юк, артканын сатабыз хәтта, – ди Раушан.

– Кайсына беренче алындыгыз: җир эшенәме, әллә фермагамы? – дим.

– Икесе берьюлы килеп чыкты. Дистәләгән баш сыерга ашатырга иген сатып ала башласаң, үз-үзен акламый ул. Җирең булмаса, бу кадәр хайван асрап булмый. Әле бит ул сыерлар бозаулый да...

Фермерның планнары зурдан – янәшәдәге ташландык ферма бинасын ремонтлап, сыерларның баш санын арттыру. Әлегә сөйләшүләр бара икән.

– Сөткә бәя түбән, дип зарланалар. Ә сез баш санын арттырырга телисез, – дим.

– Түбәнрәк инде. Тик хуҗалыкны шушы сыерлар тартып бара, хезмәт хакы, башкасы шулардан, дигәндәй. Кышын тәүлегенә 500 литр сөт саудык. Бу начар түгел дип саныйм. Сыерларның барысы да савылмый, әле буазлары да җитәрлек, кайсы ял итә. Сөткә бәя төшкән вакытта республика ярдәм итте – савылган сөтнең һәр литрына өч сум өстәп акча бирде. Эшләргә генә кирәк, ялкауланмаска. Зарланып утырып эш чыкмый.

...Лашман халкы телгә бик үткен. Урамда очраган әбиләр дә, туктап, нишләп йөрүебез белән кызыксындылар. Ачык йөзле, туры сүзлеләр. Бик яратып, якын итеп каййттык үзләрен. Бер генә теләк – авыл бүгенгедәй гөрләп торсын, озын гомерле булсын.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Дәүләт документларыннан күренгәнчә, Лашман исеме авылга XIX гасырның башында бирелә. Тарихтан билгеле булганча,1718 елда патша Петр I указы нигезендә Казан адмиралтействосы төзелә. Анда хәрби кораблар җитештерәләр. Идел һәм Кама буйларындагы урманнарда үскән йөз еллык имәннәрне кисү башлана. Урман кисү, аны ташу, кораблар төзү эшенә дистәләрчә мең крестьян тартыла. Алар «лашманчылар» дип атап йөртелә. Гадәттә лашманга физик яктан көчле ир-атларны сайлыйлар.

XIX гасырның 30 нчы еллары башында Адмиралтейство Әстерханга күчерелә. Ирек алган лашманчыларны кая да булса урнаштырырга кирәк була. Менә шушы чорда аларга хәзерге Лашман җирләренә килеп төпләнергә рөхсәт ителә. Баштарак Вәлит исемле авыл оешкан була, лашманчылар аларга килеп кушыла. Соңрак, Вәлит авылын да кертеп, Лашман исемле зур авыл барлыкка килә. 1900 елгы «Список населенных мест Самарской губернии» дигән документта авыл «деревня Лашманка» дип искә алына...

Бирегә күчеп утыручылар күп булу сәбәпле, ул бик тиз үсә, зурая. Шуңа күрә дә аны халык «Яңавыл» дип тә йөри. Дөрес, бу исем рәсми документларда теркәлмәгән.

(Гаяр Газыймҗановның «Туган җиребез – Лашман» китабыннан).

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый



2018 ел. Кабан күле яры.

Фото: Александр Ефремов

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ



1936 ел. Кабан күле яры.

Фото ТР Милли музееннан алынды